# БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫ ШАРТЛАРЫНДА МИЛЛИ УКЫТУ-ТӘРБИЯ ПРОЦЕССЫН ОЕШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Туган тел – милләтебезне милли-мәдәни һәм рухи яктан берләштерүче зур көч ул. Районыбызның белем бирү оешмаларында туган телне өйрәнү Рәсәй Федерациясе һәм Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларына һәм шуларга таянып эшләнгән “2014-2020 нче елларга Биектау районында яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятен саклау, өйрәнү һәм үстерү программасы”на нигезләнеп алып барыла. “2017-2020 нче елларда ТР Биектау муниципаль районында милли мәгарифне үстерү Концепциясен гамәлгә ашыру буенча юл картасы” (башкарма комитет карары №182, 25.01.2017) кабул ителде.

Районыбыз күпмилләтле. Белем бирү оешмаларында барлыгы 4372 бала белем алса, шуларның 2428е – татар, 1535е - рус, 34 үзбәк, 19 таҗик, 11 чуваш, 9 украин, 9 әрмән, башка милләтләр – 22, 305 бала катнаш никахтан.

Район мәгариф системасында 38 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы уңышлы эшләп килә: 17се - татар телле оешма (330 бала тәрбияләнә), 11 - рус мәктәпкәчә белем бирү оешмасында татар төркемнәре эшли (12 төркем, 228 бала). Татар балаларына туган телләрендә тәрбия һәм белем бирү 41,6% тәшкил итә. Нәниләргә телләрне өйрәтү махсус дәүләт программасы аша башкарыла. Күп кенә балалар бакчаларында туган якны, телне өйрәнү буенча махсус почмаклар бар. Моннан тыш, рус телле тәрбиячеләр дә татар теле курслары узалар.

Районда милли белем бирү оешмалары челтәре сакланып килә. Ул үз эченә 17 татар мәктәбен ала. Татар сыйныфлары Беренче, Икенче, Өченче номерлы Биектау, Шәпше, Усад урта мәктәпләрендә уңышлы эшләп килә. Район буенча татар балаларын туган телләрендә укыту 45,39 % тәшкил итә. Агымдагы уку елында татар төркемнәрен, сыйныфларын ачу һәм аларның эшен дөрес итеп оештыру өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып кала.

Район мәктәпләрендә 91 татар теле һәм әдәбияты укытучысы эшли. Шулардан 6 укытучы (7%) югары квалификацион категориягә, 63 (69%) – беренче категориягә ия. Мөгаллимнәрнең грантларда катнашуына аерым тукталып үтәсем килә: “Укытучы – мастер” грантында 3 (Рамазанова Р.Г., Минһаҗетдинова Р.Ф., Галиәхмәтова Ч.И.) җиңүче булды. “Өлкән укытучы” грантында Мияссарова Л.Р. – җиңүчеләр арасында.

Белем бирүдә югары нәтиҗәләргә ирешүдә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының алдынгы педагогик технологияләрне куллануы ярдәм итә. Татар теле һәм әдәбиятын укыту 3 юнәлештә алып барылды:

1. Татар мәктәпләрендә – татар мәктәпләре өчен булган программа буенча; Ә.З.Рәхимов буенча 2 мәктәп эшли.
2. Татар төркемнәрендә – рус мәктәбендә укучы татар балалары өчен булган программага нигезләнеп;
3. Рус төркемнәрендә дәүләт теле буларак – рустелле укучылар өчен булган программага нигезләнеп. Р.Р.Нигматуллинаның - “Татарча да яхшы бел” укыту-методик комплекты буенча 3 мәктәптә 5 укытучы, Р.З.Хәйдарова дәреслекләре белән 71 укытучы эшли. 2017 уку елыннан Беренче номерлы Биектау урта мәктәбендә беренче сыйныфларның рус төркемендә “Сәлам” УМКсы буенча укытуны башлыйбыз.

Гадәттәгечә, укучыларыбыз бердәм республика тестын үттеләр. Уртача район күрсәткече 3,79, ә республика күрсәткече 3,8. Төп дәүләт имтиханы буенча күрсәткеч бик яхшы: 4,49 (РТ – 3,79). Татар мәктәпләре, татар сыйныфлары укучылары өчен башка предметлардан төп дәүләт имтиханын ана телендә бирүне сайлау мәсьәләсе дә актуаль булып кала. Татар мәктәпләренең 9 нчы сыйныфын 99 укучы тәмамлап, шулардан 49ы имтиханнарны ана телендә тапшырды (гаризалар саны 87 иде): математика – 8, физика – 2, химия – 1, биология – 15, география – 10, җәмгыять белеме – 4, информатика һәм ИКТ – 9.

2016-2017 нче уку елында татар теле һәм әдәбиятыннан республика олимпиадасыннан 4 укучыбыз призлы урыннар яулап кайтты. Җиңүче һәм призерларны әзерләүче хөрмәтле укытучыларыбыз: Хисмәтуллина Г.Р. (Икенче), Әхмәдуллина С.Н. (Өченче), Вәлиуллина С.М. (Шәпше), Хуҗиева Г.Р. (Мүлмә). Агымдагы уку елында аларның саны артыр дип ышанабыз.

Узган уку елында үткәрелгән татар теле һәм әдәбиятыннан V Халыкара олимпиадада Шәпше мәктәбеннән Нефедова Ангелина (укытучысы – Вәлиуллина С.М.) 3 нче урын яулады. Алдагы уку елында җиңүчеләр санын тагын да арттырырга, уңышка ирешү өчен, башлангыч сыйныф укытучылары белән бәйләнештә торып, фәнни-методик яңалыкларга таянып, даими эшләү кирәк. Аеруча әдәбият фәне буенча сәләтле укучылар белән эшкә игътибарны көчәйтү мөһим бурычларның берсе булып кала.

Т.Миңнуллин исемендәге IV республика конференциясендә Абдуллин Айназ (Икенче мәктәп) 2 нче урын, Ахмедов Салават (Алат мәктәбе) номинациядә җиңүче, Абдуллина Г.Р. (Икенче мәктәп) 2 нче урын; Ә.Кәримуллин исемендәге IV республика фәнни - гамәли конференциясендә Низамиева Ә.Н. (Айбаш мәктәбе) 3 нче урын; XII бөтендөнья “Белем җәүһәрләре” интернет-проектлары бәйгесендә Низамиева Ә.Н. (Айбаш мәктәбе) номинациядә җиңүче; РФ телләре буенча төбәк олимпиадасында Әминова Ләйсән (Дөбъяз), Хәкимуллин Азат (Өченче мәктәп), Карнаева Айсылу (Икенче мәктәп), Хисмәтова Динара (Беренче мәктәп), Сафиуллина Эльвира (Беренче мәктәп), Зәбирова Зөлфия (Әлдермеш) - призерлар; “Сәйяр” республика театр фестивалендә “Сандугач” балалар бакчасы коллективы 2 нче урын, Зур Битаман һәм Бөреле мәктәпләре 3 нче урын; И.Хәлфин исемендәге XII фәнни-гамәли конференциясендә Хәсәншин Айнур (Бөреле) 2 нче урын, Садыкова Д.С. (Беренче мәктәп) 2 нче урын, Гарипова К.Б. (Суыксу) 3 нче урын; VI республика Тукай укуларында Зиннәтуллина Айсинә (Айбаш) 3 нче урын, Н.И. Лобачевский исемендәге II бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциясендә Галиева Эльвира (Каенлык) 3 нче урын, Г.Баруди исемендәге республика фәнни-гамәли конференциясендә Ганиева Алчәчәк (Ямаширмә) 2 нче урын, Ибраһимова Айгөл (Өченче мәктәп) 3 нче урын, Нигъмәтуллина Вәсилә (Ямаширмә) 1 нче урын, Исхаков Таһир (Казаклар) 3нче урын, Хисмәтуллина Гүзәл (Айбаш) 3 нче урын, Баһавиева Энҗе (Битаман) 2 нче урын, Латыпова Илалия (Дөбъяз) 1 нче урын, Хөсәенова Алсу (Ямаширмә) 2 нче урын, Кәлимуллина Кадрия (Бөреле) 3 нче урынга ия булды.

Районыбызның Ямаширмә урта мәктәбе һәм “Йолдыз” балалар бакчасы базасында татар теленә өйрәтү буенча милли үзәк эшли. Әлеге үзәкне укытучыларының алдынгы тәҗрибәсе белән уртаклашу мәйданы дияргә була. Узган уку елында уздырылган Галимҗан Барудига багышланган конференция эшчәнлегендә республиканың төрле районнарыннан килгән укытучылар, Мәгарифне үстерү институты белгечләре, Казан федераль университеты галимнәре, ТР Диния нәзарәте белгечләре катнашты .

Укытучыларыбызга методик ярдәм күрсәтү максатыннан район күләмендә семинарлар, осталык мәктәпләре, тренинглар үтә:

“ФДББС гамәлгә ашыру шартларында татар телен һәм әдәби укуны укыту мәсьәләләре” (ТР Мәгарифне үстерү институты белән Беренче Биектау мәктәбе базасында);

“Укучыларны татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадага әзерләү” (КФУ белгечләре белән Ямаширмә мәктәбе базасында);

“Татар мәктәпләрендә укыту-тәрбия процессын оештыру үзенчәлекләре” (мәктәп җитәкчеләре өчен Ямаширмә мәктәбе базасында);

“ФДББС шартларында татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә коммуникатив компетенцияләрне формалаштыру” (Дөбъяз);

“Рус мәктәбе шартларында татар сыйныфлары эшчәнлеге” (Икенче мәктәп);

«Балалар бакчасы һәм мәктәп арасындагы дәвамчанлык» темасына түгәрәк өстәлләр түбәндәге мәйданнарда үтте:

«Кояшкай», «Әтәчкәй», «Көнбагыш» - Икенче номерлы Биектау урта мәктәбе;

«Бәләкәч», «Сандугач» – Өченче номерлы Биектау урта мәктәбе;

«Миләшкәй», «Тургай» - Беренче номерлы Биектау урта мәктәбе”.

Алдагы уку елында балалар бакчасы белән дәвамчанлыкка аерым игътибар бирү кирәк.

Биектау районы Башкортстан Республикасының Куергазы районы, Тамбов өлкәсе, Марий Эл Республикасының Бәрәңге районы, Киров өлкәсенең Нократ Аланы районы белән хезмәттәшлек итә. Марий Эл Республикасының Бәрәңге районы мәгариф бүлеге һәм Биектау районы мәгариф бүлекләре; Бәрәңге урта мәктәбе һәм Ямаширмә урта мәктәпләре арасында хезмәттәшлеккә кул куелды. Район укытучылары август аенда Бәрәңге урта мәктәбендә педагогик тәҗрибә уртаклашу максатыннан мастер-класслар үткәрделәр. Район делегациясе Марий Элда үткәрелгән

татар мәгарифе көннәрендә дә актив катнашты. Киров өлкәсе белән тыгыз элемтә урнаштырылды. Октябрь аенда район делегациясе Түбән һәм Урта Шөн авылларында үткәрелгән Рафаэль Сибатка багышланган кичәдә булды. Башкортстан һәм Тамбов өлкәләре белән интернет элемтәдә торабыз.

Үсеп килүче буынга татар халкының мәдәниятен һәм гореф –гадәтләрен өйрәтүгә аерым игътибар бирелә. Белем бирү оешмаларында үткәрелә торган “Нәүрүз”, “Каз өмәсе”, “Сабантуй” һәм башка фольклор бәйрәмнәр, “Татар кызы”, “Татар егете” бәйгеләре, театраль коллективларның чыгышы моның ачык мисалы. Ел саен районыбызда Туган тел айлыгы зурлап билгеләп үтелә. Зур оешканлык һәм аеруча җылылык белән Туган тел атналыклары үткәрелә. Һәр җирлекнең үзенә генә хас рухи байлыклары: үзенчәлекле тарихы, күренекле кешеләре бар. Якташыбыз Рафис Корбан исемендәге шигырь сөйләүчеләр бәйгесе, якташ язучыларыбыз, күренекле каләм әһелләре белән очрашулар еш үткәрелә.

Яңа уку елына түбәндәге төп мөһим юнәлешләрне билгелибез:

- балалар бакчасы һәм мәктәп арасындагы дәвамчанлыкны тәэмин итү;
- укытучыларга ел дәвамында үз белемеңне күтәрү, алдынгы тәҗрибәне уртаклашу өстендә эшләргә, татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен оештырыла торган семинар-практикумнарда, квалификация күтәрү курсларында булырга;
- укучыларның татар теле һәм әдәбияты буенча белем дәрәҗәләрен күтәрү, иҗади мөмкинлекләрен үстерү өстендә системалы эш алып барырга; рус телле укучыларның татар телендә мөмкин кадәр иркен аралаша алуына ирешергә;
- уку-укыту эшчәнлегендә инновацион технологияләрне, Сингапур укыту алымнарын югары дәрәҗәдә кулланырга;
- татар теленнән укучыларны бердәм республика тестына, төп дәүләт имтиханына, мониторинг тикшерү эшләренә әзерләүдә нәтиҗәле эш алымнарын кулланып эшләргә, уңай нәтиҗәләргә ирешергә.

***Юнысова Сәлимә Фәндүс кызы,***
***Биектау районы мәгариф бүлеге методисты***

## I БҮЛЕК. ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЫ ТАЛӘПЛӘРЕН ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТОРМЫШКА АШЫРУ

### Г. ТУКАЙНЫҢ "КЫЗЫКЛЫ ШӘКЕРТ" ШИГЫРЕНӘ ТЕХНОЛОГИК КАРТА ТӨЗҮ

*Вәлиуллина Сөмбел Мөхәммәт кызы,*
*Шәпше урта гомуми белем бирү мәктәбе*

Рәсәй һәм Татарстан фән һәм мәгариф министрлыгы бүгенге көндә укытучылардан Федераль дәүләт белем бирү стандартларына нигезләнеп эшләүне таләп итә. Әлеге стандарт белем бирү процессының эчтәлеген яңарту, аның нәтиҗәләрен югары сыйфатлы итү максатын күздә тота. Федераль дәүләт белем бирү стандарт таләпләре укытучының дәресләргә технологик карта төзүен дә таләп итә. Нәрсә соң ул технологик карта? Аны төзү ни өчен мөһим?

Технологик карта – җитештерелгән эшләнмәнең эшкәртелү процессын, составын, чималын, технологик режимын, коралларын, җитештерелү вакы-тын, җитештерүченең квалификациясен һ.б. тасвирлаган технологик документациянең бер формасы. Технологик карта Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләрен тормышка ашыруда аерылгысыз бер өлеш булып тора. Дәреснең технологик картасы – укытучы һәм укучы арасындагы үзара педагогик эшчәнлекне планлаштыра торган заманча бер форма. Шул рәвешле, дәреснең технологик картасы – дәреснең гомумиләштерелгән, график тасвирламалар ярдәмендә башкарылган сценариясе, дәресне проектлаштыруның нигезе, укытучының шәхси эш методлары белән таныштыру чарасы. Технологик карта ярдәмендә белем бирү укыту-тәрбия процессын нәтиҗәле итеп оештырырга, ФДББС таләпләре нигезендә предмет, метапредмет һәм шәхси осталыкларының үсешен тәэмин итәргә, укытучының дәрескә әзерләнү вакытын җитди дәрәҗәдә киметергә ярдәм итә.

Технологик карта укытучыга түбәндәге мөмкинлекләрне бирә:

•ФДББС нигезендәге планлаштырылган нәтиҗәләрне тормышка ашыру;
• конкрет теманы өйрәнү процессында формалашачак УУГ билгеләү;
• укучыларда эзлекле рәвештә УУГ формалаштыру;
• дәрес темасын үзләштерүне күздә тотып, максаттан алып ахыргы нәтиҗәләренә кадәр булган эшчәнлекнең эзлеклелеген проектлаштыру;
• билгеле дәрес этабында каралган төшенчәләргә төшенү дәрәҗәсен билгеләү;
• эшчәнлекне чиреккә, яртыеллыкка, уку елына проектлаштыру;
• иҗади эшчәнлеккә вакыт булдыру;
• предметара белемнәрнең тормышка ашу мөмкинлекләрен билгеләү;
• предметара бәйләнешне тудыру;
• укыту-тәрбия процессында катнашучыларның килешенгән гамәлләрен оештыру;
• планлаштырылган нәтиҗәләрнең гамәлдә ни дәрәҗәдә ирешелгәнлекләрен ачыклау һәм диагностика үткәрү;
• оештыру-методик мәсьәләләрне чишү;
• белем бирүнең сыйфатын арттыру.

Технологик карта мәктәп җитәкчелегенә программаның үтәлешен һәм көтелгән нәтиҗәләрнең ирешү дәрәҗәсен контрольдә тотарга, кирәкле методик ярдәм күрсәтергә ярдәм итә.

Игътибарыгызга "Г.Тукайның "Кызыклы шәкерт" шигырен өйрәнү"гә технологик карта тәкъдим ителә. Технологик карта рус мәктәпләренең рус төркемнәрендә белем алучы 4 нче сыйныф укучыларын күздә тотып төзелде. Теманың актуальлеге шунда: Тукай безгә гаять зур иҗат мирасы калдырды. Шул мирасta иң зур һәм әһәмиятле урынны шагыйрьнең балалар өчен язган әсәрләре алып тора. Аның әсәрләрендә бүгенге көннең күп сорауларына җавап табарга мөмкин.

Дәрес темасыннан чыгып, максат һәм бурычлар куелды.

**Максат:** укучыларны Г. Тукайның иҗат мирасы белән кызыксындыру, уку культурасын күтәрү.

**Бурычлар:**

- Балаларны Габдулла Тукайның иҗади эшчәнлеге һәм тормыш юлы белән таныштыру .
- Габдулла Тукайның әсәрләренә мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияләү.

• Габдулла Тукай иҗаты аша балаларда гомумкешелек, намуслык, тугрылык, кайгыртучанлык сыйфатларын тәрбияләү.

• Габдулла Тукайның шигырьләрендә һәм экиятләрендәге махсус сөйләм телен сиземләү һәм аңлауны тәрбияләү .

**Технологик карта**

| | |
|---|---|
| **Укытучы** | Вәлиуллина Сөмбел Мөхәммәт кызы |
| **Предмет** | Әдәби уку |
| **Сыйныф, төркем** | 4 нче сыйныф, рус |
| **Тема** | Г.Тукайның “Кызыклы шәкерт” шигырен өйрәнү |
| **Максат** | Г.Тукайның иҗаты белән кыскача таныштыру, “Кызыклы шәкерт” шигырен өйрәтү; Укучыларның тыңлап аңлау, логик фикерләү сәләтләрен, диалогик сөйләмнәрен үстерү; Укучыларга кечкенәдән эшчән, тырыш булып үсәргә кирәклекне аңлату; Г.Тукай шигыре аша хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү. |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:** Кечкенәдән тырыш булып, хезмәт яратып үсәргә кирәклекне аңлау;<br>**Метапредмет нәтиҗәләр:**<br>**Танып-белү УУГ:** тыңлап аңлау, аңлап уку, нәтиҗә чыгара һәм гомумиләштерүләр ясый белү;<br>**Коммуникатив УУГ:** диалог төзи белү, үз фикерен дөрес, ачык, төгәл итеп җиткерә белү;<br>**Предмет буенча:** Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүматлы булу, шигырьнең эчтәлеген белү. |
| **Дәреснең тибы** | Яңа белемнәрне үзләштерү дәресе |
| **Төп төшенчәләр** | Шәкерт, арт аяк, аума, юләр, маэмай |
| **Предметара бәйләнеш** | Рус теле, физик тәрбия |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, төркемнәрдә, парларда, индивидуаль |
| **Материал** | 4 нче сыйныф өчен дәреслек, Хәйдарова Р.З., 2 нче кисәк, 42 нче бит; укытучылар өчен методик кулланма; |
| **Җиһазлау** | Г.Тукай портреты, китаплар күргәзмәсе, Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты буенча презентация, ял минутына презентация, “Туган тел” җыры, “Кызыклы шәкерт” мультфильмы, “Татарча-русча” сүзлекләр, проектор, ноутбук |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
|---|---|---|---|
| **Оештыру Мотивлаштыру (1-2 мин)** | Исәнләшү. Дәрескә уңай психологик халәт тудыру:<br>- Исәнмесез, укучылар!<br>- Хәерле иртә, балалар!<br>- Имин үтсен көнегез!<br>- Кәефләрегез ничек соң?<br>Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк.<br>Кара-каршы партнёрыгыз белән сәлам бирешегез, янәшә партнёрларыгызның кулын кысып уңышлар теләгез.<br>Яхшы кәеф, яңа көч белән дәресебезне башлыйбыз.<br><br>(Г.Тукайның «Туган тел» җырын тыңлау, әңгәмә)<br><br>-Укучылар, бу җыр сезгә танышмы?<br><br>-Сүзләрен кем язган?<br><br>-Сезгә Г.Тукайның тагын кайсы шигырьләре таныш? | Укучылар төркем-нәрдә дүртәр кеше утыралар.<br>Исәнләшү. Дәрескә әзерлекне күрсәтү:<br>- Исәнмесез, саумысыз!<br>-Кояшлы иртә кебек. Тукай телен, татар телен<br>Өйрәнергә дип килдек.<br><br>Җырны тыңлау, сорауларга җавап бирү:<br>- Бу җырның исеме “Туган тел”.<br><br>- Сүзләрен Г.Тукай язган.<br>-“Безнең гаилә”, “Сабыйга” һ.б. | **ШУУГ**: Телне өйрәнүгә кызыксы-ну уяну;<br>**ТБУУГ**: Тыңлап аңлау, нәтиҗә чыгару;<br>**КУУГ:** диалогта катнашу, фикерләрне ачык һәм дөрес итеп җиткерә белү;<br>**РУУГ:** эшчәнлекне оештыра, җавапларны бәяли белү. |
| **Белемнәрне актуальләштерү** | **Өй эшен тикшерү**.<br>-Укучылар, үткән дәрестә без | Сорауларга җавап бирү. | **ШУУГ**- этләрнең кешенең иң якын дусты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Рөстәм Мингалимнең “Дөньяда бер эт бар иде” шигырен укыган идек. Хәзер шигырьне сәнгатьле итеп укып чыгарбыз.<br>- Укучылар, малай башта нишләде?<br>- Аннары нишләде? Шигырьдән шул юлларны табып укыгыз әле.<br><br>- Малай яхшы эшләдеме?<br>- Сез шигырь эчтәлеген ничек дәвам итәр идегез? | - Этне ярата иде, Аны ашата иде.<br>- Яратмый да баш-лады.<br>- Ашатмый да башлады.<br>- Юк, малай яхшы эшләмәде.<br>- Этне яңадан өйгә алып кайтыр идем.(һ.б.) | булуына төшенү, аларга карата мәрхәмәтле булырга кирәклек-не аңлау;<br>**ТБУУГ:**Тексттан кирәкле инфор-мацияне таба алу һәм нәтиҗә чыга-ру;<br>**КУУГ:** диалогта катнашу, фикерләр-не дәлилле итеп җиткерә белү;<br>**РУУГ:** җаваплар-ны дөресли һәм бәяли белү. |
| **Уку мәсьәләсен кую** | - Укучылар, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәкбез? | *Тема буенча фаразлар ясыйлар. Уку мәсьә-ләсен билгелиләр.*<br>-Минемчә, без этләр турында өйләшәчәкбез ... һ.б. | **РУУГ:** фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, планлаштыру. |
| **Уку мәсьәләсен адымлап чишү** | - Укучылар, бүген без, сез әйткәнчә, этләр турында сөйләшүне дәвам итәрбез. Бу турыда күп кенә язучы-шагыйрьләр язган. Шуларның берсе – татар халкының бөек шагыйре –Габдулла Тукай.<br>Сез Г.Тукай турында нәрсәләр беләсез? Белемнәрегезне ачыклау өчен, төркемнәрдә **кластер** төзеп алырбыз.<br>(Презентация буенча Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында өстәмә мәгълүмат бирү).<br>*Укучыларның аңлау дәрәҗәсен тикшерү:*<br>- Г.Тукай кем ул?<br>- Ул ничәнче елда, кайда туган? һ.б.<br>*Сүзлек эшен оештыру.*<br><br>-Укучылар, без бүген Г.Тукайның “Кызыклы шәкерт” шигырен укырбыз. Сезнеңчә бу шигырь нәрсә турында булыр? (Тәнкыйди фикерләү алымы)<br>Г.Тукайның “Кызыклы шәкерт” мультфильмын карау, беренчел тәэсирләрен сораштыру.<br>Г.Тукайның “Кызыклы шәкерт” шигырен уку.<br>Шигырьнең мәгънәсен үз сүзләре белән әйттерү.<br>- Шигырьдә автор нәрсәгә өнди?<br>- Ни өчен яшьләй тырышырга куша?<br>- Автор кайчан эш белү уңайсыз ди? | Укучылар төркем-нәрдә **кластер** төзиләр.<br><br>Г.Тукай турында презентация карау.<br><br>Яңа сүзләрнең мәгънәләрен татарча-русча сүзлекләрдән табу һәм үзләштерү: **шәкерт, арт аяк, аума, юләр, маэмай (фаразлар агачы** алымы белән җавап бирәләр)<br>- Минемчә, бу шигырь ...<br>Мультфильмны карыйлар, беренчел тәэсирләре белән уртаклашалар.<br><br>Шигырьне укыйлар, икенчел тәэсирләре белән уртаклашалар. Сорауларга җавап бирәләр. Авторның әйтергә теләгән фикеренә төшенәләр. | **ШУУГ**: тырыш булу төшенчәсен аңлау;<br>**ТБУУГ**: шигырьне күреп, тыңлап аңлау; нәтиҗә чыгару; шигырьдән төп фикерне аерып чыгару;<br>**КУУГ:** әңгәмәдә катнашу, фикерләрен ачык һәм дөрес итеп җиткерү;<br>**РУУГ:** сүзлек эшен оештыра белү, анализ барышын төзү, җавапларны бәяли белү;<br>**Предмет нәтиҗәләре:** Г.Тукай турында мәгълүматлы булу, “Кызыклы шәкерт” шигыренең эчтәлеген белү; шигырьнең идеясенә төшенә алу. |

| **Ял минуты** (Презентация – музыка астында татарча комментарий белән физик күнегүләр) | | | |
|---|---|---|---|
| **Яңа теманы ныгыту** (Яңа белемнәрне беренчел ныгыту) | *Әңгәмә үткәрү*:<br>- Сез мәктәптә физик тәрбия дәресендә нинди күнегүләр ясыйсыз?<br>- Өйдә нинди күнегүләр ясыйсыз?<br>- Физик күнегүләр ясау ни өчен кирәк?<br>*Диалог төзү:*<br>-Сыйныфташыгызның нинди физик күнегүләр ясавын ачыклагыз. Аннан шул турыда сорагыз һәм бергәләшеп парларда диалог төзегез. | *Әңгәмәдә катнашу, нәтиҗә чыгару*.“Физик күнегүләр ясау ни өчен кирәк?” дигән сорауга җавап бирү.<br><br>*Диалог төзиләр:*<br>- Андрей, син физик күнегүләр ясарга яратасыңмы?<br>- Әйе, мин физик күнегүләр ясарга яратам. Ә син, Лиза, физик күнегүләр ясарга яратасыңмы?<br>- Әйе, мин дә физик күнегүләр ясарга яратам.<br>- Андрей, син нинди физик күнегүләр ясыйсың? һ.б. | **ШУУГ:** Физик күнегүләр ясауга кызыксыну уяну;<br>**ТБУУГ:** нәтиҗә чыгару, гомумиләштерүләр ясау, төп фикергә төшенү;<br>**КУУГ:** әңгәмәдә катнашу, диалог төзи белү, фикерләрне ачык итеп әйтә белү, парларда эшли белү;<br>**РУУГ:** эшчәнлекне оештыра белү, җавапларга контроль ясый һәм бәяли белү. |
| **Өй эше** | Өй эше биремен аңлату:<br>*Репродуктив эшчәнлеккә:*<br>“Кызыклы шәкерт” шигырен, күзгегә карап, сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә;<br>*Конструктив эшчәнлеккә:*<br>Дәреслекнең 43 нче битендәге 4 нче күнегүдән рәсемнәргә туры килгән юлларны табып укый белергә;<br>*Иҗади эшчәнлеккә:*<br>Рәсемнәрдән файдаланып һәм текстны кат-кат укып, үз сүзләрең белән сөйләргә. | Өй эше биременең аңлашылып бетмәгән өлешләрен ачыклау. | **ТБУУГ:** биремне аңлау;<br>**РУУГ:** эшчәнлекне оештыра белү. |
| **Рефлексия, бәяләү, үзбәя** | Рефлексияне оештыра, һәр укучының максатка ирешү дәрәҗәсен билгели, укучыларның дәрестәге эшчәнлеген бәяли.<br>-Укучылар, без бүген дәрестә нәрсә эшләргә тиеш идек? (УМ искә төшерелә)<br>-Ничек эшләдек?<br><br>-Хәзер дәрестәге эшчәнлегегезгә үзбәя бирегез. (Үзбәя өчен критерий бирелә)<br>(Вакыт бирелә. Кемнәр үзен “5”легә бәяләде? Кемнәр “4”легә? дип, танып-белү | Сорауларга җаваплар бирәләр: әңгәмәдә катнашалар, үз эшчәнлекләрен бәялиләр.<br>-Г.Тукайның “Кызыклы шәкерт” шигырен өйрәнергә тиеш идек. (УМ чишү юллары искә төшерелә)<br>-Әсәрне карадык, аңлап укыдык, аңлашылмаган сүзләрне “Татарча-русча сүзлек”тән карадык, сорауларга җавап бирдек, диалоглар төзедек һ.б.<br>Укытучы биргән критерий буенча | **ШУУГ:** Кечкенәдән тырыш булып, хезмәт яратып үсәргә кирәклекне аңлау;<br>**КУУГ:** фикерләрне дәлилле итеп җиткерә белү;<br>**РУУГ:** үзбәя. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эшчәнлегенең сыйфаты ачыклана). | укучылар үз-үзләренә билге куялар. | |

Язманы йомгаклап, шуны әйтәсе килә: гади дәрес конспекты белән чагыштырганда, технологик карта ярдәмендә белем бирү укыту-тәрбия процессын нәтиҗәле итеп оештырырга, ФДББС таләпләре нигезендә предмет, метапредмет һәм шәхси осталыкларының үсешен тәэмин итәргә, укытучының дәрескә әзерләнү вакытын җитди дәрәҗәдә киметергә ярдәм итә. Дәрескә төзелгән технологик карта дәреснең һәр этабында көтелгән (планлаштырылган) нәтиҗәләрне игътибар үзәгенә куя. Уку-укыту эшчәнлеге төрләрен үзләштерү укучыларга яңа төр компетенцияләргә үзлектән ия булырга мөмкинлек бирә, төпле белем алырга өйрәтә. Уку-укыту эшчәнлеге төрләре универсаль (күпьяклы) дип йөртелә, чөнки алар шәхеснең гомуми, шәхси, танып-белү, үзлектән үсеш халәтен, төрле курслар, фәннәр арасындагы бәйләнешне тоемлавын, психологик мөмкинлеген, сәләтләренең үсешен дә күз уңаенда тота.

Технологик карта төзеп үткәрелгән дәресләр Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләрен тормышка ашырырга ярдәм итә. Укытучы укучыларда нәтиҗә күрә, ә татар теле укытуда иң югары нәтиҗә булып, укучыларны татарча аралашуга өйрәтү тора.

Бүгенге укучыларның гыйлем, яхшы тәрбия алырга тулы мөмкинлекләре бар. Безгә бары тик гыйлем алуга тырышлык, теләк һәм омтылыш тәрбияләргә кирәк. Безнең кулларда – балалар язмышы. Безнең укучыларыбыз бөтен яктан да үрнәк балалар булып үссеннәр һәм милләтебез горурланырлык шәхесләр булсыннар иде.

## РИВАЯТЬ ҺӘМ ЛЕГЕНДАЛАРНЫ ӨЙРӘНҮ ДӘРЕСЕНЕҢ ТЕХНОЛОГИК КАРТАСЫ

***Галиәхмәтова Чулпан Илсур кызы,***
***Ямаширмә гомуми урта белем бирү мәктәбе***

| | |
|---|---|
| Дәрес | Татар әдәбияты |
| Сыйныф | 5 |
| Дәрес төре | Кабатлау (белем һәм күнекмәләрне актуальләштерү дәресе) |
| Дәрес темасы | Риваять һәм легендаларны өйрәнүне йомгаклау |
| Максат | 1. “Кеше гомере ничек корылган?” легендасы белән танышу.<br>2. Халык авыз иҗаты әсәрләренә хас сыйфатларны барлау; легендаларны һәм риваятьләрне чагыштырырга өйрәнү; аермасын аңлату;<br>3. Укучыларда үткәннәргә ихтирам, халык авыз иҗатына кызыксыну тәрбияләү. |
| Төп төшенчәләр, аңлатмалар | Риваять, легенда |
| Эш формалары | Парлар һәм группалар белән эшләү, индивидуаль эш |
| Ресурслар | Ф.Ә.Ганиева, Л.Г.Сабирова төзегән татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен 5 сыйныфка әдәбияттан уку әсбабы, 2014.<br>Техник чаралар: компьютер,экран, проектор.<br>Power Point та презентация;<br>www. Бала.РФ. Интерактив мультимедия китапханәсе. “Койрыклар” мультфильмы. |

| **Ирешеләчәк нәтиҗә** | |
|---|---|
| **Предмет күнекмәләре**: “Кеше гомере ничек корылган?” легендасын рольләргә бүлеп уку, аңлау, истә калдыру . | **Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре (УУГ):**<br>- дөрес сөйләм булдыруга омтылыш;<br>- төркемнәрдә килешеп эшли белү;<br>- иптәшеңә рухи ярдәм күрсәтә белү;<br>- әдәп-әхлак нормаларын үзләштерү;<br>- камилләшергә әзер булу. |
| **Язу күнекмәләре**: тест эшләү, терминнарны язу, сүзлек өстендә эш, өй эшен язу. | **Регулятив УУГ:** максат кую һәм нәтиҗә ясый белү; фаразлау: булачак нәтиҗәләрне, аның күләмен, вакытын күзаллау. |
| **Уку күнекмәләре**: риваятьне рольләргә бүлеп уку, тиешле мисаллар, үз җавапларыңны уку | **Танып белү УУГ**: - үз фикереңне дәлилли һәм әйтә белү; куелган бурычларны чишү өчен, билгеле бер гамәлләр башкару. |
| **Тел күнекмәләре**: сорауларга җавап бирү, иптәшләреңнең җавапларын | **Коммуникатив УУГ:** башкаларны тыңлый, аңлый, әңгәмәгә кушыла белү; укытучы белән хезмәттәшлек итү. |

| | |
|---|---|
| тыңлап, үз фикереңне әйтү. | |

**Өйрәнү технологиясе**

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Слайдлар, күрсәтмәле лекләр** | **Формалаш-га тиешле универсаль уку гамәлләре УУГ** |
|---|---|---|---|---|
| Оештыру (1 минут) | Укучылар белән исәнләшү, үзең белән таныштыру | Укытучы белән исәнләшү | | Укуга уңай мөнәсәбәт булдыру |
| Өй эше тикшерү (4 минут) | 1.Укучылар, сез узган дәресләрдә риваятьләр һәм легендалар белән таныштыгыз. Хәзер сезнең белемнәрне тикшерү максатыннан тест биремнәре үтәп алабыз.<br>2. Хәзер яныгыздагы иптәшегез белән дәфтәрегезне алышыгыз һәм дөрес җавапларны карап бәяләгез. | 1. Укучылар слайдтагы тест биремнәрен әдәбият дәфтәренә эшлиләр.<br>2. Эшләп бетергәч, яңа слайдтан дөрес җавапларны карап, бер-берсенә бәя куялар. Хатасыз эшкә “5”, 1-2 хатага - “4”, 3-4 хатага - “3”. | 1 слайд (тест биремнәре)<br><br>2 слайд (дөрес җаваплар һәм бәяләү критерийлар ы) | Тест биремнәрен үтәү күнекмәләрен үстерү, башкаларга бәя куярга өйрәнү. |
| Дәрескә максат һәм бурычлар кую (10минут) | Хәзер, балалар, мин сезгә ике мультфильм карарга тәкъдим итәм.(8 минут)<br>- Укучылар, беренче мультфильм нинди халык авыз иҗаты әсәренә карый?<br><br>- Сез әлеге мультфильмга охшаш риваять укыдыгызмы?<br>- Икенче мультфильм нинди халык авыз иҗаты әсәренә карый?<br>- Шул легендага охшаш нинди әкият бар? Аның авторын беләсезме?<br>- Безнең бүгенге дәресебез белән бу мультфильмнар арасында нинди бәйләнеш бар?<br>- Сез инде бик күп легендалар һәм риваятьләр белән таныштыгыз. Бүген без аларны өйрәнүне йомгаклыйбыз. | Укучылар “Стрела наследия” һәм “Койрыклар” мульт-фильмнарын карыйлар. Укытучының сорау-ларына җавап бирәләр:<br>- Беренче Мультфильмда Болгар шәһәрен басып алу һәм Янмый торган кыз турында риваять күрсәтелде.<br>- Әйе, без “Янмый торган кыз” турында риваять укыдык.<br>- Икенче мультфильм хайваннарның кой-рыклы булуы турында легендага нигезләнгән.<br>- А.Алишның “Койрыклар” әкияте бар.<br>- Димәк, без бүген риваятьләрне һәм легендаларны өйрәнәбез, чагыштырабыз. | Интернет ресурс (мультфильм )<br><br>3 слайд (Риваять һәм легендалар-ның охшаш һәм аермалы яклары) | Төрле информацион ресурслардан файдаланырга өйрәнү.<br><br>Әдәби әсәргә шәхси мөнәсәбәт һәм бәя булдыру<br><br>Дәрескә максат һәм бурычлар куярга өйрәнү, прогнозлау. |
| Белемнәрне актуальләште рү (12 минут) | - Хәзер, укучылар, “Кеше гомере ничек корылган?” легендасына тукталыйк әле. Рольләргә бүленеп укыйбыз. (Автор, Ат, Эт, Маймыл, Песи)<br>- Укучылар, легенда нәрсә турында?<br>- Кешегә нинди хайваннарның гомерләрен биргәннәр?<br>- Әсәр кызыкмы, | Укучылар рольләргә бүленеп укыйлар.<br><br>-Кешенең ничә яшькә кадәр җитүе турында.<br>- Ат, Эт, Маймыл, Песи.<br><br>-Кызык | 4 слайд (“Кеше гомере ничек корылган?” легендасы) | Укучының телдән җавап бирү күнекмәсен, логик фикерләвен активлаштыру. Юмор алымнарын таба белү. Әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, риваятьләрнең һәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Физкультмин утка (3 минут) | кызганычмы?<br>- Кайсы урыннары елмаерга мәҗбүр итә? Укып күрсәтегез.<br>- Бу легенданы кемнәр уйлап тапкан?<br>- Авторы билгелеме?<br>- Димәк, аларны халык иҗат иткән. Риваять тә, легенда да халык авыз иҗаты әсәре икән.<br>- Легендалар күбесенчә нәрсә турында икән?<br>- Әйе, бик дөрес, дәфтәрләрне ачыгыз. Теманы языгыз. Беренче баганага легенда турында язып куегыз.<br>- Ничә яшькә җитсә дә, Кеше нинди булырга тиеш?<br>- Укучылар, “Кеше гомере ничек корылган?” легендасындагы хайваннарны искә төшерик әле. (Музыка). Минем сорауларга җавапны хәрәкәтләр белән аңлатасыз.<br>- Ат чаба. Ат кешни.<br>- Эт ничек өрә? Эт койрыгын эзли. Койрыгы артыннан куа.<br>Маймыл сикерә. Маймыл банан ашый. Маймыл агачка үрмәли.<br>- Песи битен юа. Песи мырлый, мияулый. Киерелә. | Укучы легенданың кызыклы дип тапкан өлешен укый.( ахырын)<br>-Кешеләр, халык.<br>-Юк.<br><br>-Борынгы ышанулар, йолалар, табигатьнең төрле күренешләре, хайваннар турында. Укучылар дәфтәрдә язалар.<br>- Акыллы. Тәртипле. Ярдәмчел.<br><br>- Ничә яшькә җитсәк тә, безгә һәрвакыт яхшы сыйфатларны югалтмыйча, Кеше булып калырга кирәк. Укучылар төрле хайваннар булып күрсәтәләр.<br><br>Укучылар ат, эт, песи авазларын чыгаралар, хәрәкәтләр белән аңлаталар. | | легендаларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү.<br><br>Укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашырга, башкаларның фикерен исәпкә алып, үз карашларыңны дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.<br><br>Укучыда мөстәкыйль эш күнекмәләре булдыру |
| Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану<br>(10 минут) | -Укучылар, мин сезгә Биектау атамасы белән бәйле риваять сөйлим.<br>Хәзер дәфтәрләрегезгә риваятьләргә хас билгеләрне языгыз. Дәреслекнең 57 нче битеннән файдалансагыз була.<br>- Җавапларыгызны укып күрсәтегез инде.<br><br>- Димәк риваять белән легенданың аермасы нидә?<br>- Бик дөрес җавап бирдегез.<br>-Риваять, легендаларда халык нинди сыйфатлар, эш-гамәлләрне хуплый?<br>- Риваять, легендалар халык тормышы, тарихы белән аерылгысыз икән. | Укучылар укытучыны игътибар белән тыңлыйлар, аңлатманы дәфтәрләренә язып алалар.<br>- Риваятьләр тарихи чынбарлыкка нигезләнгәннәр. Төрле чорларга караган, тарихи шәхесләрне гәүдәләндергән, авыл тарихына, исемнәргә, яшәү мөнәсәбәтләрен сурәтлиләр.<br>- Риваятьләр тарих, тарихи шәхесләр турында, ә легендалар ышанулар, йолалар, дини күзаллаулар белән бәйле хәлләр турында.<br>- Батырлык, тырышлык, гаделлек, | 5 слайд (риваять, легенданың кагыйдәсе)<br><br>6 слайд (риваять, легенда жанрының үзенчәлеге) | Төрле чыганаклардан (уку әсбабыннан, әдәбият белеме сүзлегеннән) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерер лек мәгълүматлар табарга өйрәнү.<br><br>Баланың әдәби текстны, кагыйдәне, әсәрнең үзенчәлекләрен аңлап бәяли белүенә ирешү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Бу жанрларның үзенчәлеге дә шунда. | ярдәмчелек, хәйлә белән эш йөртү. | | |
| Өйгә эш бирү (8 минут) | Балалар, “Татар халык легендалары һәм риваятьләре” китабыннан яки интернеттан файдаланып, кызлар легенда, ә малайлар риваять укып килсенннәр. | Укучылар биремнәрне дәфтәргә язалар. | | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү |
| Рефлексия (2 минут) | - Бүгенге дәрестә сөйләшкәннәр киләчәк тормышыгызда кирәк булырмы?<br>- Дәрестә сөйләгәннәрдән чыгып, нинди нәтиҗә ясыйбыз?<br><br>Мин сезгә Серле сандык алып килдем. Тактадагы мәкальне дәвам итсәгез, сандык ачылыр. | - Без буген риваятьләр һәм легендаларның аермалы якларын билгеләдек, кагыйдәләрен яздык. Без киләчәктә дә халкыбызның үткәнен онытмаска тиешбез. Халык авыз иҗаты белән танышуны дәвам итәчәкбез.<br>- Халык әйтсә, ( хак әйтә) | | Гомуми нәтиҗә, тапкыр җавап бирү күнекмәләрен үстерү |

**Үзанализ.** 5 нче сыйныф әдәбияты курсында легенда һәм риваятьләрне өйрәнүгә 6 сәгать вакыт бирелә. Безнең бүгенге дәрес аларны өйрәнүне йомгаклау дәресе булды. Максатлары: “Кеше гомере ничек корылган?” легендасы белән танышу; легендаларны һәм риваятьләрне чагыштырырга өйрәнү; аермасын аңлату; Укучыларда үткәннәргә ихтирам, халык авыз иҗатына кызыксыну тәрбияләү. Укучылар легенда һәм риваятьләрне уңышлы аера беләләр, аларга хас үзенчәлекләрне билгеләделәр. Дәрестә русча һәм татарча мультфильм карау, тарихи риваятьләрне өйрәнү, хайваннарга хас билгеләрне күрсәтү предметара бәйләнешне тәшкил итә. Тарих, рус теле, биология фәннәре белән бәйли.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**нә килгәндә,

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре** (УУГ):

- дөрес сөйләм булдыруга омтылыш; - килешеп эшли белү; - иптәшенә ярдәм күрсәтә белү; - әдәп-әхлак нормаларын үзләштерү; - камилләшергә әзер булу.

**Регулятив УУГ**: максат кую һәм нәтиҗә ясый белү; фаразлау: булачак нәтиҗәләрне, аның күләмен күзаллау.

**Танып белү УУГ**: үз фикереңне дәлилли һәм әйтә белү; куелган бурычларны чишү өчен, билгеле бер гамәлләр башкару.

**Коммуникатив УУГ**: башкаларны тыңлый, аңлый, әңгәмәгә кушыла белү; укытучы белән хезмәттәшлек итү.

Яңа белем стандартлары нигезендә эшләгәндә үзбәя кую мөһим. Укучылар тест биремнәрен дә, бер-берсен бәяләүне дә тиз башкардылар. Дәрестә уңай психологик атмосфера хөкем сөрде..

## ЭНДӘШ СҮЗЛӘРНЕ КАБАТЛАУ

*Галиәхмәтова Резидә Илгиз кызы,*
*Беренче номерлы Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе*

1. ***Дәреснең максатлары:***

1) фәнни максат: эндәш сүзләр турында алган белемнәрне тирәнәйтү һәм гомумиләштерү, рус теле белән чагыштырма анализ ясый белү;

2) коммуникатив максат: укучыларның сөйләм байлыгын үстерү, парларда, төркемнәрдә һәм командаларда эшләргә өйрәтү, тәрҗемә күнекмәләре формалаштыру;

3) тәрбияви максат: тел матурлыгы кешенең иң зур байлыкларының берсе икәнлеген аңлату, туган як, аның күренекле шәхесләре белән горурлану хисләре тәрбияләү.

***II. Бурычлары:***

1) синтаксик анализ ясау күнекмәләрен ныгыту;

2) эндәш сүзләрне аера белү күнекмәләрен формалаштыру;

3) эндәш сүзләр янында тыныш билгеләре куярга өйрәтү;

4) эндәш сүзне тиңдәш кисәкләрдән һәм аныклагычтан аерырга өйрәтү;

4) телебезнең матурлыгын, байлыгын тоярга өйрәтү;

5) татар теленнән рус теленә, рус теленнән татар теленә эндәш сүзләрне мәгънәсен саклаган хәлдә тәрҗемә итәргә өйрәтү.

***III. Принциплары:***

1) дидактик: фәннилек, күрсәтмәлелек, аңлаешлылык, тормыш белән бәйләнеш;

2) лингвистик: функциональ;

3) гомумметодик: коммуникатив, чагыштырып анализлау, гомумиләштерү, модельләштерү;

***IV. Эшне оештыру төрләре***: уку мәсьәләсен чишү, фронталь, индивидуаль, төркемнәрдә эш, проектлаштыру, фәнни-эзләнү, предметара бәйләнешләр, информацион технологияләрдән файдалану, грамматиканы янәшә куеп, чагыштырма өйрәнү һ.б.

***V. Планлаштырылган нәтиҗәләр***: модаль җөмлә кисәге буларак эндәш сүзләрне таный һәм куллана белү.

***VI. Дәреснең тибы***: белем һәм күнекмәләрне актуальләштерү, интегральләшкән дәрес.

***VII. Төп төшенчәләр***: җөмлә кисәге, җөмләнең модаль кисәге, эндәш сүз, синтаксик анализ.

***VIII. Предметара бәйләнеш***: рус теле, татар әдәбияты, рус әдәбияты

***IX. Җиһазлау:*** тематик презентация, карточкалар, терәк схемалар, таблицалар.

***X. Чыганаклар***: төп: дәреслек; өстәмә: слайдлар, карточкалар, компьютерлар, сүзлекләр.

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре. (УУГ) |
|---|---|---|---|
| Оештыру, мотивлаштыру | **Татар теле укытучысы:**<br>Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.<br>Мин иртә белән<br>Сыйныфка керәм,<br>Укучыларымның<br>Хәлләрен беләм:<br>Исәнмесез, Диана һәм Айсылу!<br>Исәнме, Адель!<br>Исәнме, Динә!<br>Исәнме, Әдилә !<br>Хәлләрегез ничек?<br>Данияр һәм Чулпан!<br>Сезгә, дусларым,<br>Иртәнге сәлам!<br>Исәнме, Алмаз!<br>Саумы, Илфат!<br>Авырмыйсызмы?<br>Алинә һәм Илшат!<br>Исәнме, Камилла!<br>Сәлам, Әдилә!<br>Бәхетле иртә!<br>Сиңа, Әдилә,<br>Хәерле иртә!<br><br>**Рус теле укытучысы:**<br>Здравствуйте!<br>Укучылар, ә хәзер әйдәгез, дөньяның төрле телләрендә бер-берегезне сәламләгез әле.<br>Притча. Рус теле укытучысы: Давным–давно в одном городе жил очень мудрый человек. К нему часто приходили люди за советом. Каждому из них он умудрялся | Хәерле көн, укытучыбыз!<br><br>Добрый день, Гулюса Ирековна!<br><br>башкортча- “ Хаумыгыгыз!»<br>чувашча – «Аван-и!»<br>марича - “Салам лийже!»<br>удмуртча - “Джечь буречь!» | К. Сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген формалаштыруда хезмәттәшлек итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | дать очень хороший и правильный совет. Слава о его мудрости разнеслась повсюду.<br>Однажды его слова дошли до еще одного человека, который тоже был мудрым и известным в округе. Этот человек тоже помогал другим людям. Ему нравилось то, что его считают самым мудрым и прислушиваются к его советам. И когда он узнал, что есть еще один мудрец, то стал злиться на него за то, что теряет свою известность. И он стал думать, как доказать другим людям, что на самом деле более мудрым является он.<br>Долго он думал и решил: «Я возьму бабочку, спрячу ее между ладоней, подойду на глазах у всех к мудрецу и спрошу его: «Скажи, о мудрейший, какая бабочка в моих руках, живая или мертвая? » И если он скажет, что бабочка живая, тогда я легонько сожму ладони так, что когда я их раскрою, то все увидят, что она мертвая. А если он скажет, что бабочка мертвая, тогда я отпущу ее, и она полетит. И тогда все увидят, что он оказался не прав» . Так он и сделал. Пошёл ранним утром на луг, поймал красивую бабочку, принёс к мудрецу и спросил его:<br>- Скажи, о мудрейший, какая бабочка у меня в руках, живая или мертвая?<br>Тогда мудрец, который действительно был очень мудрым человеком, посмотрел ему в глаза, подумал и сказал:<br>- Все в твоих руках.<br>Укытучы: Укучылар, барысы да сезнең кулларда. Бүгенге дәрестә белемне сез үз кулларыгыз һәм башыгыз белән үзегез табарсыз. | әзербайҗанча - “Салам алейкум!»<br>төрекчә - “Мәрхаба!»<br>инглизчә - “Хеллоу!»<br>немецча - «Гутн так!»<br>французча – «Бонжур»<br>ивритта – «Шалом!»<br>грузинча – «Гомар Джоба!»<br>кытайча – «Нихао!»<br>белорусча - «Дзень добры!»<br>итальянча - «Салюти!» | |
| Өй эшен тикшерү | Җавапларны тыңлау, бәяләү. | 1 нче төркем укучылар 294 нче күнегү. (Тыныш билгеләрен дөрес итеп куеп, күчереп язарга)<br>2 нче төркем | Ш: үз уңышларыңның (уңышсызлыкларыңның ) сәбәпләре хакында фикер йөртү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | укучыларга “Минем чынбарлыктагы һәм хыялымдагы сыйныфым” исемле хикәя төзергә.<br>3 нче төркем.<br>Эндәш сүзләр темасы буенча презентация - кагыйдә эшләргә. | |
| Проблемалы ситуация булдыру.<br>Уку мәсьәләсен кую | *Бирем./Задача*<br>**Рус теле укытучысы:**<br>- Выполните задания на карточке. Прочитайте предложения, расставьте знаки препинания, выполните синтаксический разбор. Скажите, сколько учеников успешно сдали экзамен?<br><br>*Данияр Адиля и Диана успешно сдав экзамены вошли в список лучших учеников школы!*<br>Рус теле укытучысы.<br>- Давайте выведем тему урока.<br><br>- Укучылар, дәрес башында мин нәрсә эшләдем?<br>- Ничек итеп сәламләдем?<br>- Ә нәрсә соң ул эндәш сүзләр?<br>- Без бу теманы өйрәндекме.?<br>- Ә рус теленнән өйрәндегезме? | *Ожидаемый ответ*:<br>- Данияр, Адиля и Диана, успешно сдав экзамены, вошли в список лучших учеников школы!<br>2 ученика - Адиля , Диана успешно сдали экзамен. В предложении слово Данияр –обращение. Адиля и Диана – однородные подлежащие.<br><br><br>*Көтелгән җавап*:<br>- Безне сәламләдегез.<br>- Һәрберебезгә исемнәребез белән эндәштегез.<br>- Эндәш сүзләр сөйләм төбәп әйтелгән затлар, әйберләр. Ул җөмләнең модаль кисәге.<br>- Без бу теманы өйрәндек.<br>- Өйрәнәбез. | Т: төп билгеләрне аерып алу нигезендә теманы формалаштыру. |
| Дәрескә максат һәм бурычлар кую.<br>Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру | Дәреснең темасын һәм максатын хәбәр итү.<br>- Без сезнең белән җөмлә кисәкләрен кабатлыйбыз. Бүген кайсы кисәкне кабатларбыз?<br>Үз алдыбызга максатлар куйыйк. | Көтелгән җавап:<br>- Эндәш сүзләрне.<br>- Кагыйдәләрне искә төшерәбез; күнегүләр эшлибез, тәрҗемә итәбез, проект эше башкарабыз, компьютерларда эшлибез. | К: мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү.<br>Т: яңа белемнәр табу, үзеңнең белем системасында ориентлаша белү. |
| Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру | - Укучылар, без сезнең белән мөстәкыйль эш башкарырбыз. Хәзер сез 3 төрле эш башкарачаксыз. 1 номерлы укучылар бирелгән шигырьләрне рус теленнән татар теленә, 2 номерлы укучылар, киресенчә, татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәсез. | <u>*1 нче бирем.*</u><br>Укучылар төркемнәрдә эш башкаралар: 1 нче укучы шигырьне рус теленнән татар теленә, 2 нче укучы татар теленнән рус теленә тәрҗемә итә.<br>*Көтелгән җавап:* | К: сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда күршең белән хезмәттәшлек итү. Индивидуаль, коллектив фикер алышуда катнашу. Башкаларның фикерләрен аңлавы, үз фикерләрен башкаларга |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Тәрҗемә эшендә нәрсә-ләргә игътибар итәргә кирәк?<br><br>- Сезгә 5 минут вакыт бирелә. Сүзлекләр алдыгызда. Карточкалар белән эшләүчеләр, сез җавапларны карточкага беркетелгән җавап таблицасына тутырасыз. Эшне башкару өчен 5 минут вакыт бирелә. | - Эндәш сүзләргә, инверсия күренешенә, рифмаларга, татар һәм рус телләрендә баш кисәкләрнең урынына.<br>3-5 укучылар бирелгән җөмләләрдә эндәш сүзләрне билгели һәм эндәш сүз янындагы тыныш билгесенең номерын язып куя.<br>Тәрҗемәләр укытыла, үзбәя куела.<br>Слайдтан карап, эшләрен тикшерәләр һәм үзбәя куялар. | җиткерә алулары. Үзбәя куя белү.<br>Р: кагыйдә-күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу. |
| | - Сезгә бирелгән текстларның авторларын карагыз һәм укыгыз әле. Ничек уйлыйсыз, нигә бу авторларның әсәрләреннән җөмләләр алынды икән, аларны нәрсә берләштерә?<br>- Әйдәгез, алар турында берничә сүз әйтеп китик. | - Рафис Корбан, Альберт Хәсәнов, Ләлә Сабирова-Гыймадиева, Боратынский әсәрләреннән мисаллар китерелгән. Быел бу авторларның юбилейлы туган көннәре. Татар әдипләре барысы да безнең районда туганнар, ә Е.А.Боратынскийның Каймар авылында усадьбасы булган. Укучылар Рафис Корбан, Е.А. Боратынский, Ләлә Сабирова турында сөйлиләр. | Р. Эзлекле һәм дөрес итеп сөйли белү. |
| | - Укучылар, эндәш сүзләрдәге тагын бер катлаулы очрак белән танышыйк әле. Карточкаларны алыгыз һәм бирелгән текстны укыгыз. Сүз нәрсә турында бара? Җөмләләрне тикшерик әле. Эндәш сүзләрне, җөмләнең баш кисәкләрен әйтегез.<br><br>- Укучылар, җөмлә кисәкләрен билгеләүдә, бигрәк тә модаль кисәкләрне, 1 нче һәм 4 нче җөмләләр сездә авырлык тудырамы?<br>- Укучылар, икенче, өченче | _2 нче бирем._<br>*1.Биектавым, син күпме ул һәм кызларыңны дәһшәтле сугышка озаттың. 2.Син, районым, армый-талмый фронтны икмәк белән туендырып тордың. 3.Сез, батыр якташларым, җиңеп чыктыгыз! 4. Мин синең белән горурланам, Биектау!* _Көтелгән җавап:_ | К: мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү.<br>Т: яңа белемнәр табу, үзеңнең белем системасында ориентлаша белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җөмләләрдәге *районым, батыр якташларым* сүзләре эндәш сүзгә дә, аныклагычка да охшаган. Әйдәгез, ачыклап карыйк әле, нинди җөмлә кисәге икән соң алар? Башта аныклагыч билгеләрен табыйк.<br>- Хәзер инде эндәш сүзгә хас билгеләрне табыйк.<br><br>- Дөрес, интонациягә дә игътибар итик әле. Башта бу җөмләләрне аныклау интонациясе белән, аннан эндәшү, мөрәҗәгать итү интонациясе белән укып карыйк<br>- Хәзер алмашлыклар белән исемнең урынын алмаштырып карыйк.<br><br>*<u>Нәтиҗә ясау</u>*. Җөмләнең иясе 2 нче зат берлек я күплек сандагы алмашлыклар белән белдерелгәндә, аннан соң килгән баш килештәге исемнәр эндәш сүз була. | - Юк, монда Биектавым, Биектау сүзләре - эндәш сүзләр.<br>*<u>Көтелгән җавап</u>:*<br>- Исем алмашлык белән бирелгән ияне аныклый кебек, үзе аныклап килгән сүздән соң урнашкан.<br>*<u>Көтелгән җавап:</u>*<br>- Бу җөмләләрдә әлеге сүзләр сөйләм төбәлгән затны белдерә.<br>*<u>Көтелгән җавап</u>:*<br>- Аныклау интонациясе белән укып булмый, мәгънә югала.<br><br>*<u>Көтелгән җавап</u>*:<br>- Бу очракта аныклагычка охшашлык бөтенләй бетә. | |
| | - Ребята, есть в русском языке такой интересный случай. Прочитайте, пожалуйста, предложения и обратите внимание на обращения.<br>Есть ли такая форма обращения в татарском языке?<br><br>**Зва́тельный падеж** - особая форма имени (чаще всего существительного), используемая для иденти-фикации объекта, к которому ведётся **обращение.** Название этой формы «падежом» условно, так как в строго грамматическом смысле звательная форма падежом не является.<br>В праславянском языке, а за ним древнерусском и старославянском звательный падеж образовывался следующим образом:<br>1)-*о* — после твёрдого согласного, -*е* — после мягкого: «жено!», «сестро!», «душе!», «дѣвице!»<br>2)-*е* — после твёрдого согласного, -*ю* — после мягкого: «старче!», «отче!», | *Мам, а мам, я в библиотеку пошёл. Оль, а ты пойдёшь на дополнительное занятие по русскому языку? Бабуль, мне нужна твоя помощь!*<br>*Ожидаемый ответ:*<br>- Использована сокращённая форма обращения.<br>- Нет, такая форма обращения не используется в татарском языке. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | «коню!», «Игорю!»<br>3)Древняя основа на *-*u*-:<br>-*у*: «мёду!», «сыну!»<br>4)Древняя основа на *-*i*-:<br>-*и*: «ночи!», «огни!», «Господи!»<br>В современном **русском языке** существует в виде нескольких архаизмов, по большей части входящих в состав фразеологических оборотов и других речевых формул, либо перешедшие в разряд междометий («бо́же», «созда́телю», «го́споди», «Иису́се», «Христе́», «влады́ко», «митрополи́те», «ста́рче», «о́тче», «сы́не», «бра́те», «дру́же», «кня́же», «челове́че» и другие).<br>Причём, в старозвательной форме употребляются не только имена собственные, но и неодушевленные имена нарицательные, такие как «стено́», «пра́вило», «о́бразе», «защи́то», «реко́», «трапе́зо», «похвало́», «сто́лпе», «лампа́до», «ка́мене», «ни́во», «мо́сте» и другие.<br>В то же время, иногда под «современным звательным падежом» (или«новозвательным») понимаются словоформы с нулевым окончанием существительных первого склонения, как «Миш», «Лен», «Тань», «Марин», «Танюш», «Ванюш», «бабуль», «мам», «пап» и т. п., то есть совпадающие по форме со склонением множественного числа родительного падежа. Статус данной формы слова пока остаётся предметом споров учёных: часть склоняется к выделению подобной формы в отдельную грамматическую категорию, часть же выступает против. | | |
| Динамик пауза (ял минуты) | | | |
| | - Укучылар, хәзер ике телдә дә эндәш сүзләргә караган охшаш һәм аермалы якларны билгеләгез.<br>Сезнең компьютерларыгызда таблица бирелгән. Шунда + һәм – куеп, эндәш сүзләрне ике телдә дә чагыштырыгыз. Күпме охшашлык, күпме | *Бирем3.*<br>Затка, предметка, күренешләргә төбәп әйтелгән сүзләр.<br>Модаль кисәк.<br>Җөмләнең башында, уртасында, ахырында килә ала.<br>Эндәш сүзләр янында | К: сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда күршең белән хезмәттәшлек итү.<br>Индивидуаль, коллектив фикер алышуда катнашу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | аерымлык таптыгыз, астагы юлга саннарны язып куегыз. | өтер һәм өндәү билгесе куела.<br>Җыйнак һәм җәенке була ала.<br>Тиңдәшләнеп килергә мөмкин.<br>Җөмләдә күпнокталар белән билгеләнә.<br>Эндәш сүзләр 4 төркемгә бүлеп карала. Кешеләргә эндәшү сүзләре дүрт төркемгә бүленә.<br>Эндәш сүзләр кыскартылма формада да кулланыла ала.<br>Эндәш сүзләр җөмләне матурлыйлар.<br>Эндәшү, мөрәҗәгать итү интонациясе белән әйтелә.<br>Эндәш сүзләр икенче зат белән бәйләнгән.<br>И, ай, әй, о ымлыклары эндәш сүзләр янында бер гомуми интонация белән әйтелсә, алар арасында өтер куелмый, башка ымлыклардан соң куела.<br>Эшләренә үзбәя куялар. | Башкаларның фикерләрен аңлавы, үз фикерләрен башкаларга җиткерә алулары. Үзбәя куя белү.<br>Р: кагыйдә-күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу. Төп билгеләрне аерып ала белү, кагыйдә формалаштыру. |
| Белемнәрне үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау | Эндәш сүзләр белән бәйле проект эшләре башкару. | *Бирем 4.*<br>1 нче төркем – кроссворд эшли;<br>2 нче төркем – балаларга яратып-иркәләп эндәшә торган сүзләр белән презентация эшли;<br>3 нче төркем - эндәш сүзләр темасына буклет эшли.<br>Эшләрне яклау, үзбәя кую. | К: коллективта эшли белү, мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. |
| Өй эше. | 298 нче күнегүнең өстәмә биремен аңлату | 1 төр эш. 298 нче күнегү. Күчереп язарга, синтаксик анализ ясарга.<br>2 төр эш. 298 нче күнегүне тәрҗемә итәргә.<br>3 нче төр эш. 298 нче күнегүнең биремен башкарырга. “Минем өемдәге “тере дустым”” темасына хикәя төзергә | Ш: үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау. |
| Рефлексия, үзбәя | Эшчәнлеккә нәтиҗә ясау. “Укучылар, бүгенге дәрескә бәя бирегез. Дәрес сезгә ошадымы? Нинди яңалык алдыгыз? Кайсы эш төрләре сезне күбрәк җәлеп итте? Белемнәрегезне ничек бәялисез? | Төрле телләрдә саубуллашалар<br>инглизчә - «Bye!», «GoodBye!»<br>белорусча – «Пакуль!», «Да спаткання!»<br>болгарча – «Чао!», «Довиждане!»<br>немецча – «Auf Wiedersehen!»<br>төрекчә - «Hoşçakal!»<br>французча - «Au revoir!»<br>итальянча – «Ciao!» | |

| | | |
|---|---|---|
| | Инде хушлашабыз. | үзбәкчә – «Хайер!»<br>чувашча – «Тепре куриччен!»<br>башкортча – «Һау булыгыз!»<br>марича – «Чеверын!»<br>удмуртча – «Зеч луэ!»<br>украинча – «До побачэння!»<br>кыргызча – «Дңакшы калынгыздар!»<br>казахча – «Сау болыңыз!» |

**Төркемнәрдә эшләү өчен бирелгән грамматик биремнәр**

**Биремле карточкалар№1**
**Карточки с заданием**

*Эндәш сүзләр янында куела торган тыныш билгеләре урынына куелган саннарны язып алыгыз.*

*Выпишите цифры, на месте которых должны быть знаки препинания при обращении (знаки препинания не расставлены).*

**1 нче группа**

1. Әнием(1)абыема компьютер алырга (2) акча бир әле(3). (Ләлә Гыймадиева)
2. (1)Кибеткә матур алмалар кайтарганнар икән(2) кызым(3) барып алырсың(4). (Ләлә Гыймадиева )
3. Син(1) балакай(2) нәрсәләр генә уйлап утыра торгансыңдыр(3)(4)диде(5). (Ләлә Гыймадиева)
4. Слыхал я (1) добрые (2) друзья (3)

Что наши прадеды в печали (4)
Бывало (5) беса призывали… (Е.А.Боратынский)

5. Люблю я (1) вас (2) богини пенья (3)

Но ваш чарующий наход (4)
Сей сладкий трепет вдохновенья (5)
Предтечей жизненных невзгод. (Е.А.Боратынский)

6. Когда твой голос (1) о поэт (2)

Смерть в высших звуках остановит (3)
Когда (4) тебя (5)во цвете лет (6)
Нетерпеливый рок уловит(7)
Кого закат могучих дней
Во глубине сердечной тронет? (Е.А.Боратынский)

**Биремле карточкалар №1**
**Карточки с заданием**

*Эндәш сүзләр янында куела торган тыныш билгеләре урынына куелган саннарны язып алыгыз*
*Выпишите цифры, на месте которых должны быть знаки препинания при обращении*
*(знаки препинания не расставлены).*

**2 нче группа**

1. Кәккүккәем(1) кәккүккәем(2) әйтче миңа(3) бик тә тырышып ясаган рәсемнәремә (4)укытучым(5) нинди билге куяр икән(6). (Альберт Хәсәнов)
2. Кайгырма(1) күгәрченкәем(2) мәче (3)тырнагыннан котылдың инде(4). (Альберт Хәсәнов)
3. Нәрсә(1) кылый(2) күз(3) әллә бал татып карыйсың киләме(4). (Альберт Хәсәнов)
4. Я возвращуся к вам (1)поля моих отцов (2)

Дубравы мирные (3) священный сердцу кров!
Я возвращуся (4) к вам (5) домашние иконы ! (Е.А.Боратынский)

5. Прощай (1) прощай (2) сияние небес!

Прощай(3) прощай (4) краса природы! (Е.А.Боратынский)

6. Шуми (1) шуми с крутой вершины (2)

Не умолкай (3) поток седой (4)
Соединяй протяжный вой(5)
С протяжным отзывом долины! (Е.А.Боратынский)

**Биремле карточкалар №1**
**Карточки с заданием**

*Эндәш сүзләр янында куела торган тыныш билгеләре урынына куелган саннарны язып алыгыз.*

*Выпишите цифры, на месте которых должны быть знаки препинания при обращении (знаки препинания не расставлены).*

**3 нче группа**

1. Керпе балаларын сыйдыра күр инде үзеңә(1) урман(2). (Альберт Хәсәнов)

2. Авылым(1) дип күпме шигырь яздым(2)
Исемеңне телгә алмадым(3)
Кичер мине (4)кичер(5) Битаманым(6)
Мин хатамны инде аңладым (7) ( Р . Корбан)

3. Дәвам итәр җирдә тормыш(1)
Кыш үтәр(2) килер язлар(3)
(4)Мин сөям сине(5) тормыш(6)(7)(8)дип
Шагыйрьләр шигырь язар(9). (Р.Корбан)

4. Поверь (1) мой милый друг (2) страданье нужно нам;
Не испытав его (3) нельзя понять и счастья:
Живой источник сладострастья
Дарован в нем его (4)сынам. (Е.А.Боратынский)

5. Ты ропщешь (1) важный журналист (2)
На наше модное маранье (3)
«Всё та же песня: ветра свист(4)
Листов (5) древесных увяданье...» (Е.А.Боратынский)

6. Что за звуки? Мимоходом (1)
Ты (2) поешь перед народом (3)
Старец нищий и слепой (4) (Е.А.Боратынский)

Тәрҗемә өчен шигырьләр:

Водопад
А.Е. Боратынский
Шуми, шуми с крутой вершины,
Не умолкай, поток седой!
Соединяй протяжный вой
Протяжным отзывом долины!

Сагыну җырлары
Р.Корбан
Йөрәк типми, ул да туктап калган.
Бу – күңелдә хисләр тулган чак.
И, гомернең илаһи бер мәле
Синдә икән бит ул, туган як.

Уен:
Рафис Корбан
И Кол Гали, Бөек Гали!
Ул нинди гөнаһ кылып,
Сигез гасыр гүрдә ятып,
Рухына юк тынгылык?!
Кичер безне, и Кол Гали?!
Ярлыка безне, Алла?!
Шул уенга кушылган без
Гөнаһлы Сезнең алда!

**Биремле карточка №2**

Бирелгән текстны укыгыз. Сүз нәрсә турында бара? Җөмләләргә синтаксик анализ ясагыз.

*1.Биектавым, син күпме ул һәм кызларыңны дәһшәтле сугышка озаттың. 2.Син, районым, армый-талмый фронтны икмәк белән туендырып тордың. 3.Сез, батыр якташларым, җиңеп чыктыгыз! 4. Мин синең белән горурланам, Биектау!*

Бирем №3

Чагыштырма анализ ясагыз, төркемнәрдә эшләгез (эш компьютерда башкарыла)

| | | Татар телендә + / - | Рус телендә + / - |
|---|---|---|---|
| 1. | Затка, предметка, күренешләргә төбәп әйтелгән сүзләр | | |
| 2. | Модаль кисәк | | |
| 3. | Җөмләнең башында, уртасында, ахырында килә ала | | |
| 4. | Эндәш сүзләр янында өтер һәм өндәү билгесе куела | | |
| 5. | Җыйнак һәм җәенке була ала | | |
| 6. | Тиңдәшләнеп килергә мөмкин | | |
| 7. | Җөмләдә күпнокталар белән билгеләнә | | |
| 8. | Эндәш сүзләр 4 төркемгә бүлеп карала | | |
| 9. | Кешеләргә эндәшү сүзләре дүрт төркемгә бүленә | | |
| 10. | Эндәш сүзләр кыскартылма формада да кулланыла ала | | |
| 11. | Эндәш сүзләр җөмләне матурлыйлар | | |
| 12. | Эндәшү, мөрәҗәгать итү интонациясе белән әйтелә | | |
| 13. | Эндәш сүзләр икенче зат белән бәйләнгән. | | |
| 14. | И, ай, әй, о ымлыклары эндәш сүзләр янында бер гомуми интонация белән әйтелсә, алар арасында өтер куелмый, башка ымлыклардан соң куела. | | |

## ЯҢА ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ДӘРЕСТӘН ТЫШ УКУ

***Низамиева Әлфинур Нуретдин кызы,***
***Айбаш урта гомуми белем мәктәбе***

Минем кулымда – татар мәктәпләре өчен чыккан яңа ”Әдәбият” дәреслекләре. Кулга алуга ук, күңелдә матур тойгылар уята. Бу китаплардан йомшаклык, затлылык, наз бөркелә төсле. Тышлыгы якты төсләр белән бизәлгән, форзац битләрендә бөекләрнең зирәк фикерләре бирелгән. Татар теле һәм әдәбиятын күп еллардан бирле укыткан укытучыга яңа дәреслекләрнең эчтәлеге бигрәк тә ошады. Алдагы елларда басылган дәреслекләрне дә яратып кулландым, ләкин яңа стандартларга җавап бирә торган заманча дәреслекләр белән, һич икеләнмичә, 2014-2015 нче уку елында ук укыта башладым. Дәреслекнең төзелеше дә, әдипләр турында бирелгән мәгълүматлар, бигрәк тә әдәбият теориясе, сүзлек, әсәр белән эшләү өчен кертелгән сораулар, төрле характердагы биремнәр искиткеч! 6 нчы сыйныфтан ук әдәби әсәрнең төзелеше һәм эчтәлегенә, ягъни композициясе, тема һәм проблема, идеяне ачыкларга өйрәтә башлау бик мөһим, кирәкле. Практик дәресләр өчен аерым сәгатьләр бирү күптән кирәк иде. Әдипләрне, аларның әсәрләрен чорына, темасы һәм жанрына карап бүлү дә бик отышлы.

Бу дәреслекләрне гамәлгә кертү турында “Мәгариф” журналы оештырган “Түгәрәк өстәл” дә төрле фикерләр әйтелде. Дәреслекләр авторы Ф.Ә.Ганиева, яңа стандартлар мәктәпне баштанаяк үзгәртмәде, дип саный. “Яңа федераль стандартлар мәктәптә ниндидер зур үзгәрешләр кертмәде. Төп яңалык белем эчтәлегенә кагыла. Элек әдәбият фәненнән белем бирү укып чыккан әсәрнең эчтәлеген истә калдырудан гыйбарәт иде, төп басым шуңа ясалды. Яңа стандарт нигезендә куелган таләп буенча, әдәбият белеме теориясе һәм әдәбият тарихы белән бергә үрелеп өйрәнелә, – ди ул. – Икенче яңалык исә – программаны укучының мөстәкыйль өйрәнүенә басым ясауда”. Ә программаны мөстәкыйль үзләштерүнең бер юлы – дәрестән тыш уку. Дөрес, бу эш әдәбият программасын теләсә ничек үзләштерергә мөмкинлек бирә, дип уйлау ялгыш булыр иде. Яңа программаларда дәрестән тыш укуга бик аз вакыт бирелә. Шуңа карамастан мин укучыларның дәрестән тыш китап укуларын даими барлап торам.

Дәреслекләрнең сыйныфтан сыйныфка эзлекле итеп эшләнүе бик уңышлы. Гадәттәгечә, уку елы башында язма әдәбиятның нигезен тәшкил иткән халык авыз иҗаты үрнәкләре өйрәнелә. Дәреслектә әсәрләр җитәрлек түгел, шуңа күрә мин дәрестән тыш та укырга кушам. Укучылар халык әдәбиятының байлыгына төшенәләр. Язучының иҗатын тирәнрәк белү өчен дә дәреслектә бирелгән бер әсәр генә (кыскартылган вариант) җитми. Әдәбиятны яраткан, әсәрләрне күп укучы дәреслек

белән генә чикләнми. Андый укучыларга мәктәп һәм авыл китапханәсендә китаплар җитәрлек, теләгәнен сайлап алу мөмкинлеге дә бар.

Яңа стандартларга нигезләнгән дәреслекләр 7 нче сыйныфтан башлап икешәр кисәктән торалар. Күптән шулай эшләргә кирәк булган, чөнки бик уңайлы. Яңа дәреслекләрдә моңа кадәр кермәгән авторлар һәм аларның әсәрләре кертелү дә – уңай күренеш. Шулай да, дәреслекләр ничек кенә әйбәт булмасын, әдәбиятны класстан тыш укудан башка өйрәнеп, өйрәтеп булмый. Укучыны әдәбият белән кызыксындыруның иң отышлы юлы да – дәрестән тыш уку белән гадәти әдәбият дәресләрен якынайтуда, бергә үреп алып баруда.

Милләтпәрвәр җитәкчеләребез, мәгариф хезмәткәрләре, китапның әһәмиятен аңлаучы чиновниклар мәктәп китапханәләрен “Мәктәп китапханәсе”, “Хәзинә” сериясендә басылган китаплар белән баетсалар, авыл китапханәләрен классик язучыларыбызның, халык язучысы, халык шагыйрьләренең томнары, “Сайланма әсәрләр”е, балалар энциклопедияләре белән баеттылар, яшь язучыларның да китаплары бер-бер артлы кайта башлады. Ә 2010 нчы елның май аенда Бөек Җиңүнең 65 еллыгы уңаеннан укучыларны зур бүләк белән сөендерделәр: мәктәп китапханәсенә 15 томнан торган (һәр томы берничә экземплярда) китаплар сериясе кайтты. “Хәтер уты” томында халыклар дуслыгы, батырлыгы казанышларын саклау идеяләре белән сугарылган әсәрләр басылса, “Сугыш турында фронтовиклар” томындагы әсәрләрнең геройлары – дошманга каршы батырларча көрәшкән реаль шәхесләр. “Драматургиядә утлы еллар авазы”, “Сугыш чоры балалар әдәбияты”, “Без кайтырбыз туган илләргә”, “Сугыш эзләре буйлап”, “Дәһшәтле чор балалары”, “Утлы еллар авазы”, “Давылларда сыгылмас гөлләр”, “Мәңгелек яшәү”, “Хатирәләр яңарганда”, “Каһарманлык юлы”, “Гарасатлы еллар”, “Сугыш корбаннары кайтавазы” дип аталган китапларда әсир сугышчылар язмышы, фронттагы, тылдагы вакыйгалар, сугыш вакытында татар хатын-кызларының фидакарьлекләре сурәтләнгән әсәрләр дә, очерклар, язмалар да тупланган. Г.Кутуйның “Рөстәм маҗаралары” хикәясе программадан төшеп калса да, мин бу китапны укырга бирәм. 8 нче сыйныфта “Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты”ннан Ф.Кәрим иҗатын өйрәнгәндә, 15 томлыкның фронтовик язучыга багышланган томын укырга тәкъдим итәм, чөнки дәрестән тыш укуны Ф.Кәрим поэмаларына, башка әсәрләренә багышлыйм.

Китап укыган баланың телдән сөйләме дә, язма эшләре дә матур, эзлекле килеп чыга, ә китап яратмаган укучы сүз эзләп кесәгә керә, теле дә, рухы да ярлы була. Менә шуңа күрә дә тел укытучысы үз фәненә, тел-әдәбиятка ихтирам, кызыксыну уятуны китаптан, бигрәк тә дәрестән тыш өстәмә әдәбият укытудан башларга тиеш. “Татар теленең дәрәҗәсен күтәрү, аны аралашу теле баскычыннан күпләр өчен әдәби, фәнни телгә әйләндерү, укучыларга халыкның рухи хәзинәләрен, милли сәнгатьнең матурлыгын, мәдәни байлыкны күрсәтеп, шуларга соклану, халкың белән горурлану хисләре тәрбияләү өчен иң туры, кыска юлларның берсе аның әдәбиятын уку, ярату, өйрәнү икәнлеге берәүдә дә шик уятмый”, – дип язды галимәбез дә. (Заһидуллина Д. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәш., 2004. – 367 б.).

Укучыга тәрбияви әһәмияткә ия булган китап тәкъдим итә белергә кирәк, компьютер, интернет заманында бигрәк тә. Ә татар әдәбиятында дөрес әхлак формалаштыруга, шәхес тәрбияләүгә багышланган әдәби әсәрләр бихисап. Мәсәлән, бу эшне мин 5 нче сыйныфтан башлыйм. Дәрестән тыш әкиятләр укыту, Г.Тукай, А.Алиш, Ф.Яруллинның балалар өчен төрле әкият, хикәяләрен тәкъдим итү отышлы. Т.Миңнуллинның “Авыл эте Акбай” пьесасының “Акбай һәм Кыш бабай”, “Акбай, Тәмлетамак һәм Этбүрләр”, “Акбай нигә күңелсез?” һ.б. кебек дәвамын балалар, яратып укыйлар.

5 нче сыйныф укучыларына дәрестән тыш уку дәфтәре башлату зур әһәмияткә ия, мин аларга дәфтәр тотышын аңлатам, үрнәк дәфтәрләр күрсәтәм. Бу эшне һәр класста искә төшереп тору, үрнәк дәфтәрләр күрсәтү бик файдалы. Бер укучым турында аерым әйтәсем килә. 5 нче сыйныфта укыганда ук аның “Дәрестән тыш уку” дәфтәре берничә булды. 7 нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң, шул укучым җәйге каникулда Н.Фәттахның “Әтил суы ака торур” романын үзе теләп укыды. Татар теленнән “4” ле белән “3” ле арасында барган Гөлия 8 нче сыйныфта “4” ле белән “5” легә күтәрелде. Аның өй эшләре дә бик иҗади, китаплардан файдаланып башкарыла.

Шулай ук “Мәктәп китапханәсе” сериясендә чыккан, мәктәп балалары өчен кыскартып бирелгән “Тукай” романы яки “Кечкенә Апуш” китабын 6 нчы сыйныфлар укый. Китап укучыларның телен баета, Г.Тукайга карата ихтирамны арттыра, укучыларда ихтыяр көче тәрбияли. Билгеле, фонохрестоматия, электрон ярдәмлекләрдән дә файдаланабыз. Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” хикәясен дә кайбер укучылар тулы вариантта укыйлар. Кайбер дәресләрне дәреслекләр белән түгел,

китапханәдән алган китаплар белән уздыру да бик мөһим. Укучылар дәрескә өстәмә әдәбият алып киләләр. Р.Мөхәммәдиевнең “Ак кыялар турында хыял” әсәрен укучылар 11 нче сыйныфка җиткәнче үк укыйлар. Урта сыйныф укучыларына Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” повестен, Н.Фәттахның “Итил суы ака торур” романын “Мәктәп китапханәсе” сериясендә басылган китаплардан укырга киңәш итәм. Г.Әпсәләмовның “Алтын йолдыз” әсәрен “Газинур” романы белән алыштырып укытам, чөнки “Газинур” романы балаларга җитәрлек тә һәм реаль шәхес турындагы документаль әсәр буларак та тәкъдим ителә. Р.Батулланың “Сөенбикә” романын көчлерәк укучыларга гына укырга мөмкинлекне әйтәм, ә Ф.Латыйфиның “Хыянәт” романын барлык укучыларга да бик теләп укытам. Кайвакыт әсәрләрне укучыларга бүлеп тә укытырга туры килә: я китап җитми, я укучылар вакыт ягыннан да сыеша алмаска мөмкин.

Сыйныфтан тыш уку дәресләре кечкенә классларда күбрәк әчтәлек белән танышу формасында уздырылса, зуррак сыйныфларда китап укучылар конференциясе яки башка формада үткәрелә. Укучыларга аннотация яки рецензия яздыру да отышлы.

11 нче сыйныфта экология темасына “Сакларга кирәк, юк, тагын да ныгытырга кирәк табигать белән дуслыкны” дигән темага ачык сыйныфтан тыш уку дәресе үткәрергә туры килде. Берничә укучы, билгеле, көчлерәкләре, Г.Бәшировның “Җидегән чишмә” романын укыды. Бер укучы И.Юзеевның “Гашыйклар тавы” на, икенчесе – А.Гыйләҗевнең “Хушыгыз, тургайлар” пьесасына, өченчесе – И.Юзеевның “Карурман” ына, дүртенчесе табигатьне саклауга багышланган шигырьләргә тукталды. Дәрескә ”Табигать һәм без” дигән әдәби бюллетень чыгарылды, “Карурман” поэмасыннан түбәндәге юллар язып эленде:

“Шәфкать көтми кеше табигатьтән,<br>
Теләгәнен ала көч белән.<br>
Ә ул, шомырт-кара күзен мөлдерәтеп,<br>
Рәхим-шәфкать көтә кешедән.”

“Татар әдәбиятында хатын-кыз мәсьәләсе” дигән темага үтәсе дәрескә берничә китап укырга кушам: Г.Исхакыйның “Көз” һәм “Татар кызы” повестьларын, Г.Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” ын, Г.Ахуновның “Хәзинә”, “Идел кызы”, Г.Бәшировның “Намус” романнарын һ.б. әсәрләрне. Әсәрләрдән өзекләрне слайдларга язып куярга була. Программада булмаган китапларны да тәкъдим итәргә туры килә, ләкин теләсә нindине түгел, ә бәлки укучыларга тәрбия бирә торганнарын гына. 8 нче сыйныф укучылары белән Ф.Латыйфиның “Хыянәт” романы буенча “Күпме михнәт чиккән безнең халык, күпме күз яшьләре түгелгән” темасына дәрес-конференция уздырырга яратам. (Яңа программа буенча бу әсәр 9 нчы сыйныфта укырга тәкъдим ителә.) Н.Фәттахның “Кичү” романын яки өзекләрен 8 нче, 10 нчы сыйныфта ук укырга киңәш итәм, чөнки 11 нче сыйныф укучысы, теләсә дә, укырга өлгерми бу әсәрләрне: аның имтиханнарга, ВПР га әзерләнәсе бар. 1960 нчы елларда язылып та, 30 ел буе басыла алмыйча яткан әсәрдә әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелә: Башкортстан республикасында татар теленең кысылуы, татар халкына карата мыскыллы караш, татар теле сагында торучы кыю кешеләрнең эш-гамәлләре һ.б. Соңгы елларда бу темага мөрәҗәгать итүче язучылар саны артты, билгеле. Мәсәлән, Г.Гыйльмановның “Бүреләр һәм Иоһанн Себастьян Бах” хикәясе буенча мин 7 нче сыйныф укучылары белән сыйныфтан тыш уку дәресе уздырам. Дәрестә хикәяне укыйбыз, фикер алышабыз, туган телнең әһәмиятенә төшенәбез.

“Татар әдәбиятында әниләр һәм бәбиләр проблемасы” темасына да семинар дәрес, дәрес-диспут үткәрергә мөмкин. Бу дәресне 9, 10 нчы сыйныфларда уздыру отышлы. Дәрескә әзерлек барышында Т.Миңнуллинның “Әниләр һәм бәбиләр” пьесасы, Г.Гыйльмановның “Китек ай” әсәре, М.Җәлилнең “Яшь ана” шигыре, А.Гыйләҗевнең “Җомга көн кич белән” повесте, Ф.Яруллинның “Кыйгак-кыйгак каз кычкыра” әсәре укыла, сораулар алдан бирелә, шулай итеп укучы балалар хәзерге заманның проблемасын хәл итүдә катнашалар. Дәрестә укучыларның чыгышлары, сәнгатьле укуы, эчтәлек сөйләү, сораулар һәм биремнәр белән эшләү киң кулланыла. Нинди форма сайланса да, максат бер – әсәрне тирәнтен аңларга өйрәнү, китапның әһәмиятенә төшенү, укучыга тәрбия бирү.

Китап – дөньяны танып белергә ярдәм итә торган ачкыч ул. Аңарда кешелек акылының океаны бар. Милли китап – халыкның көзгесе. Анда милләтнең меңләгән еллар дәверендә үткән тәҗрибәсе һәм уңышлары, ачыш һәм табышлары, хыял һәм өметләре, кайгы һәм хәсрәтләре – бөтен тарихы чагылыш тапкан. Шуңа күрә китапка игътибарны киметмик, киресенчә, арттырыйк. “Китабына хөрмәте булмаган халыкның киләчәге өметле булуына мин ышанмыйм. Китабына хөрмәте булмаган халыкның милли әдәбияты да озын гомерле була алмый. Китап – ул телнең дә сакчысы, китап язмышы халык язмышы белән аерылгысыз бәйләнгән. Китап халык хәтере дә. Хәтерен югалта баручы халык сарык көтүен хәтерләтә торган массага гына әйләнә бара. Татар китабына 270 ел тулган бу елда менә шушы икегә икене тапкырласаң да, кушсаң да дүрт була дигән кебек гап-гади нәрсәне укучының да, язучыларның да, галимнәрнең дә, һәр татар кешесенең дә исенә төшерәсе килә,” – дип язган академик Ә.Кәримуллин. Аның зирәк, акыллы фикерен куәтләп, минем шуны әйтәсем килә: китапка мәхәббәт тәрбияләү

укытучының гына бурычы түгел, бәлки китап язучыларның да, басучыларның да, аны таратучыларның да мөһим вазифасы. Без бергәләп милләтебезгә хезмәт иткәндә генә, яшь буында Галиҗәнап Китапка ихтирам тагын да артыр, дип ышанасы килә.

### КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Бәширов Ф.”Сөйлә, каләм!”. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – 144 б.
2. Гыйльманов Г. “Галиҗәнап Китап – тылсымлы көч! – “Сабантуй” газетасы, 1999, №27
3. Заһидуллина Д. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2005. –112 б.
4. Заһидуллина Д. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2004. –367 б.
5. Кәримуллин Ә. Китап дөньясына сәяхәт. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979
6. Китап бәйрәме. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2003. –95 б.
7. Мәһдиев Р. Мин кулыма китап алам. – “Мәгърифәт” газетасы. – 2011.


## АВАЗ ИЯРТЕМНӘРЕ ТУРЫНДА ТӨШЕНЧӘ, ТӨЗЕЛЕШЕ ЯГЫННАН ТӨРЛӘРЕ

(7 нче сыйныф)


***Әхмәдуллина Сәкинә Нәсих кызы,***
***3 нче номерлы Биектау гомуми урта белем бирү мәктәбе***


**Максат:**

- *дидактик* – аваз ияртемнәре турында гомуми төшенчә формалаштыру, аларның дөрес язылышын һәм төзелеше ягыннан төрләрен үзләштерергә ярдәм итү;
- *үстереш* – әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, ишетә белү, ишеткәнеңне үз фикереӊ белән чагыштыру, нәтиҗәләр ясый белү күнекмәләрен камилләштерү;
- *тәрбияви* – төркемнәрдә дустанә аралашып эшләү культурасын үстерү.

**Формалашырга тиешле универсаль уку гамәлләре (УГГ)**

*Шәхескә кагылышлы:*

1) төркемнәрдә бергәләп эшләү аша, укучыларда гомумкешелек кыйммәтләрен күрә, аера белү, үзеңдә шуларны булдырырга омтылу, иптәшең өчен сөенү;
2) иптәшеңә терәк, таяныч булу (төркемдә, парда эшләгәндә);
3) дөрес сөйләргә омтылу, үз сөйләм хаталарыңны тану, төзәтү;
4) шәхесне (янындагы иптәшеңне) кимсетүдән саклану, вакытында тыелып калу.

*Метапредмет:*

- *регулятив:* УМ куя белү, төркемдә чишү юлын билгеләү, адымлап, биремнәр үтәү, нәтиҗәне дөрес формалаштыру, үзбәя кую;
- *танып белү:* әңгәмәдәшеңнән ишеткәнне үз фикереӊ белән чагыштыру, гомумиләштерә белү күнекмәләрен камилләштерү, дәреслектәге белешмә белән эшли белү, эчтәлекне модельләштерү;
- *коммуникатив:* иптәшеңнең фикерен тыңлый, ишетә белү; чират белән чыгыш ясау, үз фикереңне курыкмыйча дәлилли белү, диалогик сөйләм күнекмәсен камилләштерү.

**Дәрес тибы:** яңа материалны аңлату.

**Төп төшенчә:** аваз ияртемнәре.

**Предметара бәйләнеш:** әдәбият, рус теле.

**Укыту методы:** проблемалы ситуация тудыру, тикшерү.

**Эшне оештыру төрләре:** фронталь, индивидуаль, төркемнәрдә эшләү.

**Материал:** дәреслек (Татар теле. 7 нче сыйныф. Рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен)/ В.А.Гарипова, С.А.Айдарова, Т.Г.Нәбиуллина.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015), таратма материал (биремле карточкалар), табигать күренешләре ясалган рәсемнәр.

**Җиһазлау:** презентация, проектор, экран.

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | Котелгән нәтиҗәләр (предмет) |
|---|---|---|---|
| **I.Мотивлаштыру –** | - Хәерле көн, укучылар! Бер – | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **ориентлашу этабы.** (10 мин)<br>1. а) уңай психологик халәт тудыру | берегез белән исәнләшегез. | | |
| ә) белемнәрне актуальләштерү. | - Без үткән дәрестә нинди уку мәсьәләсе өстендә эшләдек?<br><br>- Затланышсыз фигыльләргә нинди фигыль төркемчәләре керә?<br>- Ни өчен алар затланышсыз фигыльләр дип атала? | **КЖ**:- Без үткән дәрестә затланышсыз фигыльләрне кабатладык.<br>- Сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив.<br>- Алар зат-сан белән төрләнмиләр.<br>Үзбәя. | Кагыйдәне яттан әйтә белү |
| 2. а) өй эшенең ярым иҗади төрен тыңлау 216 нчы күнегү (әдәби әсәрләрдән затланышсыз фигыльләр кергән 4 җөмлә табып язарга һәм затланышсыз фигыльләргә морфологик анализ ясарга) | Һәр төркемнән бер укучының ярым иҗади өй эшен тыңлау.<br>Үзбәя кую өчен критерийлар:<br>1) затланышсыз фигыльләр кергән 4 җөмлә яздым, 4 затланышсыз фигыльгә морфологик анализ ясадым һәм аның дөреслегенә ышанам – “5” ле;<br>2) 1 хата ясадым – “4” ле;<br>3) 2-3 ялгышым булды – “3” ле. | Үзбәя. | Затланышсыз фигыль төркемчәләрен аеру, аларга морфологик анализ ясый белү |
| ә) өй эшенең иҗади төрен тыңлау: затланышсыз фигыльләрне гомумиләштереп кабатлау өчен, 8 биремнән торган тестлар әзерләргә | Һәр төркемнән бер укучының иҗат эшен тыңлау.<br>Үзбәя кую критерийлар:<br>1) 8 бирем әзерли алдым – “5” ле;<br>2) 5-7 биремле тестлар төзедем – “4” ле. | **КЖ**: 8 бирем кергән тестлар тәкъдим итү.<br>Үзбәя. | Затланышсыз фигыльләр темасын иҗади күзаллау. |
| 3. УМ кую ситуациясе | Сезнең алдыгызда схема. Һәр өстәлдәге беренче һәм өченче номерлы укучы ак кәгазьне ала, урталай бөкли аннары ерта. Ярты ягын янәшә утыручы иптәшенә бирә. Хәзер һәрберегез кәгазьне урталай бөкләгез һәм ертыгыз. Тагын бер тапкыр шулай эшлибез. Бер минут эчендә схеманы тулыландыру өчен кирәк булган сүзләрне кычкырып әйтәсез һәм кәгазьгә язып уртага куясыз. Сүзләр кабатланмасын һәм капланмасын. Мөстәкыйль сүз төркемнәренең күрсәткечләрен дә әйтергә онытмагыз. Башлыйбыз. Вакыт бетте. Хәзер язган сүзләрегез белән схеманы тулыландырыгыз. Һәр командадан икенче сандагы укучы җавап бирә.<br>- Нинди билгеләренә карап, без аларны мөстәкыйль сүз төркемнәре дип атыйбыз?<br>- 7 нче мөстәкыйль сүз төркемен өйрәндекме? Җөмләләр төзү. | **КЖ**: Сүз төркемнәре:<br>1) мөстәкыйль; 2) бәйләгеч; 3) модаль; исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, фигыль;<br>- Лексик мәгънәләренә карап: исем-предметны, сыйфат - предметның билгесен, фигыль –эш яки хәлне, хәрәкәтне, рәвеш билгенең билгесен, эш яки хәлнең билгесен, сан предметның исәбен белдерә, алмашлык башка сүз төркемнәрен алыштырып килә;<br>- морфологик яктан-төрләнәләр, төрле кушымчалар ялгана;<br>- синтаксик яктан төрле җөмлә кисәкләре булып киләләр.<br><br>- Юк. Димәк, бүген 7 нче сүз төркеме турында сөйләшербез. | Модельне дөрес итеп укый белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Хәзер табигать күренешенә карап, гади җөмләләр төзегез әле.<br>- Җөмләне матурайтып җибәрегез әле. Кошлар ничек сайрый? Чишмә ничек ага? Тукран ничек тукылдата?<br>Сез өстәгән сүзләр нәрсә тавышларыннан ясалган?<br>Димәк, төрле тавышларга охшатып ясалган сүзләр дә була икән.Тавышны без башкача ничек әйтәбез? Бүгенге дәрес темабыз ничек булыр?<br>Үзбәя кую өчен критерийлар:<br>1) мин модельне тутыра алдым, УМ матур итеп әйтеп бирә алам – “5” ле;<br>2) 1 сорауга дөрес итеп җавап бирдем, УМ матур итеп әйтеп бирә алам – “4” ле;<br>3) иптәшләрем ярдәме белән генә җавап бирә алам – “3”ле. | Үзбәя.<br>Җәйге урманда кошлар сайрый.Урманда чишмә ага.Тукран агачтагы кортларны чүпли.<br>Җәйге урманда чут-чут кошлар сайрый. Челтер-челтер чишмә ага.Тукран тук-тук итеп агачтагы кортларны чүпли. Кошлар,чишмә, тукран тавышларыннан.<br>Аваз.<br>Аваз ияртемнәре.<br>**(5 нче слайд)** | |
| | Тактага теманы язу. | Дәфтәрләргә теманы язу. | Башкалар белән беррәттән тема-ны дөрес һәм матур итеп яза белү. |
| **II. УМ адымлап чишү этабы.** (30мин)<br>4. УМ чишү | 1 нче бирем. 217 нче күнегү. Текстны укырга, аваз ияртемнәрен табарга. Бу аваз ияртемнәре нәрсә тавышларыннан ясалганнар? Аваз ияртемнәрен төшереп калдырып укыганда, мәгънә төсмере үзгәрерме? Аваз ияртемнәренең җөмләдә роле нинди?<br>Үзбәя кую өчен критерийлар:<br>1) биремне дөрес үтәдем – “5”ле;<br>2) 1-2 урында икеләндем – “4”ле;<br>3) иптәшләрем ярдәмендә генә үти алдым – “3”ле. | **КҖ**: Чупыр – чупыр – су эчкән тавыш; лач – лоч – сагыз чәйнәгән тавыш; чөкер – чөкер – сөйләшкәндәге тавыш; кет – кет –көлү тавышы; тыр – пыр – мотоцикл тавышы; “кикрик – күүүк” – әтәч тавышы.<br>Аваз ияртемнәрен төшереп калдырганда, текст эчтәлеге “тоныкланып кала”; мәгънә төсмере югала. Сөйләм тагын да тәэсирлерәк, төгәлрәк була, чынбарлыкның төрле күренешләрен образлы чагылдыралар.<br>Үзбәя. | Аваз ияртемнәрен җөмләдән мөстәкыйль табу, җөмләдәге ролен билгели алу. |
| 5. Модельләштерү. | 2 нче бирем. Мин сезгә табышмаклар язылган карточкалар таратам. Аны күчерегез һәм җавапларын языгыз, ясалышын билгеләгез. Дәреслектәге белешмәне өйрәнеп, аваз ияртеменең моделен төзергә, билгеләмә бирергә, аны бер-берегезгә һәм үз-үзегезгә әйтергә**.**<br>Һәрбер укучы ак битне ала, 4 кә бөкли, йомык почмагыннан өчпочмак бөкли. Ачабыз, | **КҖ**: Аваз иярteme мөстәкыйль сүз төркеме, кеше һәм башка җан ияләре чыгарган авазларга, шулай ук төрле предметлар һәм табигать күренешләре тавышларына охшатып ясалалар.Төзелеше һәм ясалышы буенча ялгызак, парлы, катлаулы була. Парлы | Дәреслектәге белешмәдән аваз ияртемнәре турында кирәкле мәгълүматны аерып алу, аны гомумиләштереп модель төзү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сызыкларны ручка белән йөртәбез.Уртага аваз ияртемнәре дип , беренче өлешкә бу сүз төркеменә хас характеристиканы, икенче өлешкә - ясалышын, өченче өлешкә мисаллар, дүртенче өлешкә капма-каршы мисаллар язабыз.Сезгә 1 минут вакыт бирелә. Вакыт башланды. Вакыт бетте. 3 нче өстәлнең җавабын ишетәсем килә. 4 нче номерлы укучы башлый. Чиратлашып дәвам итәсез.<br>Үзбәя кую өчен критерийлар:<br>1) мин модель төзүдә актив катнаштым, билгеләмәне әйтә алам – “5”ле;<br>2) иптәшләрем ярдәменә таянып, модель төзедем, билгеләмәне әйтә алам – “4”ле;<br>3) 2 биремдә дә иптәшләрем ярдәменә таяндым – “3”ле. | аваз ияртемнәре сызыкча аша языла, катлаулы аваз ияртемнәре – сызыкча яки нокталар аша язылалар.<br>Үзбәя. | |
| 6. Гомуми ысулны куллану. Үзконтроль. | 3 нче бирем. 224 нче күнегү Аваз ияртемнәрен табып, таблицага урнаштырырга. Буш калган урынга үзегез уйлап языгыз.<br>Үзбәя кую өчен критерийлар:<br>1) мин биремнәрне дөрес үтәдем – “5”ле;<br>2) иптәшләрем ярдәменә таяндым – “4”ле;<br>3) нигездә иптәшләрем әйткәнне генә язып бара алам – “3”ле. | **КҖ**: *Ялгызак:* мияу, дерт, гөлт, шалт, кап, челт.<br>*Парлы*: тап-тап, ха-ха, бак-бак, тук-тук, чи-чи.<br>*Катлаулы:* тик-так-так, пух-пах-пух, ах-ах-ух, ту-ту-ту, уу-уу-уу, чың-чың-чың, дың-дың-дың, пуф-пуф-пуф, уф-уф-уф. | Ясалышы буенча аваз ияртемнәрен аеру, үз-үзеңне тикшереп карау. |
| **III. Рефлексив бәяләү этабы**.<br>(5 минут) | - Дәрестә нинди УМ өстендә эшләдек?<br>- Үзең өчен нинди ачыш ясадың? | **КҖ**: - Без бүген дәрестә аваз ияртемнәре турында өйрәндек. 217 нче күнегүне үтәп, сөйләмдә аваз ияртемнәренең җөмләдәге ролен ачыкладык. Дәреслектәге белешмәне өйрәнеп, аваз ияртеменең моделен төзедек, аңа билгеләмә бирдек. Шул билгеләмәне бер-беребезгә һәм үз-үзебезгә әйтеп карадык. Карточкадагы табышмаклар аша аваз ияртемнәренең мәгънәви ролен билгеләдек. 224 нче күнегүне үтәп, аваз ияртемнәрен ясалышы буенча таблицага урнаштырдык. | Аваз ияртемнәренә багышланган дәрескә рефлексия ясый белү. |
| **Дәрескә гомуми бәя кую.** | Билгеләр журналга төшерелә. | Биремнәр үтәүдә алган билгеләрдән гомуми билге чыгарыла. | |
| **Өй эше:** мәҗбүри - 218 нче күнегү; ярым (иҗади) – әдәби әсәрләрдән аваз ияртемнәре кергән 6 җөмлә язарга; иҗади –“Урманның сихри моң-тавышлары” дигән темага кыска сочинение языгыз. | | | |

## ДҮРТ АЯКЛЫ ДУСЛАРЫБЫЗ

**(**әдәби укудан дәрес эшкәртмәсе. 3 сыйныф, рус төркеме)

***Тазмиева Рушания Миннәхмәт кызы,***
***Бөреле урта гомуми белем бирү мәктәбе***

**Цикл**: Кечкенә дусларыбыз.

**Тема.** Минем этем (песием) бар - д/м сөйләм.

**Максат**:

1. Дүрт аяклы дуслар турында алган белемнәрне кабатлау, ныгыту, системага салу, диалогик-монологик сөйләмгә чыгу.

2. Укучыларның логик фикерләү сәләтен үстерүгә шартлар тудыру.

3. Кечкенә дусларга карата хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү.

**Бурыч**: Укучыларның иҗади фикерләү сәләтен, үз-үзеңә бәя бирү мөмкинлекләрен үстерүгә шартлар тудыру, аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру.

**Регулятив:**

- укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү;
- кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;

**Танып белү:**

- тиешле мәгълүматны табу, билгеләү;
- төшенчәгә якын килү өчен нәтиҗә ясау;

**Коммуникатив:**

- хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү;
- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү.

**Шәхси:**

Ярдәмчеллек, башка кешеләргә карата кайгыртучан булу.

**Җиһазлау:** компьютер, схемалар, карточкалар, презентация, интерактив такта, рәсемнәр

**Дәреснең тибы:** ЛГКК

**Дәрес барышы**

**I Оештыру өлеше. Уңай психологик хәләт тудыру.**

- Исәнмесез, балалар!
- Исәнмесез, хәерле көн!

Матур үтсен көнебез!
Көләч булсын йөзебез!

Булыйк һәрчак әдәпле,
Отыйк матур гадәтне.
Дөрес, матур утырыйк,
Тырышып җавап бирик.

2. Дежур укучы белән әңгәмә.
3. Һава торышы турында сөйләшү

- Артемий, спроси у Даши, какая сегодня погода?
- Аня, спроси у Ильи, какое у него настроение? һ.б.

**II. Белемнәрне актуальләштерү. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

Кроссворд чишү.

**III. Дәрескә максат һәм бурычлар кую**

- Вертикаль сызык буенча нинди сүз килеп чыкты? **(койрык)**
- Бу сүзнең безнең дәрескә нинди катнашы бар?
- Димәк, бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәкбез?

**Нәтиҗә**: дүртаяклы дусларыбыз турында сөйләшәчәкбез.

- Балалар, бүген дәрестә без сезнең белән дүртаяклы дусларыбыз турында алган белемнәребезне кабатларбыз Һәм ныгытырбыз.

**IV. Белем һәм осталыкларны төрле ситуацияләрдә куллану.**

**1. Өй эшен тикшерү.**

- Балалар, хәзер өй эшен тикшереп алырбыз. Мин сүзтезмәләрне русча әйтәм, сез алдыгыздагы кәгазьләргә аларның татарча тәрҗемәсен язасыз.

**Тикшерү**: каршы күршегез белән кәгазьләрне алышыгыз һәм бер-берегезне тикшерегез дә кире бирегез. (Экранда слайд №1, тәрҗемә белән сүзләр).

Ит ашый – ест мясо
Балык ярата – любит рыбу
Сөт эчә – пьёт молоко
Күзләре яшел – глаза зелёные

Койрыгы йомшак, озын – хвост пушистый, длинный
Уйнарга ярата – любит играть
Сөяк кимерә – грызёт кость
Өйне саклый – дом охраняет

Колаклары кечкенә – уши маленькие                    Тычкан тота – ловит мышей

**Билге кую**: 9-10 дөрес сүз - “5”ле, 7-8 дөрес сүз – “4”ле, 5-6 дөрес сүз – “3”ле.

- Яхшы, балалар, сез өй эшен әйбәт өйрәнгәнсез.

**2. Парлы эш - диалоглар төзү.**

- Хәзер шул сүзтезмәләрне кулланып сораулар төзегез, җилкәдәш күршегез белән сөйләшегез.

**Тикшерү:** һәр төркемнән бер пар тыңлана, икенче төркемнән бер укучы бәя бирә.

**Ял минуты**. Музыка уйнаганда биеп йөриләр. Музыка туктагач, биремнәр әйтелә.

Күрсәтегез: Песидә ничә тәпи? Кәҗәдә ничә койрык? Эттә ничә колак? Кешедә ничә күз? Сыйныфта ничә төркем?

**3. Җөмләне тулыландыр**. Укучылар, сезнең алдыгызда карточкалар ята. Сезгә, өйрәнгән сүзтезмәләрне өстәп, җөмләләрне тулыландырырга кирәк. (3 әр сүзтезмә)

№1. Актырнакның ..., ..., ... .

№2. Акмуенның ..., ..., ... .

№3. Песием ..., ..., ... ярата .

№4. Этем ..., ..., ... ярата.

Тәмамлаган укучы торып баса һәм башка төркемдәге шул номерлы укучы белән фикер алыша, үзендә булмаган сүзтезмәләрне өстәп яза.

**Тикшерү:** Кем 3 сүзтезмә өстәп язды? (4 сүз, 5 сүз). Иң күп сүзтезмә язучы укучы җөмләне укый.

- Бик яхшы, балалар, булдырдыгыз.

4. **Ситуатив күнегү эшләү.**

**-** Һәр укучы 1 җөмләне тәрҗемә итә һәм уртага куя. Эш беткәч, төркемнән 1нче укучы торып баса.

Как скажете о том, что:

№1. - моя собака любит рыбу и мясо;

№2. - у кошки длинный, мягкий хвост;

№3. - Акмуен меня любит и слушается;

№4. - Акмуен вкусно ест и много спит?

**Тикшерү**:1т.- №1, 2т.- №2, 3т. - №3, 4т. - №4 нче укучы җавап бирә.

Бик яхшы, балалар, булдырдыгыз.

**V. Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру**

**-** Балалар, хәзер нокталар урынына төшеп калган сүзләрне куеп хикәя төзибез. Эшне төркемнәрдә эшлибез. Кайсы төркем алдан эшләп бетерер?

Минем ... бар. Ул бик ... һәм ... . Ул ... төстә. ... койрыгы ... , колаклары ... , күзләре ... төстә. Ул .... , ... ашый, ... эчә. Песием (этем) ... ярата. Без аны бик яратабыз.

- Ә зәзер хикәягезгә исем табыгыз һәм текстыгызның өстенә язып куегыз.

- Хикәяне кем сөйләп күрсәтә ала? Теләүчеләр бармы? *(Хикәяне теләүче укучылардан сөйләтү.)*

**VI. Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү**

1. Үзеңнең кечкенә дустыңның рәсемен я фотосын алып килергә.
2. Дустың турында 4-5 җөмлә төзергә

**VII. Рефлексия.** (Дәрескә йомгак ясау).

- Дәрес башында үзебезгә нинди максат һәм бурычлар куйган идек?

- Без үзебезнең бурычларыбызны үтәдекме?

- Сезгә күбрәк нәрсә ошады? Ни өчен?

- Песиләр, этләр турында нәрсәләр белдек? һ.б.

**VIII. Укучыларның белемен бәяләү. Үзбәя**

**-** Укучылар, дәрес башында мин сезгә түгәрәкләр тараткан идем.Ә хәзер мине игътибар белән тыңлагыз һәм түгәрәкләргә исемнәрегезне языгыз. Дәрестә кем бар эшне дә аңлап, үз-үзенә ышанып эшләде, түгәрәкләрегезне шат йөзле кояшка куегыз. Әгәр бераз икеләнебрәк эшләгән һәм ялгышкан булсагыз, малай рәсеменә куегыз. Сезгә эшләр бик авыр тоелган булса һәм сез биремнәрне үти алмаган булсагыз, түгәрәкләрегезне айга куегыз.

- Оля, син нинди рәсем сайладың? Ни өчен?

- Аня, Толикка нинди билге куяр идең? Ни өчен? һ.б.

## Ә. ЕНИКИНЕҢ «ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ» ӘСӘРЕНДӘ БУЫННАР БӘЙЛӘНЕШЕ
(7 нче сыйныф)

***Гарипова Клара Барый кызы,***
***Суыксу гомуми белем бирү мәктәбе***

**Максат.** Әсәрдә өлкән һәм урта буынга хас сыйфатларны билгеләү, алар арасындагы каршылыкның сәбәпләрен ачыклау, әсәрнең темасын, идеясен табу.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет – катлаулы текст белән эшли, иң әһәмиятлесен таба белергә өйрәнү.

Предмет – Ә. Еникинең “Әйтелмәгән васыять” әсәрен анализлау.

Шәхескә кагылышлы – өлкән буынга ихтирам, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау**: мультимедиа проекторы, экран, «Әйтелмәгән васыять» әсәрен анализлау барышында кирәк булган иллюстрацияләр, сюжет элементлары язылган слайдлардан презентация.

**Дәрес барышы.**

**Слайдта язылган эпиграф укыла:**

**Слайдта язылган эпиграф укыла:**

Бер-беребезгә нинди бәгырьсез без,
Хәтта кансыз — кемнән өйрәндек?
Усаллыкка, әдәпсезлекләргә
Нинди иләк аша иләндек?

Ата-баба гомер юлымы бу —
Без нинди соң, нинди юл алдык?
Аерылдык җирдән, йолалардан,
Үзебездән үзебез югалдык.

Наҗар Нәҗми.

**Укытучы**. Бу шигырь юлларын дәрескә эпиграф итеп алуым юкка гына түгел, укучылар, чөнки без бүген Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен өйрәнүне дәвам итәбез. Ничек уйлыйсыз, без бүген нинди темага сөйләшү алып барырбыз?

- Өлкәннәр һәм яшьләр турында.

- Әйе, без бүген Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә буыннар бәйләнешен, буыннар арасында рухи бәйләнешне күзәтербез, өйрәнербез.

**“Аквариум” блиц-сорау**. (Өч укучы “алтын балык” була һәм дәрескә сораулар язалар, калган укучылар тыңлап кына утыралар һәм тактага язылган сораулар рәтенә үзләренекен өстиләр, шулай итеп дәрескә план төзелә).

1. Акъәби гомере буе балалары дип яшәсә дә, ни өчен картайган көндә ялгыз кала?
2. Балалары, оныкларының әбигә мөнәсәбәте нинди?
3. Акъәбинең васыятен тыңлаучы табыламы? һ.б.

**Укытучы.** Әсәр белән барыбыз да таныш. Әйдәгез, әсәрнең төзелешен искә төшерик.

**1 нче төркем, сюжет элементларын искә төшереп, 2 нче төркем белән әңгәмә оештыра.**

Ике төркем дә әзерләнә. “РАУНД ТЭЙБЛ” структурасы кулланыла. Укучылар сюжет элементларын язалар һәм җавап әзерлиләр. Әңгәмә барышында укучылар дөрес җаваплар бирсәләр, бәяләү карточкасына + тамгасы куеп баралар, соңыннан, билге куйганда, бу исәпкә алына.

**Әңгәмә:**

| | |
|---|---|
| - Бу әсәрдә экспозиция өлеше нинди? | - Әбинең авылдагы тормышы сурәтләнә. |
| - Төенләнеш? | - Акъәбинең авырып китүе. |
| - Вакыйгалар үстерелеше? | - Акъәбине шәһәргә алып килү, авырып ятуы. |
| - Кульминация? | - Әбинең васыять әйтергә теләве, васыять үзе. |
| - Чишелеш? | - Үлем. |
| - Эпилог? | - Авылдан сандык килү, Миңлебай картның сүзләре. |
| - Ә сюжетның нигезендә нәрсә ята? | - Каршылык (конфликт). |
| -Каршылык кемнәр арасында булырга мөмкин? | - Кешеләр. Кеше һәм тирәлек. Кеше һәм яшәү рәвеше. Кешенең үз эчендә. (Бу җаваплар слайдта күрсәтелә.) |

**Укытучы.**

- Ә менә «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә төп каршылык кемнәр арасында бара?
- Акъәби һәм балалары, оныклары арасында.
- Бу нинди каршылык?
- Бу карашлар каршылыгы. Бу каршылык рухи төрлелек сәбәпле килеп чыга.
- Әсәрдә төп образ кем?

- Акъәби. (Слайдта укучылар ясаган Акъәби портреты куела).

**Укытучы.** Менә шушы кеп-кечкенә буйлы, арык кына бер әбине нинди сыйфатлар бизи? Ни өчен аны авыл халкы хөрмәт итә?

- Ул гомере буе ак күңелле булган. Күршеләре аны хөрмәт итә, озатырга барысы да килә. Хәтта кечкенәләр дә аның исемен ишетүгә тынып калалар.

**Укытучы.** Бөтен кеше хөрмәт итеп яши, ә шулай да ул үзен ялгыз хис итә. Ни өчен? (Җавапны әсәрдән эзләтү эше оештырыла.)

- ... Шулай да карчыкка җиңел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде. Ялгыз башын монда асраса да, күңеле белән ул һаман балалары янында иде...

(Нәтиҗә: балалары аның сагынуын аңламыйлар, ашыгалар.)

**Укытучы.** Акъәби балаларының бәхетле булуларына куана, әмма шул ук вакытта борчыла да. Ни өчен? Бу сорауга җавапны дәреслектәге өзектән эзләп карыйк әле.

- ... Тик менә бәхетле булып киткән балалары аңардан ничектер шактый ераклаштылар шикелле. Зарланса язык булыр, карыйлар, ярдәмнәреннән ташламыйлар, рәхмәт үзләренә. Тик шулай да карчык борчылып уйламыйча булдыра алмый: туган җирләрен дә, кечкенә Юлкотлыны да, аталарыннан калган нигезне дә алар бөтенләй онытып баралар кебек. Уйлары да, күңелләре бүтәндә булса кирәк... (Нәтиҗә: ата– аналар нигезен онытып баралар кебек, вакытлары юк.)

**Укытучы.** Оныгы кунакка кайткач, карчык бик сөенә, бар булган сый-хөрмәтен куя. (Өзек уку)

... Акъәби уйчан гына аңа карап торды, үзалдына гына күрсенгәндәй итте. Аннары моңсу-назлы итеп кенә елмайды: нишлисең, бу җирән чәчле егеттә аның каны. Башкорт каны ага иде шул...

Ә нигә көрсенә соң ул? Әсәрнең кайсы урынында бу турыда язылган?

-...Ах, бу тел юклыгы!.. Карчыкның тел өйрәнер вакыты күптән үткән шул инде, әмма ник бу Суфиян, юньсез, балаларына, ичмасам, әбиләренә дәшә алырлык кына үзебезчә берничә дистә сүз өйрәтмәде икән соң?!

**Укытучы.** Тормыш үз агышына гына барган чакта, көтелмәгән вакыйга була. Нинди вакыйга ул?

- Акъәби авырый һәм шәһәргә китә.

**Укытучы**. Шәһәргә киткәндә, ананың халәтен тасвирлаган юлларга тукталыйк әле. (Әсәрдән өзекне уку)

- ...Карчык бүтән сүз әйтмәде, авыр сулап кына куйды, монда доктор каравыннан башка, мәтрүшкә-фәлән эчкәләп кенә терелеп китмәсен үзе дә аңлый иде булса кирәк. Аннары япа-ялгыз яту да аны шомландыра иде. Ә тегендә, калада, бөтен балалары диярлек, ходайдан вакыт җитеп, алай-болай булып китсә, алар аның янында булачаклар. Әмма шул ук вакытта нәкъ менә шушы «алай-болай булып» , ягъни үлеп китүен уйлап, ул үзенең гомер иткән почмагыннан чыгып китәргә дә теләми иде. Чит җирдә үлү, чит җир туфрагында ятып калу аны һәрвакытта куркыта иде. Юк, аның шушында, карты җан биргән кечкенә өендә үләсе, авылдашлары кулы белән кечкенә авыл зиратына - карты һәм яшьли үлгән сабыйлары янына куеласы килә иде. ... Юк, авыр иде бу карчыкка бу төенне чишү, бик авыр иде!

**Укытучы**. Үзенең борчу-хәсрәтен ана ни рәвешле белдерә, сүзләр беләнме? - Юк, авыр сулап.

**Укытучы**. Бу сүзләр әсәрдә тагын очрыймы? - Әйе, еш очрый.

**Укытучы**. Менә шушы сабыр җанлы ананың иң борчылганы, иң курыкканы нәрсә?

- Чит җирдә үлеп калу.

**Укытучы**. Язмыштан узмыш юк дигәндәй, Акъәбигә шәһәргә китәргә туры килә. Начар булмый аңа анда. Урыны йомшак, астында чип-чиста ак җәймә, өстендә сатин юрган — ипле, рәхәт. Рәхмәт инде киявенә дә, кызына да. Билгеле, ул балаларыннан бик риза, күңеленнән аларга рәхмәт укып кына тора, әмма шулай да йөрәге сызланып куя. Ни өчен?

- Аларның бу соңгарак калган яхшылыклары вакыт-вакыт карчыкка аны фани дөньядан юатып озатыр өчен генә эшләнгән шикелле булып тоела, шуңа йөрәге сызланып куя, һәм чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, иң элек бер алласына сыенып, тыныч кына ята бирә.

**Укытучы.** Гомернең соңгы чиге — үлем. Акъәби үзенең соңгы көннәре якынлашуын сизә. Туган җирдән аерылу аның үзәген өзә, әмма аннан да көчлерәк борчылу биләп ала аны. Бу нинди борчылу?

- Акъәби үзен ничек күмүләре хакында уйлап борчыла.

... Иң элек аның уен, билгеле, үлгәннән соң ничек итеп күмәрләр дигән нәрсә гел борчып тора. Ул белә: кайда, кемнәр кулында ятуын, әмма ул, гомере буена башыннан яулыгын салмаган мөселман карчыгы, алла хозурына барам дип ышана, шуңа алдан әзерләнеп килгән бөтен керсез күңеле белән үлгәннән соң гәүдәсен бары мөселманча итеп җирләүләрен тели...

... зиһене ачык, теле бар чакта ул үзенең соңгы теләген, соңгы васыятьләрен әйтеп калырга тиеш. Аннары инде ... китәргә дә була...

**Укытучы.** Акъәби балаларының үзеннән, туган җирдән ераклаша баруларын тойса да, васыятьне үтәми калуларына ышанмый. Өметләнә. Нәрсә ди ул?

...Ул кушканча эшләргә тиешләр — бу бит газиз аналарының соңгы васыяте! Васыятьне үтәмәү мөмкинме соң?!

**Укытучы.** Аның өметләре акланамы соң?

- Юк, акланмый шул.

**Укытучы.** Карчыкның күңелендә балаларга рәнҗү хисе уяна. Бу кайсы юлларда чагыла? Әсәрдән шул урынны табып укыйк әле.

... Алай, әнә ничек икән ул!.. Үләсе кеше белән каласы кеше тиз генә уртак тел таба алмыйлар икән! Бик кыен икән аларга сөйләшүе... Ни өчен соң бу шулай? Бөтенләй кирәксез, юк нәрсә турында кайгырып ятамыни ул — дөньядан китәсе ана кеше? Балалары белән аның арасы шулай бик ераклашты микәнни? Алай дисәң, карыйлар, дәвалыйлар, кызганып, борчылып та торалар кебек, ә менә әсәйләренең соңгы сүзен, соңгы үтенечен аңларга, йөрәген аңларга теләмиләр. Нидән соң бу болай?

Васыятьне уку. (Укытучы сәнгатьле итеп укый.)

**Укытучы.** Әнә шул васыятьне тыңлаучы кеше табылмый. Акъәби һаман бер хәлгә гаҗәпләнә. Нәрсәгә гаҗәпләнә ул?

- Гөлбикә дә, Суфиян да, барысы да ашыгалар. Ашыгалар, ашыгалар!

**Укытучы.** Үлем дә ашыга иде. Акъәбинең үлемен, васыятенең ничек, ни дәрәҗәдә үтәлүен барыгыз да беләсез. Әсәрдә аның җанын аңларга тырышучы бер образ бар. Ул нинди образ?

- Шагыйрь образы.

**Укытучы**. Нәрсә якынайта соң аларны?

- Икесе дә туган туфракка, гореф–гадәтләргә тугрылыклы. (Үзара сөйләшүләрен искә төшерү, шагыйрьнең кабер янында әйткән сүзләрен уку).

Әмма шагыйрьне аңларга теләүче табылмый.

**Укытучы.** Акъәби биек тау башындагы зиратта әнә шулай ялгызы гына торып калса да, үзенең фани дөнья белән аерылмавын тагын бер тапкыр балаларының исенә төшерде. Нинди вакыйга булды?

- Сандык вакыйгасы.

**Укытучы.** Сандыкта иң өстә нәрсә ята иде? - Кәфенлек.

**Укытучы.** Ни өчен балалары, бу кәфенлекне күргәч, хәтта бер–берсенә күтәрелеп карарга да кыймадылар?

- Чөнки алар әниләрен мөселманча күммәделәр.

**Укытучы.** Балалар сандыктагы әйберләр арасыннан иң беренче нәрсәгә игътибарны юнәлттеләр?
- Камчыга.

**Укытучы**. Акъәби үлгәннән соң, аның балалары буыннарга тапшыру өчен, бүре тотканда кулланыла торган камчыны сайлап алалар. Ә карчык камчыны хәтергә дә алмый. Яшь буын әйтерсең лә явызлык символын сайлый, матурлыктан баш тарта, аны театрда, музейларда кулланыла торган бизәккә әйләндерә. Шул ук вакытта камчы — яра сала торган корал, әйтерсең лә язучы хикәядә күтәрелгән проблемаларны искәртеп, безнең күңелләргә дә эз сызып куя. Сандыктагы истәлекләрне кая тапшырдылар?

- Театр гардеробына.

Укытучы. Акъәби белән балаларны, өлкән буын һәм урта, яшь буынны бәйләп калырга мөмкин булган соңгы җеп тә өзелде. Буыннар арасында тирән упкын ясалды.

**Ике төркемгә эш бирелә. (Интеллект-карта төзү)**
**Геройларга характеристика бирү**



**Укытучы.** Әсәрдә Акъәби образы нинди вазифаны башкара? (1 нче төркем нәтиҗә чыгара һәм фикерен дәлилли.)

- Туган җиргә, милли гадәт–йолаларга үзенчәлекле мөнәсәбәте булган өлкән буын вәкиле.

**Укытучы**. Ә балалары, оныклары? (2 нче төркем нәтиҗә чыгара һәм фикерен дәлилли)

- Тамырларын югалткан, туган-туфрактан, йола-гадәтләрдән аерылган буын вәкилләре.

**Укытучы.** Әсәрнең темасы нинди?

- Буыннар арасында рухи бәйләнеш өзелү.

**Укытучы**. Ә идея — тема куйган мәсьәләнең, сорауның җавабы ул. Ни өчен буыннар арасында рухи бәйләнеш өзелде? Автор нәрсә әйтергә тели?

- Буыннар арасында бәйләнешләр өзелү Акъәбинең васыяте балаларына барып җитмәүдә күренә.

**Укытучы.** Ләкин язучы бу ноктада туктап калмый. Әсәр ахырында Миңлебай карт авызыннан нинди сүзләр әйттерә?

- ... «Кайтыр, насыйп булса, кайтыр, ә син учагын карый тор, учагын. Учагында ут сүнмәсен.»

**Укытучы**. Шул рәвешле ул нинди фикер белдерә?

- Өлкән буын өчен әһәмиятле булган кыйммәтләр югалмас, дигән фикер белдерә.

Эпиграфны яңадан уку.

**Укытучы.** Ә. Еники бер әсәрен дә тота-каба язмаган, озак уйланып йөргәннән соң гына язарга тотынган икән. «Әсәрнең темасын миңа мәрхүм Баязит Бикбай (башкорт язучысы) биргән иде, - дип искә ала язучы. Дөресрәге, бер башкорт карчыгының аянычлы үлеме турында сөйләгән иде. «Уйла, бәлки, язарсың, синең каләмгә туры килә бу, дигән иде».

Димәк, бу әсәрне язарга этәргән реаль фактлар булган. Бу әсәре аша язучы безгә олы фикер җиткерә. Акъәбинең васыятен балалары да, оныклары да ишетмәде. Бары тик без генә аның күңелендәге кичерешләрен, яшь буынга җиткерәсе кыйммәтле сүзләрен белдек. Сез бу васыятьне ничек кабул иттегез икән?

**Өй эше.** 1. « Минем күңелемдә туган хисләр». Фикерләрне туплап язарга.

2. Әсәрдән күңелеңә иң тәэсир иткән урыннарны сәнгатьле укырга өйрән.

3. Хисләремне салам рәсемгә ...

4. Рус әдәбиятында өйрәнелә торган К. Паустовскийның “Телеграмма” әсәре белән уртак һәм аермалы якларын билгеләү*

Рефлексия. 1. Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Ни өчен әсәр “Әйтелмәгән васыять” дип атала? Ни өчен балалары Акъәбинең соңгы васыятен үтәмиләр? Бу хаталарны төзәтеп буламы?

2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

## ИСЕМ, СЫЙФАТ, ФИГЫЛЬ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕН КАБАТЛАУ

(2 нче сыйныф өчен дәрес фрагменты)

***Сәйфуллина Рузалия Суфиян кызы,***

***Хәй Вахит исем. Мәмдәл гомуми урта белем мәктәбе***

**Максат:** сүзләрнең нәрсә белдерүләрен, сораулар куеп, төркемнәргә бүленүен ныгыту һәм сөйләмдә аларның төрле формаларын танып белү күнемәсен формалаштыру; төркемнәп эшләү күнекмәләрен ныгыту; игътибарлык, мөстәкыйльлек тәрбияләү.

**Җиһазлау:** аваз модельләре, сүз төркемнәре моделе, дәреслек, өстәмә эш дәфтәрләре.

**Дәрес барышы**

1.**Оештыру өлеше.** Мин иртә белән дәрескә керәм, укучыларымның хәлләрен беләм.

Исәнме, Гүзәл, саумы Рүзәл! Хәерле иртә, Мәрьям, хәлен ничек Галләм.

**Укытучы сүзе.** Мин сезнең белән ничек итеп исәнләштем? (Җавап бирәләр). Сез дә иптәшләрегез белән шулай исәнләшәсезме? Бер-берегезгә хәерле иртәләр телисезме? Бу ягымлы, җылы йомшак сүзләрдән соң сезнең дә күңелегез күтәрелдеме?

**Укытучы сүзе.** Балалар, безнең татар халкында бик матур итеп исәнләшү йоласы бар. Безнен эби-бабайлар ничек итеп исэнлэшэлэр? *(Ике кулларын сузып, ягымлы елмаеп исәнләшәләр)*

**Укытучы сүзе.** Доньял халыклары ничек итеп исэнлэшэлэр икэн шуны карап үтик әле. *(Карта янына киләсең!)*

Японнар ике кулларын күкрәкләренә куеп, баш иеп исәнләшәләр. Америкалылар, гел елмаеп, кул болгап исәнләшә. Ә менә руслар, укучылар, кочаклашып исәнләшә.

Әйдәгез, без дә алар кебек бер-беребезне сәламләп карыйк *(Басалар, исәнләшәләр).*

**Укытучы сүзе.** Ничек күңелле булып китте. Шундый күңелле моментта, дәресебезне башлыйбыз. *(Сыерчык сайраган тавыш ишетелә.)*

**Укытучы сүзе:** Балалар, ишетәсезме, безнең дәрескә кунак килгән. Кем белә, нинди кош тавышы икән бу? *(сыерчык)*

Сыерчык, сыерчык... кем бу кошны тасвирлап бирә ала. *(Сөйлиләр)*

-Бик дөрес, ерак иллөрдән туган ягыбызга сыерчык кайткан. *(Экранда сыерчык рәсеме чыга).*

**II. Укытучы сыерчык турында өстәлдән таптырып укыта:** Сыерчыклар күренү белән гөрләвекләр ага. Үги ана яфраклары чәчәк ата, беренче күбәләкләр оча башлый.

Сыерчыклар башка кошларның тавышларын истә калдыралар һәм бик төгәл итеп башкаралар. Сыерчыклар 1 сәг эчендә 30-35 тапкыр җим алып кайталар.

Басу, бакчаларны корткыч бөҗәкләрдән чистартып, сыерчыклар кешеләргә зур файда китерәләр. Ата сыерчыклар иртәрәк килә.

**Укытучы сүзе.** А) Тактада РЕБУС: Сыер+чык, Б) Сыерчык сүзенә башка аңлатмалар биреп үтик әле. Сыерчык сүзенең моделен **дәфтәрдә тикшерү**.

**III.Төркемнәргә бүленеп эшләү.**

**1 нче эш. Укытучы сүзе.** Сыерчыклар безгә **ЯЗ (рәсеме кирәк)** алып килгәннәр. Алар үз канатларында яз көне нәрсәләр алып киләләр? (Күп итеп кояш нурлары, җылылык, кар эрү, гөрләвекләр агу ...).

**Укытучы сүзе.** Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен табигать үзгәрә соң? (Кояш нурларын күбрәк сипкәнгә) Кояш кайчан яктылыкны, җылылыкны күбрәк бирә? (нурлары күп булганда).

**Тактага куела:** 1нче төркем: Яз, кояш, тамчы, балалар

2 нче төркем:Ямьле, зәңгәр, күңелле

3нче төркем: Җитте, эри, тама, ага

Әйдәгез, кояш нурлары артындагы сүзләрнең мәгънәләренә карап 3 төркемгә берләшик. (Сүзләрне чыгып алалар, басып аралашалар, киңәшәләр һәм төркемләшеп утыралар).

**Укытучы сүзе.** Сүзләрне тагын бер кат укып, нәрсәгә карап бүлендегез, аңлатып бирегез? (мәгънәләренә карап). - Димәк, бүген без мәгънәләренә карап бүленүче сүзләр турында булган белемнәребезне барларбыз.

**2 нче эш. Укытучы сүзе.** Ә хәзер өстәлдәге 3 карточканың 1 сендә сезнең сүзләргә туры килә торган җавап бирелгән, кайсысы булыр? Уйлагыз, сайлагыз!!

**Язып өстәлгә куела:** 1 төркем. Бу сүзләр предметны белдерәләр. Кем? Нәрсә? соравына җавап бирәләр.

2 төркем. Бу сүзләр предметның билгесен белдерәләр Нинди? Кайсы ? соравына җавап булып киләләр.

3 төркем. Бу сүзләр эшне белдерәләр. Нишли? Нишләде? Соравына җавап булып киләләр.

**3 нче эш.** Һәрбер предметның, күренешнең исеме булырга тиеш. Әйдәгез, үзебез төзегән сүз төркемнәренә исемнәр бирик. (**экранда** 3 сүз тәкъдим ителә, үзегезгә туры килгәнен сайлап алыгыз.).

Экранда исем, сыйфат, фигыль сүзләренең аңлатмалары бирелә. Һәр төркем бу исемне ни өчен сайлап алганын әйтә. (**Кагыйдәне тулы** итеп әйттерү).

**4 нче эш.** Предмет исемен белдергән сүзләрдән предметның билгесен һәм эшен, хәрәкәтен белдергән сүзләр ясa.

**Тактага язу:** Май-майлы, майлый. Җыр-җырлы, җырлый һ.б.( тикшерү).

**5 нче эш.** Бу йортларда нинди сүзләр яши ала? Һәр йортка бишәр **сүз яз.** (Йорт рәсеме бирелә.)

**6 нче эш.** Уен “Бер предметка күп билге” (Муляжларны телдән тасвирлау.)

1 нче төркем алма сүзенә

2 нче төркем кыяр сүзенә

3 нче төркем лимон сүзенә сыйфатлар языгыз

**7 нчы эш.** Табышмаклардагы предметның билгесен белдергән сүзләрне – кызыл карандаш белән, эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне яшел карандаш белән түгәрәккә ал.

**8 нче эш:** Бирем И, С, Ф не белдергән 3-5 әр сүзне сайлап языгыз:

Йөгерә, авыз, бәрәңге, җиңел, җылы, елый, тикшерә, тавык, сәгать, шәһәр, эссе, йөрәк, карый, тәмле, савыт, сеңел, елга, муен, егет, авыл, кыңгырау, караңгы, тәмле, йөзә, кавын, казый, чаңгы, һава, йолдыз, сикерә, елмая, борын, йомшак, хайван, эшли, бияләй.

**Йомгаклау.** Бүген дәрестә нәрсәгә өйрәндек? (Кагыйдәләрне тагын 1 кат әйтеп чыгыгыз). Дәрес сезгә ошадымы? (Кайсы ягы кемгә күбрәк ошады.) **Бәяләү.**

**Өйгә эш бирү.** Сүзләрдән схемага туры килерлек итеп җөмләләр төзеп язарга.

1. ИСЕМ сыйфат исем
2. Сыйфат исем фигыль
3. Исем исем фигыль

# СЕРЛЕ ХӘРЕФЛӘР

(10 нчы сыйныфта татар теле һәм әдәбиятыннан интеграл дәрес)

***Җамалиева Ләйсән Ильяс кызы,***
***Хәй Вахит исем. Мәмдәл гомуми урта белем мәктәбе***

**Дәреснең максаты:**

1. Гарәп графикасы һәм Коръән турында укучыларның белемнәрен системалаштыру һәм тирәнәйтү.

2. Коръән мотивларының Г.Тукай иҗатында урын алуы турында төшенчә бирү, укучыларның мөстәкыйль фикер йөртү сәләтен үстерү.

3. Укучыларга әхлак тәрбиясе, үз-үзләрен тәрбияләүгә юнәлеш бирү.

**Тибы:** катнаш дәрес.

**Метод, алымнар:** әңгәмә, эзләнү эше, үзлектән эш, диктант, сәнгатьле уку, дәреслек буенча эш.

**Җиһазлау:** компьютерда слайдлар, Г.Тукай китаплары, борынгы кулъязмалар. Шәмаилләр, карточкалар, тест.

**Дәрес барышы**

1. **Актуальләштерү. Психологик уңай халәт тудыру**. Язмада "Әллүки" көе яңгырый.

- Хәерле көн, кадерле укучылар, килгән кунаклар. Сезнең белән күрешүне мин сезнең йөзләрегез, күзләрегез, күңелегез аша башлыйм. Барыгызга да яхшы кәеф телим. Әйдәгез, бер-беребезгә елмаеп алыйк әле. Сез бик шат күренәсез. Бер-беребезне аңлап, бу дәрестә күп эшләр башкарырбыз, дип уйлыйм.

**Дәрескә максат кую. 1 слайд.** Кешенең гүзәллеге - аның язуында. Ә бу гүзәллекнең акыллы кеше кулында булуы – бәхет.

"Кешенең гүзәллеге - аның язуында. Ә бу гүзәллекнең акыллы кеше кулында булуы - бәхет", - ди шәрык афоризмы. Гаҗәеп бизәкләр рәвешенә кертеп язылган гарәп графикасы белән без алдагы дәрестә таныштык. Шуннан чыгып, бүгенге дәресебезнең темасын "Серле хәрефләр" дип аталачак. Дәресебездә әлеге хәрефләрнең көче, могҗизасы турында сөйләшербез. Әйдәгез, искә төшереп китик әле.

**2. Үткән материалны кабатлау.**

***Укытучы.*** Гарәп графикасы татарларда кайчан кулланыла башлый һәм кайчанга кадәр әлеге графика кулланылышта була?

***Укучы***. Гарәпләрдә безнең эра башларында кулланылган бу язу, ислам дине урнашкач, VI-VII йөзләрдә бик нык активлаша. Ислам дине таралуга бәйле рәвештә, гарәп язуы башка күп кенә халыкларда, шул исәптән фарсыларда һәм төркиләрдә дә кабул ителә. Безнең борынгы бабаларыбызга ул кайбер җирләрдә IX йөздә үк керә. Ә Болгар илендә гарәп язуы 922 нче елда, ислам дине кабул ителгәч, активлаша һәм ул бездә 1927 нче елга кадәр кулланыла. Бу язуда безгә халкыбызның бик бай рухи мирасы килеп җиткән.

***Укытучы.*** Гарәп графикасында язылган язмаларны күбесенчә күчереп язып тараткannар.

**2 слайд.** Мөхәммәтгали Мәхмүдов мәдрәсәдә укыганда ул аеруча гарәп хәрефләре белән кулдан матур язу сәнгатендә зур сәләт күрсәтә. (портреты куела)

Шундый матур язу остасының берсе – безнең авылдашыбыз, Селәнгер авылында туып-үскән Мөхәммәтгали Мәхмүдов . Мәдрәсәдә укыганда ул аеруча гарәп хәрефләре белән кулдан матур язу сәнгатендә зур сәләт күрсәтә.

Укучылар, ә гарәп графикасында ничек языла?

***Җавап***. Гарәп графикасында хәзерге тәртиптә түгел, киресенчә, уңнан сулга языла. Һәр хәрефнең 4 төрле язылышы була: аерым, сүз башында, уртасында, ахырында.

***Укытучы***. Гарәп графикасына нигезләнгән иске татар язуында ничә сузык авазга гына билге булган?

***Җавап***. Гарәп графикасына нигезләнгән иске татар язуында өч сузык авазга гына билге булган: әлиф , уау, йа.

**3 слайд.** Гарәп графикасының үзенчәлекләре:

1) Гарәп графикасында хәзерге тәртиптә түгел, киресенчә, уңнан сулга языла. Һәр хәрефнең 4 төрле язылышы була: аерым, сүз башында, уртасында, ахырында.

2) Гарәп графикасына нигезләнгән иске татар язуында өч сузык авазга гына билге булган:әлиф, уау, йа.

3) Гарәп графикасында саннар сулдан уңга укыла.

***Укытучы***. Бик яхшы, укучылар. Хәзер әйдәгез уку күнекмәләрен тикшереп алыйк:

1) Хәрефләр укыла.

2) Кыска сүзләр укыла.
3) Тактада укучыларның исемнәрен яздыру.
4) Җөмләләр уку.
5) Диктант. Тикшерелә.

**4 слайд.** Гарәп графикасында язылган Г.Тукайның “Туган тел” шигыре

6) Г.Тукайның “Туган тел” шигырен бергәләшеп уку.

**5 слайд.** Гарәп графикасында язылган Г.Тукайның “Шүрәле” шигыре

7) “Милли моңнар” шигырен дәреслектән уку, карап китү. 65 нче бит.

***Укытучы.*** Яхшы, укучылар. Сез үзегезгә бирелгән биремнәрне үти алдыгыз. Дөрестән дә, гарәп графикасы татарларда 1005 ел кулланылышта булган һәм шул вакыт эчендә документлар, өндәмәләр, әсәрләр иске татар телендә әлеге графика белән язылган. Менә безнең мәктәпнең музеенда да гарәп графикасы белән язылган китаплар саклана. 1878 нче елгы китапта шигырьләр, хәдисләр урын алган, нindидер билгесез кешеләрнең үз куллары белән язылган язмалары сакланган һәм Уфа шәһәреннән бирелгән 1925 нче елда язылган Указны да күрә аласыз.

Мәктәпләрдә, уку йортларында гарәп графикасын уку программаларына кертү, димәк, ни өчен кирәк?

**Җавап.** Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, дигән әйтем яши татар халкында. Шуңа күрә без дә, үзебезнең тарихыбызны язма ядкарьләрдән белер өчен, гарәп графикасын да, латин графикасын да өйрәнергә тиеш. Бу язуда халкыбызның бик бай рухи мирасы саклана бит.

***Укытучы.*** Шулай булмаса, алтын язулы, көмеш-кургашын бизәкле, нокта, өтер урынына гөлчәчәкләр, "җир күзе", нәни борыч сурәтләре төшелгән изге язуларны халкыбыз элек-электән үк өйнең иң түренә, кашага өсләренә, ишек башларына элеп куймас; беләзек, йөзек, чулпыларга уелган хикмәтле сүзләрнең бәла-казадан, бәхетсезлектән саклавына, уңыш китерүенә ышанмас, аларны кадерләп сакламас иде.

Бүген шушы көннәргә кадәр сакланып килеп җиткән милли сәнгатебез үрнәкләрен кайларда күрергә мөмкин?

***Укучылар җавабы:*** бүгенге көндә без гарәп язулы борынгы дини китапларны очратабыз. Кабер ташларында, мәчет диварларында, саклагычларда, шәмаилләрдә күрә алабыз.

6,7,8 **слайдлар.** Кабер ташлары, мәчетләр, шәмаилләр. Укучылар, экранга игътибар итик.

***Укытучы*** Дөрес, укучылар. Шәмаилләрнең борынгыларын да очратырга була, ә менә 1990 нчы еллардан башлап шәмаилләр ясау белән аерым кешеләр шөгыльләнә. Менә без дә шәмаилләрнең төрле үрнәкләрен карап китик. ***(Укытучы күргәзмәдәге шәмаилләргә игътибар итәргә куша).***

Шәмаил нәрсә соң ул?

***Укучы*** Шәмаил – татар сәнгатенең үзенчәлекле, специфик төре. Ул шәһәр кешеләре тормышында да киң таралыш ала, авыл көнкүрешендә дә кирәкле элемент булып санала. Бер үк вакытта шәмаил халык аңында Аллаһы Тәгаләгә ышану билгесе буларак та кабул ителә. Татарларда борынгыдан ук Коръән сүрәләре, догалар язылган кәгазьләр бөти рәвешендә яисә кесәләрендә үзләре белән йөртелгән. Ә өй догалары китап киштәләрендә яки стенада эленеп торган махсус букчаларда сакланган. Шәмаилләргә беркайчан да табынмаганнар, алар ислам дине иконалары түгел. Алар Аллаһы Тәгаләгә барлыгын искә төшереп торган. Борынгы бабалардан калган традиция буларак, Коръәннән китерелгән сүзләргә хөрмәт, олылау белән караганнар.

**9 слайд.** Коръән рәсеме.

***Укытучы.*** Димәк, шәмаилләрдә Коръәннән сүрәләр язылган. Ә Коръән нәрсә ул?

***Укучы.*** Коръән ул – дини китап. Аның үзенчәлекле стиле, читләтебрәк кулланылган мөрәҗәгате, таныш булмаган хәл-вакыйгалар турындагы мәгълүматлары бар.

Коръән – тәрбия чарасы. Анда тугрылык, ихласлылык, юмартлык, сүз һәм гамәл берлеге, шәфкатьлелек, ата-ананы хөрмәт итү, сабырлык һәм шундый башка әхлакый сыйфатлар мактала, тискәреләре хөкем ителә.

***Укытучы.*** Укучылар бүген безнең дәресебездә “Мөхәммәдия” мәдрәсәсен тәмамлап. Институтта белем алган гарәп теле укытучысы Рушан абыегызга бирелә. Ул сезнең сүзне йомгаклап куяр.Сүз кунакка бирелә.

I. **Уку мәсьәләсен кую.** Азан тавышы яңгырый. Г.Тукайның “Коръән укысам” шигыре укыла:

**10 слайд.** “Коръән укысам” шигыре

*Нечкәрә күңелем, Коръән алып укысам, җаным киңәя,*
*Сәҗдәләргә ятам, тәсбих әйтәм, рухым ләззәтләнә, киләнә,*
*Китә күңелем тулган тау-тау кайгы, шәрк-зыйлләләрдән пакьләнәм,*
*Тәңремнән көтәм чиксез рәхмәт, әллә нәрсәдән сакланам.*

*Белмим, чынлап сорыйм: бу эшләрем якынлыкмы минем Аллага,*
*Мохтасар түгел, фәтва сормыйм, зәкятләрем дә юк, алдамам.*
*Җыелган да яшем, күзгә тула, шәһадәт сүрәсе шәүкыма,*
*Тәүкыйнадан сикереп “Аллаһу әкбәр!” дигән таушым чыга фәүкыма.*
*Һәр айәтдән көтәм әллә ниләр, күп өмидләремнең ачкычын,*
*Күңел күзгеләре ялтырый да, эзлим мин бәхетләр баскычын.*

**11 слайд.** Г.Тукай иҗатында Коръән мотивлары. ***Укытучы.*** Димәк, укучылар, без бүгенге дәресебездә гарәп графикасының татарлар арасында таралуының төп сәбәбе булган Коръәнгә бөек шагыйребез Г.Тукайның мөнәсәбәте турында сөйләшербез. Дәресебезнең эпиграфы итеп, Г.Тукайдан түбәндәге юлларны алыйк: “...Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин...”

**12 слайд.** “...Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин...” Г.Тукай кыска гына вакыт эчендә татар милләтенең сөекле шагыйренә әверелә. Моның сәбәбе – шагыйрьнең күп гасырлык бай әдәби традицияләребезгә таянуында. Әдәбиятка яңалык алып килүче реалист буларак танылса да, ул үзенең 7 буын мулла нәселеннән килүен яхшы белгәнгә, иҗатының бөтен тамырлары белән борынгы татар һәм көнчыгыш әдәбиятларына, Ислам мәдәниятенә барып тоташа. Кече яшьтән үк ул гади халыкның самими ышануларын сеңдереп, борынгы Ислам әдәбиятын укып үсә, шулар җирлегендә тәрбияләнә, ә соңрак иҗат итә.

Игътибар итегез, шагыйрьнең 1909 нче елда язган кулъязмасы.

**13-14 слайд.** Тукайның кулъязмалары.

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

Укучылар, хәзер әйдәгез Г.Тукайның сез алып килгән шигырьләрен карап үтик.

***1 нче укучы.*** “Тәәссер” шигырен укый. (Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр. ТаРИХ-2002, 183 нче бит).

Әлеге 1908 нче елда язылган шигырьдә сүз Аллага ышануның кеше күңеленә тынычлык, сафлык китерүе, авыр вакытларны җиңеләйтүе хакында бара. Ул М.Ю.Лермонтовның “Молитва” шигыренә ияреп язылган, ләкин, милли, дини әсәр буларак кабул ителә. Шигырь Алланың барлыгын тагын бер кат раслап, шуңа канәгатьлек белдереп, мөселманнарның теленнән төшми торган гыйбарәләр белән төгәлләнә.

***Укытучы.*** Рәхмәт. Алга таба дәвам итик.

***2 нче укучы.*** Г.Тукайның Коръәнгә ихтирамы, мәхәббәте чиксез зур була, ул аны укып әсәрләнә, аннан үзенә чиксез илһам ала. Мәсәлән, “Васыятем” шигырендә мондый юллар бар:

*Әһле тәгфир (динсезләр) бер гаҗәпләнсен күреп актык сүзем:*
*Күр, нә рәсмә тулган Иман берлә Коръән күңелемә.*

Күңеленә Коръән урнашкан шагыйрь иҗатында Коръәннән кергән сюжетлар, мотивлар зур урын ала. ( *“Кадер кич” шигыре укыла. )*

Бу шигырь турыдан-туры Коръәнгә барып тоташа. Ул “Кадер” дип аталган 97 нче сүрәне шагыйранә тасвирлап биргән.

Г.Тукай Коръәнне бик яхшы белгән. Хәтта ул аның кайбер сүрәләрен уңышлы гына тәрҗемә иткән.

**15 слайд.** М.Мозаффаров: : “Бервакыт әнием Тукайдан: “Менә Кадер киче җитә, балаларга җырлар өчен бер шигырь булмасмы, Габдулла?”-дип сорады. Тукай берничә көннән безгә: “Бу кадер кич – елда бер кич...”- дип башлана торган шигырен үз кулы белән язып, чәчәк ябыштырылган открытка алып килде”.

***Укытучы.*** Әлеге шигырьнең язылу тарихы турында әйтеп үтәсем килә. Композитор Мансур Мозаффаров болай дип язган : “Бервакыт әнием Тукайдан: “Менә Кадер киче җитә, балаларга җырлар өчен бер шигырь булмасмы, Габдулла?”-дип сорады. Тукай берничә көннән безгә: “Бу кадер кич – елда бер кич...”- дип башлана торган шигырен үз кулы белән язып, чәчәк ябыштырылган открытка алып килде”.

***3 нче укучы.*** 1909 нчы елны язган “Ана догасы” шигырендә улына Алладан бәхет сораучы ана образы тудырыла. Тыныч төнге авыл, йоклап беткән өйләр фонындагы намазлыкта утыручы карчык самими, ихлас чын күңеленнән Аллага ышанган, аңа омтылучы булып күз алдына килеп баса. Лирик геройның соңгы строфадагы соравы аның да догалар кабул булуына ышанычын раслау булып яңгырый.

***4 нче укучы****.* Г.Тукайны без “Таян Аллага” дигән шигыре өчен генә дә Ислам диненең иң зур сакчысы дип атар идек. Яшь балага шагыйрь һәр эшендә Аллага таянырга, аңа дога кылырга чакыра:

Кыйль дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугры юл бар гаршенә!

Яки менә шагыйрьнең “Алла яратсын өчен” шигыре. Бу шигырь кешене инсафлы, тугры, белемле булырга өнди. Тик шундый бәндә генә Тәңренең мәрхәмәтенә ия булыр, ди шагыйрь.

“Алла яратсын өчен” шигыре безгә конкрет киңәшләр бирә:

Без дә бер кешедәй дус булыйк,
Алла яратсын өчен;

Эрелек, төче теллелекне ташлыйк,
Алла яратсын өчен.

***Укытучы.*** Димәк, укучылар, нәтиҗә ясыйк. Шагыйрь иҗатында Ислам дине, Коръән нинди урын тоткан соң?

***Укучы.*** Г.Тукай өчен дин – яшь буынны тәрбияләү, гыйлем һәм мәгърифәт чарасы. Шуңа күрә дә ул үзенең кайбер шигырьләрендә динне пычратучы, диннән бары тик керем-файда гына эзләүче рухани-түрәләрне тәнкыйтьли дә. Әхлаксызлык, имансызлык кебек колакка начар яңгырашлы сүзләрдән ерак булу өчен без Габдулла Тукайның киңәшләрен тотарга, аларга колак салырга тиешбез

Коръән-кәримнең барлык өйрәтмәләренең дә кешегә дөрес юл күрсәтүенә иманы камил шагыйрьнең. Үзенең “Туган тел”, “Туган авыл” шигырьләрендә дә шуны искәртә Г.Тукай.

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәтне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.
(Туган авыл” шигыреннән).
И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам
Ярлыкагыл, дип үзем һәм эткәм-энкәмне Ходам. (“Туган тел”)

II. **Ныгыту.** Рәхмәт, укучылар. Бер дәрестә генә барлык шигырьләрне дә карап чыгу мөмкин түгел. Ләкин сез алып килгән шигырьләр аша да без Г.Тукай иҗатында Коръәннең урынын билгели алдык.

Шулай да Тукай иҗатыннан күп тәрбия алырга мөмкин. Аның башка темаларга язган шигырьләре укучыга әдәп-әхлак, экологик, хезмәт тәрбиясе бирә, туган ил, туган җир, милләт төшенчәләрен аңларга ярдәм итә.

Ә Коръән, дөрестән дә, күп язучыларны илһамландырган. Бөек рус язучысы А.С.Пушкин да изге китапка мөрәҗәгать итә.

**16 слайд/** Бог милосерд:Он Магомеду
Открыл сияющий Коран.
Да притечем и мы ко свету
И да падет с очей туман.

**Иҗади эш.** Г.Тукайның “Туган тел” шигырендә язган сүзләр дә шәмаил итеп элеп куярга мөмкин сүзләр. Әйдәгез, хәзер, дөрестән дә, әлеге шигырьнең үзегезгә ошаган өлешен язып карыйк. Ә сезгә гарәп теле белгече үзе ярдәм итәчәк. (Шәмаилләр ясауда гарәп теле белгече Билалов Р. ярдәм итә, тактага язып күрсәтә).

Дәвам итеп, Флера Ханнанованың “Тукай иҗатында дини мотивлар” мәкаләсеннән өзек белән танышыйк һәм бирелгән биремнәрне үтик.

1) *XX гасыр әдәбиятында тирән эз калдырган, аның үсеш юнәлешләрен билгеләгән классикларыбызның берсе ул - Габдулла Тукай. 2) Г.Тукай әсәрләре үз заманында ук зур уңыш казана.3) Кыска гына вакыт эчендә ул татар халык шагыйренә әверелә. 4) Бу хәлнең эстетик сәбәпләреннән берсе - Тукайның күп гасырлык бай әдәби мирасыбызга таянуында. 5) Моның белән ул әдәбиятыбызның күптәнге күркәм традициясен дәвам итте. 6) Эш шунда: Тукай яшәгән һәм иҗат иткән яңа заман татар әдәбияты үткән мираска - татар, көнчыгыш һәм, гомумән, мөселман мәдәнияты мирасына нигезләнеп формалашты һәм үсеп китте. 7) Безнең әдәбиятка ислам мәдәнияты йогынтысы турында сүз алып барганда исә без, беренче чиратта, әлеге мәдәниятнең иң зур казанышы булган Коръәнне күздә тотабыз. 8) Коръән болгар-татар әдәбиятына мең ел буена көч-куәт биргән, аңа идея- эстетик яктан юнәлеш бирүче якты маяк булган. 9)Коръән әдипләр* ***өчен*** *илһам чыганагы, гуманизмның, гаделлекнең, камиллекнең өлгесе булып хезмәт иткән. 10) Кол Гали, Рабгузыйлар традициясен актив дәвам итүчеләрнең берсе дә Габдулла Тукай булды. 11).Галимлек белән гадилекне үзендә чагылдырган зат буларак, Тукай үз заманына киң карашта торган, аның төрле якларына һәм мәсьәләләренә объектив карый алган. 12). Шушы хәл Тукайның дингә мөнәсәбәтендә дә ачык чагылган.*

1 нче өлеш.

А 27. Текст татар әдәби теленең кайсы стилендә язылган?

1) публицистик стильдә
2) матур әдәбият стилендә
3) хатлар стилендә
4) рәсми стильдә

А 28. Текстның эчтәлегенә туры килгән мәкаль-әйтемне сайлап алыгыз.
1) Туй беткәч, сүз күбәер.
2) Каз канаты каләм булыр.
3) Эш күрсәткән ирне ил онытмас.
4) Туганыңа сөенмә, торганыңа сөен.

А 29. 6 нчы җөмләдә ике нокта куелу сәбәбен табыгыз
1) Гомумиләштерүче сүз янында
2) Иярчен кушма җөмләдә бәйләүче чараны күрсәтә
3) Ия белән хәбәр арасына
4) Аныклагыч янында

А30. 3 нче җөмләдә логик басым кайсы сүзгә (сүзләргә) төшә?
1) Кыска 2. Халык шагыйренә 3. Әверелә 4. вакыт

*2 нче өлешне эшләү тәртипләре искә төшерелә.*

В1. 7 нче җөмләдән ирен гармониясенә караган сүзне күчереп алыгыз.
В2. 1 нче җөмләдән рус теле аша кергән сүзне күчереп алыгыз.
В3. 11 нче җөмләдән ясалма исемнәрне табыгыз.
В4. 9 нчы җөмләдә аерып бирелгән сүзнең төркемчәсен билгеләргә.
В 5.Текстта кереш сүзләр кулланылган җөмләләрнең санын үсә бару тәртибендә күрсәтегез.
В 6. Текстта кушма сүз кулланылган җөмләнең санын күрсәтегез.
В7. Ия белән хәбәр арасына сызык куелган очракка туры килгән җөмләләрнең санын күрсәтергә.
В8. Сан кулланылган җөмләнең санын күрсәтегез.

**V. Үзбәя. (**Укучылар үзләренең эшчәнлегенә анализ ясый.) Бүгенге дәрестә үзегезнең эшчәнлегегезне ничек бәяләр идегез?

**VI. Өй эше.** Әлеге текстка нигезләнеп, 150 сүздән дә ким булмаган әдәби-иҗади инша язарга.
1) Текст нәрсә турында?
2) Сез Г.Тукай турында ниләр беләсез?
3) Ни өчен ул Коръәнгә мөрәҗәгать иткән?
4) Сез үзегез нинди мөнәсәбәттә?

**VII. Рефлексия.** Бүгенге дәрестә нәрсәләр белдегез?
Үзегез өчен яңалык булырлык мәгълүматлар ишеттегезме?
Гарәп графикасын өйрәнү ни өчен кирәк?
Г.Тукай иҗатында Коръәннең урыны булганмы?

**17 слайд.** “Тукай ул –шәм, ерагайган саен яктыра гына бара”,-дигән иде Рабит Батулла

***Укытучы.*** “Тукай ул – шәм, ерагайган саен яктыра гына бара”, - дигән иде Рабит Батулла. Дөрестән дә, укучылар, Тукай бездән ераклашкан саен аның милләт өчен, яшь балалар өчен эшләгән эшенең зурлыгы тагын да яктырак булып күренә. “Үткәнен белмәгән халыкны киләчәге юк”,- диләр. Ә Тукай - безне үткәнебез, ерак тарихыбыз белән тоташтырып торучы күпер дә, яшәү кагыйдәләрен өйрәтүче зат та ул.

Ә ерак тарихларның кайтавазы булган, “халык күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс раушан көзгесе” булып сакланган, безнең көннәргәчә килеп җиткән милли сәнгатебезнең үзенчәлекле, кабатланмас булуын раслый.

## ЗАТЛАНЫШЛЫ ҺӘМ ЗАТЛАНЫШСЫЗ ФИГЫЛЬ ТӨРКЕМЧӘЛӘРЕН ГОМУМИЛӘШТЕРЕП КАБАТЛАУ.

(Татар төркеме. 7 нче сыйныф)

***Рамазанова Розалия Гарифулла кызы,***
***Коркачык гомуми урта белем мәктәбе***

**Максат:**

1. Укучыларның теманы ничек үзләштерүләренә контроль ясау, белемнәрен системалаштыру.
2. Өйрәнелгән кагыйдәләрне практикада куллана белүләренә ирешү, фигыль төркемчәләрен җөмлә эчендә таба белү, аларга морфологик – синтаксик анализ ясый белү күнекмләрен ныгыту,уйлау-фикерләү сәләтләрен, активлыкларын көчәйтү.

3. Укучыларга үзләрендә мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек, кешеләргә игътибарлы мөнәсәбәт кебек асыл сыйфатларны тәрбияләргә кирәклегенә төшендерү.

**Эшчәнлекне оештыру формалары:** фронталь, төркемнәрдә, парлап, индивидуаль.

**Җиһазлау**: индивидуаль карточкалар, тест сораулары, мәкаль язылган карточкалар, компьютер, проектор,экран, презентация.

**Материал:** Дәреслек : "Татар теле", 7нче класс, Р.Ә.Асылгәрәева, М.З.Зиннәтовна, Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2010 нчы ел.

**Метод һәм алымнар**: әңгәмә, өлешчә эзләнү, мөстәкыйль эш, тест.

**Дәрес тибы**: белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру дәресе.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше.** ***Уңай психологик халәт тудыру.***

Менә тагын яңа көн туды. Димәк, бу җирдә яшәүгә омтылышыбыз, теләгебез артты.

Яңа көн тууга, үзебезнең газиз җиребездә бик бәхетле булуыбызга тагын бер кат инандык. Әти-әниләребезнең, туганнарыбызның исән-сау булуына, сөекле туган мәктәбебездә белем алуыбызга тагын бер кат сөендек. Әнә шундый изге теләк-омтылышлар, сөенеч-шатлыклар белән дәресебезне башлап җибәрик әле.

**II. Дәреснең темасын һәм максатын билгеләү.** *(Укучылар ике баганага аерып язылган фигыльләрне тикшерәләр һәм теманы ачыклыйлар)*

Бүгенге дәрестә без фигыль сүз төркеме турындагы белемнәребезне ныгыту белән беррәттән шәфкатьлелек, игелеклелек турында да сөйләшербез.

**III. Өй эшләрен тикшерү.** Укучылар, дәфтәрләрдә өй эшләре үтәлгәнме?(Өй эшләре тикшерелә) 1 төркемнән 1 номерлы укучы язып килгән җөмләләрен укый,ә икенче төркем укучылары тикшереп бара.

**IV.Белемнәрне актуальләштерү**.

1.**"Саннар ни сөйли?" уены** (2 слайд)

Укучылар, сез математика дәресендә һәрвакыт саннар белән эшлисез. Әйдәгез әле,бүгенге дәресебездә саннарны татар теле белән дә бәйләп карыйк..

Мин сезнең игътибарыгызга саннар тәкъдим итәм. Әлеге саннар белән фигыль арасында нинди уртаклык бар?

3 нче слайд – **2** (фигыль ике төркемгә бүленә – затланышлы, затланышсыз, берлектә һәм күплектә килә, барлыкта һәм юклыкта килә, үткән һәм киләчәк заман хикәя фигыльләрнең 2 төре бар: билгеле һәм билгесез)

4 нче слайд – **3** (фигыль 3 заманда килә ала,)

5 нче слайд – **4** **(**затланышсыз фигыльләр дә,затланышлылары да 4)

6 нче слайд – **5** (фигыль юнәлешләре 5)

7 нчы слайд – **8** (фигыль төркемчәләре8)

Җавапларын дәлилләп тә баралар.

**2) Бирелгән модель буенча фигыльләр турында сөйләргә. (8 слайд)**

Укучылар парларга бүленәләр һәм кара-каршы партнерлар бер-берсенә сөйлиләр.

Һәр төркемнән 3 нче номерлы укучылар җавап бирәчәк.1 төркем ,сездән башлыйбыз.

- Фигыль нинди ике төркемгә бүленә?
- Фигыльләр затланышлы һәм затланышсыз була.
- Затланышлы фигыльләргә нинди фигыльләр керә?
- Хикәя, боерык, теләк, шарт фигыльләр затланышлы була. Алар зат-сан белән төрләнәләр.
- Рәхмәт. Затланышсыз фигыльләр турында 3 нче төркем сөйләр .Рәхим итегез.
- Сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив затланышсыз фигыльләр дип атала, ягъни алар зат-сан белән төрләнмиләр.

**V.Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.**

1. Хикәя фигыльләрне искә төшереп алыйк инде. Яшел төстәге биремдә язылып бетмәгән җөмләләр күрәсез. Сезгә аларны язып бетерергә кирәк булыр.

а) Хикәя фигыль ...., ..., белдерә.

б) Фигыльнең ...,... формалары бар.

в) Хикәя фигыль ..., ..., ... белән төрләнә.

г) Җөмләдә ... булып килә.

- Язып бетердегезме, балалар? 2 нче номерлы укучылар укып китәрләр.

**Нәтиҗә**. Хикәя фигыль эш яки хәлнең үтәлү-үтәлмәвен хикәяләп белдерә. Барлык, юклык формалары була. Хикәя фигыльләр зат-сан, заман белән төрләнә. Җөмләдә хәбәр булып килә. **Үзбәя.**

2.Дәвам итәбез Һәм экрандагы текстны укыйбыз.(9 слайд)

Ул нәрсәне белми? Юлда бер малай бер бабайны куып җитте. Бабай бик күп әйбер күтәргән .

- Әй бабай, - диде малай, синең бер китабың төшеп калды!

- Минем бар әйберем дә үземдә шикелле, ул минем китап түгелдер, - диде бабай.

- Юк-юк,синең китап ул, - диде малай, - мин карап килдем, синең өч китабың, бер портфелең һәм бер төенчегең бар иде, барысы биш кисәк әйбер.Ә хәзер кулыңда дүртәү генә…

- Һи, улым, син математиканы бик яхшы беләсең икән, - дип мактады бабай малайны. - Әмма син бер кагыйдәне начар үзләштергәнсең.

Малай нинди кагыйдәне начар үзләштергән? Астына сызылган фигыльләргә морфологик анализ ясагыз.

**Үрнәк:** Күтәргән-фигыль, затланышлы хикәя ф.,барлыкта,төп юнәлештә,билгесез үткән заман, 3 зат берлектә,хәбәр.

4 нче номерлы укучылар үз эшләрен укыйлар.**Үзбәя.**

3. Хәзер өстәлләрегездән сары төстәге биремне алыгыз. Анда кайбер сүзләре төшеп калган җөмләләр бирелгән. Сезгә ул җөмләләрне тутырып язарга кирәк булыр.

*Юеш кием белән ..., суык тия.*
*Телевизорны күп ... , баш авырта.*
*Тырышып..., күп беләсең.*
*Йокыдан вакытында ..., мәктәпкә соңга калмыйсың.*
*Иртә... , аш пешә; соңга ..., бит пешә.*

Нинди җөмләләр килеп чыкты икән, тыңлап карыйк әле.

*Юеш кием белән йөрсәң, суык тия.*
*Телевизорны күп карасаң, баш авырта.*
*Тырышып укысаң, күп беләсең.*
*Йокыдан вакытында торсаң, соңга калмыйсың.*
*Иртә торсаң, аш пешә, соңга калсаң бит пешә.*
*Йөрсәң, торсаң,укысаң, карасаң, калсаң* нинди фигыльләр алар?

- Бу фигыльләр – шарт фигыльләр.

-Димәк, шарт фигыльләр ничек ясалалар?(-са,-сә)**Үзбәя.**

4. Балалар, экранга күз салыгыз әле, анда нинди фигыльләр язылган? **(10 слайд)**

- *Бар, сана, эшлә, уйла*,җырла,йөгер.

-Болар боерык фигыльләр.

- Боерык фигыль нәрсә белдерә?

- Боерык фигыльләр эш кушуны, боеруны, чакыруны, өндәүне белдерә; зат-сан белән төрләнә; барлыкта яки юклыкта килә һәм җөмләдә хәбәр була. Аларны аңларга җөмләнең мәгънәсе, әйтелү интонациясе, кисәкчәләр ярдәм итә.

- Әйе, бик дөрес. Ә хәзер биткә-бит утырган иптәшегез белән парлашып эшлисез.Үзегез теләгән боерык фигыльне зат- сан белән төрләндерәсез.Кайсы затта килә алмый.Аны беренче затка куйсак ,ул нинди фигыльгә әйләнә?**Үзбәя.**

**5. Физкультминутка.** Мин сезгә фигыльләр әйтеп барам, шарт фигыль булса чүгәлибез, боерык фигыльгә кул чабабыз, хикәя фигыльдә урында басып кына торабыз:

**Барсам, укый, сана, барды, үтсәләр, йөгерә, чап, утыр, ташласам, кайта, әйтсә, бардым, күрсәң, тыңла.**

**IV. Укучыларны гомумиләштерелгән эшчәнлеккә әзерләү. Тиешле дәрәҗәдә яңадан үзләштерү (үзгәртелгән сораулар белән)**

*1. Дәресебезне дәвам итәбез. (Уйла-яз-фикер алыш)* ***(11 слайд)***

*Бирем.* Бирелгән фигыльләрне 4 баганага аерып языгыз.

Киләчәк (дус), коелган (алма), чабылган (болын), баручы (кеше), сызгыра торган (уклар), уйнап җибәрде, көлә-көлә бара, сөрткәч кипте, кайтканчы утырды, бирелеп тыңлый, сөйләшү, терелү, бизәшү, уйнау, алмау, сөртмәскә, сызарга, карарга, менмәскә, көләргә.

(биремне үтәгәч, тикшерү) **(12 слайд) Үзбәя**

- Хәзер нәтиҗә чыгарыйк. Сүзләрне ничек аердыгыз ?
- *Бирем.* Сыйфат фигыльләрнең заманын билгеләгез. Нәтиҗә ясыйбыз.
- *Хәл фигыльләрнең төрләрен әйтегез.* Нәтиҗә.
- *Исем һәм инфинитив фигыльнең* ясалышын аңлатыгыз. Нәтиҗә

**4. Белемнәрне үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү.(Өстәлдә кызыл биремнәр.)**

- Укучыларга ике вариантта төзелгән тест бирелә. Укучылар тест эшлиләр,аннан соң уң як күршесе белән алмашып, җавапларын тикшерәләр, билге куялар.

**1 вариант**

**А1. Боерык фигыль нәрсәне белдерә?**

- а) эшнең үтәүчегә мөнәсәбәтен
- б) эш-хәрәкәтнең шартын
- в) эш кушуны, боеруны

**А2. Кайсы рәттә билгеле үткән заман хикәя фигыльләр бирелгән?**

- а) кайта, барган, килгән
- б) барды, очты, карады
- в) көлсә, уйлар, эшли

**А3. Кайсы кушымчалар хәзерге заман хикәя фигыльнеке?**

- а) –ган/-гән, -кан/-кән
- б) –ар/-әр, -р
- в) –а/-ә, -ый/-и

**А4. Фигыльнең барлык-юклык формасы нәрсәне белдерә?**

- а)  эш-хәлнең һәрвакыт үтәлүен
- б) эш-хәлнең һәрвакыт үтәлмәвен
- в) эш-хәлнең үтәлү-үтәлмәвен

**А5. *Килүче, кайтучы, китүче* сүзләре нинди сүз төркеменә карый?**

- а) хәзерге заман сыйфат фигыль
- б) исем
- в) сыйфат

**А6. Хәл фигыльнең ничә төре бар?**

- а)  биш
- б) дүрт
- в) өч

**А7. Кайсы кушымчалар исем фигыльнеке?**

- а) –у/-ү
- б) –а/-ә
- в) –ый/-и

**А8. Кайсы рәттә инфинитивлар бирелгән?**

- а) чаба, үсте, сибәр
- б) алып, караучы, калса
- в) ашарга, төзергә, әйтергә

**А9. *Сизәбез, сизәсез, сизәләр* сүзләре нәрсә белән төрләнгән?**

- а) сан белән
- б) тартым белән
- в) зат-сан белән

**А10. Ничә затланышсыз фигыль төре бар?**

- а) биш
- б) дүрт
- в) өч

**II вариант**

**А1. Шарт фигыль нәрсәне белдерә?**

- а) эшне кайсы зат үтәвен
- б) эш-хәрәкәтне үтәүнең шартын
- в) эшнең үтәлү-үтәлмәвен

**А2. Кайсы рәттә билгесез үткән заман хикәя фигыльләр бирелгән?**

- а) барса, килсен, саный
- б) акты, сузачак, уйлар
- в) ауган, озаткан, алган

**А3. Кайсы рәттә билгесез киләчәк заман фигыльләр бирелгән?**

- а) сизгер, үткер, тапкыр
- б) камыр, сыер, сикер
- в) килер, барыр, санар

**А4. Кайсы кушымчалар хәл фигыльнең беренче төренеке?**

- а) –ып/ -еп, -п
- б) –ды/ -де, -ты/ -те
- в) –гач/ -гәч, -кач/ -кәч

**А5. Үткән заман хикәя фигыльнең нинди төрләре бар?**

- а) һәрвакыт билгеле
- б) билгеле һәм билгесез
- в) һәрвакыт билгесез

**А6. Ничә затланышлы фигыль бар?**

- а) өч
- б) дүрт
- в) биш

**А7. Исем фигыль килеш, тартым, сан белән төрләнәме?**

- а) төрләнми
- б) төрләнә
- в) кайберләре төрләнә

**А8. *Юган күлмәк* сүзтезмәсендә билгеләнгән сүз нинди сүз төркеменә карый?**

- а) үткән заман хикәя фигыль
- б) сыйфат
- в) үткән заман сыйфат фигыль

**А 9. Кайсы рәттә шарт фигыльләр бирелгән?**

- а) сатса, уйласа, китмәсә
- б) алыр, кага, укыды
- в) белеп, кигәч, күрәчәк

**А10. Нинди фигыльләр заман белән төрләнә?**

- а) хәл фигыль, сыйфат фигыль
- б) инфинитив, исем фигыль
- в) хикәя фигыль, сыйфат фигыль **(13 слайд)**

**Тикшерү.Үзбәя.**

**Иң игътибарлы укучы**

Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.
Һөнәр ашарга сорамый,үзе ашата.
Эш беткәч, уйнарга ярый.
-Ә хәзер тикшерегез. Бу җөмләләр ничек атала? (мәкальләр дип атала)

- Бу мәкальләрне нинди темаларга бүлеп була?
- Хезмәткә багышланган мәкальләр нәрсәгә өйрәтә?

**7. Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү**

- ***Тексттан фигыльләрне табыгыз*** ***(14 слайд)***
- "Тирә-ягыбызда караучысыз калган өлкәннәр, инвалидлар, ятимнәр, авыр хәлләргә очраган кешеләр яши. Алар безнең ярдәмгә мохтаҗ. Аларга ярдәм кулы сузу, игелек кылу - әхлакый бурычыбыз. Бер-беребезне кайгыртып яшик, бер-беребезгә игътибарлы булыйк. Р.Хәмитов
- 1 в. Тексттан фигыльләрне табып ,төркемчәләрен билгеләргә.
- 2 в. Фигыльләргә морфологик анализ ясарга.
- 3 в. Төрле фигыльләр кертеп,"Мохтаҗларга игелек кылу - изге бурычыбыз" темасына инша язарга.

**8. Рефлексия (дәрескә нәтиҗә ясау). Билгеләр кую.**

- Укучылар, дәрестә нәрсә эшләргә тиеш идек?
- Нәрсә башкардык?
- Нинди нәтиҗәгә килдек?
- (Һәр төркемнән укучылар дәрестә өйрәнгәннәр буенча җавап бирә)
- Бүгенге дәрестә без нинди сүз төркемен кабатладык?
- Алар ничә төргә бүленә?
- Нинди фигыльләргә затланышлы дибез?
- Алар ничә төргә бүленәләр?
- Затланышсыз фигыльләр дип нинди фигыльләр атала?
- Затланышсыз фигыльләргә нинди фигыль төркемчәләре керә?

Укытучы: Кадерле укучылар, дәресебезне йомгаклап шуны әйтәсем килә: күркәм холыклы, янәшәдәге талант ияләре үрнәгендә, эти-әнигә хөрмәтле, укытучы абый-апаларыгызга ихтирамлы булыгыз. Йөзегез ямьле, сүзегез тәмле булсын. Дәрестә катнашканыгыз өчен рәхмәт, укучылар.

## II НЧЕ БҮЛЕК. ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫ ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА СИНГАПУР СТРУКТУРАЛАРЫН КУЛЛАНУ

### АТА-АНА БЕРДӘМ БУЛСА, БАЛАЛАРЫ КҮРКӘМ ҮСӘ
### (М.Маликованың "Чәчкә балы" повестена анализ)

***Низамиева Әлфинур Нуретдин кызы,***
***Айбаш урта гомуми белем мәктәбе***

**Максат.** *1)дидактик:* М.Маликованың "Чәчкә балы" повестеның темасын билгеләү, сюжет, композиция, проблема, тел-стиль чаралары төшенчәләрен ныгыту, тирәнәйтү, идея эчтәлеген ачу, образларга характеристика бирү;

*2)үстерешле:* укучыларның проза әсәренә проблемалы-тематик анализ ясау, текст белән эшләү күнекмәләрен камилләштерү, тел-сурәтләү чараларын ачыклау, иҗади фикер йөртү, бәя бирү сәләтләрен үстерү;

*3)тәрбияви:* укучыларга әхлакый тәрбия бирү, авыл тормышы белән шәһәр тормышының аермаларына төшендерү, тормышта дөрес юл сайларга әзерләү, гаилә тормышы этикасы кагыйдәләре, татар халкының яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре турында белгәннәрен тирәнәйтү, әхлак кыйммәтләренең әһәмиятен ассызыклау, матурлыкка, сафлыкка омтылыш тәрбияләү.

**Җиһазлау һәм материаллар.** Экран, компьютер, проектор, китаплар күргәзмәсе. Д.Заһидуллинаның "Әдәби әсәргә анализ ясау", Г.Гыйльманов, Т.Миңнуллин, Р.Мөхәммәдиев, Ф.Дәүбаш, А.Әхмәтгалиева китаплары, афоризмнар, мәкальләр язылган плакатлар: "Ата-ана бердәм булса, балалары күркәм үсә", "Аталар сүзе – акылның үзе", "Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы үзгәртә алмас." (Р.Фәхреддин), "Бала балдан татлы да, баланнан ачы да була ала" (М.Мирза), "Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз", "Ана мәрхәмәте белән ата кырыслыгы – балаларга булган мәхәббәтнең ике канаты" (Ш.Галиев), "Балалар – хыял агачлары корымаган, өмет куаклары киселмәгән ышаныч бөреләре" (Р.Фәйзуллин) һ.б., авыл тормышын сурәтләгән рәсемнәр, умарта балы турында мәгълүматлар.

**Методлар һәм алымнар**. Сорау-җавап, әңгәмә, өлешчә эзләнү, сайлап уку, текст белән эшләү.

**Дәрес формасы.** Телевизион "Таяну ноктасы" тапшыруы.

**Дәрес төре.** Дәрестән тыш уку.

**Дәрес тибы.** Катнаш дәрес.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Предмет УУГ:*** әдәби әсәргә анализ ясау, текст белән эшләү, төп төшенчәләрне ныгыту.

***Шәхси УУГ:*** дөрес сөйләм булдыруга омтылыш; үз фикереңне әйтә белү; иптәшеңә рухи ярдәм күрсәтә белү; фикереңне дәлилли белү.

***Метапредмет УУГ:***

*Регулятив:* уку бурычын кую; ситуациядә аралаша белү; үз фикереңне төгәл җиткерү; дөрестән дөрес түгелне аеру; нәтиҗә формалаштыру;

*Танып-белү:* тиешле мәгълүматны табу һәм аеру; сорауларга җавап бирү; нәтиҗә формалаштыру.

*Коммуникатив:* башкаларның сөйләмен ишетү һәм тыңлау; үз фикереңә ышандыра белү; башкаларга аңлаешлы сөйләм төзү.

**Дәрес барышы**

**I. Белем алуга омтылыш булдыру.** (Укучыларның фикерен дәрескә туплау, уңай халәт тудыру). Хәерле көн, укучылар. Әдәбият дәресен, әдәп һәм тәрбия, тел дәресен башлыйбыз.

**II. Белем-күнекмәләрне актуальләштерү.**

**Укытучының ("Таяну ноктасы" тапшыруын алып баручы) кереш сүзе.** Укучылар, сез өегездә язучы М.Маликованың "Чәчкә балы" повестен укып килдегез. Авылда һәм шәһәрдә яшәүче яшьтәшләрегезнең тормышы белән таныштыгыз. Тагын бер елдан кайберләрегез шәһәргә китәр. Без тикшерәсе әсәр геройлары кебек, сезгә дә тормышта хыялларыгызны чынга ашырырга туры киләчәк. Билгеле, сезгә бу эштә эти-әниләрегез ярдәм итәчәк. Автор бу повесте белән безгә нәрсә җиткерергә тели икән, шуны белергә тырышыйк, укучылар. Иң беренче авторның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышып үтик. *(Бер-ике укучы язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында чыгыш, проект эше яки блогы белән таныштыру әзерләргә мөмкин. Язучының биографиясе "Кушымта" да бирелә).*

**III. Уку мәсьәләсен кую.** Хәзер әсәрне анализлауга күчик, шулай ук повестьта күтәрелгән проблемаларга тукталырбыз, геройларга бәя бирербез, әсәрнең сәнгатьчә эшләнешен күзәтербез.

**IV. Уку мәсьәләсен чишү.** Куелган сорауларга җавап табу, биремнәрне үтәү, фикерләрне исбатлау аша бара.

**Укытучы.** Укучылар, әсәрнең әдәби төрен, жанрын билгеләргә кирәк.

**Укучы.** “Чәчкә балы” – эпик әсәр, повесть жанры, чөнки геройлар язмышы, алар белән бәйле вакыйгалар сурәтләнгән. Әсәрнең төп герое берәү генә – Гамил.

**Укытучы.** Ә хәзер, укучылар, әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйлибез, ягъни сюжетын күз алдына китерәбез. Яле, Гөлия, син сөйли башла.

**Укучы.** Авылда яшәүче Гамилнең хатыны Сәгъдия ире аркылы сеңлесе Сәриягә чәчкә балы биреп җибәрә. Подъезд төбендә яшүсмерләр, акчасын талау максатыннан, Гамилне кыйный башлыйлар. Берсе аның йөрәк турысына пычак кадый. Яшүсмерләр качалар, ә Гамил җирдә ятып кала. Бераздан ул аңына килә, урамда күргән кешеләр аны балдызының квартирасына кертәләр. Балдызы Сәрия аптырап һәм куркып китә. Гамил балдызына дөресен әйтми, ташка егылдым, ди. Сәрия беренче ярдәм машинасын чакырта. Врачлар белән милиция дә килеп җитә. Сәрияне – милиция бүлегенә, ә Гамилне больницага алып китәләр. Пычак кадаучы Сәрия дип уйлыйлар. Сәрия милициядә гариза язганда, Гамил улына охшаган яшүсмерне күрә. Ул Макар була.

**Укытучы.** Шәүкәт, син дәвам итәрсең.

**Укучы.** Гамил белән Сәгъдия ике ул үстерәләр. Олы уллары Җәмил ни Гамилгә, ни Сәгъдиягә охшамаган. Сәгъдиясе белән үзенә охшамаган баланы, шикләнсәләр дә, “менә дигән итеп” тәрбиялиләр. “Зөфәр кебек кызыл чәчле булса да, чирләшкә булса да” яраталар, аякка бастыру өчен бик күп көч куялар. Кешеләр сүзен дә күтәрәләр. Урамда, үзенә һөҗүм иткән яшьләр арасында, үзенең Газименә охшаган малайны күргәч, ул бөтенесен дә аңлап ала. Бәби табу йортында алышынган бала бит бу. Милициягә дә, хатынының сеңлесенә дә дөресен әйтмичә малайны яклый, өенә алып кайта, тәрбияли башлый. Әйткән сүзендә тора. Көчен дә, акчасын да кызганмый. Макар Гамилнең акчасын урлый да, машинасына утырып, шәһәргә китә. Бу акчага ул наркотик сатып ала. Макар авариягә эләгә, аны хастаханәгә салалар. Врачлар аның наркоман булуын беләләр. Наркоман икәнен белгәч тә ташламый Гамил Макарны. Әкренләп малайның күңеленә ышаныч кайта. Үз гомерендә эчү, сугышу, җәберләү, начарлыкны гына күргән малай, монда икенче тормыш барлыгын күрә һәм терелә дә. Моңа бал кортлары, бер-береңә ышаныч, хөрмәт һәм мәхәббәт ярдәм итә.

**Укытучы.** ”Чәчкә балы” әсәренең темасын ачыклап булыр, дип уйлыйм, укучылар? Нәрсә ул тема, искә төшереп алыйк. ***(Укучылар җавап биргәннән соң, 3 слайдта күрсәтелә. )***

**Тема** – әдәби әсәрнең нигезендә ята торган вакыйгалар, предметлар, күренешләр бөтенлеге. Икенче төрле әйткәндә, тема әдәби чагылдыру объектын, ягъни әсәр язу өчен җирлек хасил иткән тормыш күренешләрен үз эченә ала.

**Укучы.** Әсәрнең темасы: гаиләдә ир белән хатын мөнәсәбәте, бала тәрбияләү. Хикәядә төп образ – Гамил, ярдәмче геройлар – хатыны Сәгъдия, балалары, балдызы Сәрия, катнашучылар – Зөфәр, Геннадий, аның хатыны, милиция хезмәткәрләре, врачлар һ.б.

**Укытучы.** Әсәрнең композициясе турында нәрсә әйтеп була? Композиция, сюжет дип нинди төшенчәгә әйтәләр? ***(Укучылар җавап биргәннән соң, 4 слайдта күрсәтелә. )***

**Композиция** – әдәби әсәр өлешләрен бербөтен оештыру, аның төзелеше ул. Композиция ике төрле була: текст композициясе һәм әсәрдә сурәтләнгән дөнья композициясе. Соңгысы үз эченә әсәр персонажларын, сюжетны, әдәби детальләрне дә ала. Шуңа күрә “персонажлар композициясе”, “сюжет композициясе” дигән төшенчәләр яшәп килә.

Персонажлар композициясендә язучы әсәрдә катнашучыларны һәм каршылык, һәм охшашлык принцибына карап урнаштырган, дип әйтергә була.

**Сюжет композициясе –** әсәр сюжетының өлешләрен урнаштыру.

**Укучы.** “Чәчкә балы” әсәрендәге сюжет композициясенә, традицион төстә, сюжетның төп өлешләре буларак, экспозиция (Гамил белән Сәгъдиянең тигез мәхәббәтләре, авылда яшәүләре, нинди эш белән шөгыльләнүләре, балалары белән танышу), төенләнеш (билгесез үсмерләрнең Гамилгә пычак кадаулары), вакыйгалар үстерелеше (Гамилнең беркемгә сиздермичә эзләнүе, күп нәрсәләрне ачыклавы), кульминация (үз улы Макарның чит гаиләдә үсүе, үзләренең чит бала үстерүләре), чишелешне (Макар-Мохтарның наркотиктан арынуы, аларның бер гаилә булып яшәүләре) аерып чыгарып булыр иде. Моннан тыш, әсәрдә төп образның рухи дөньясын сурәтләүгә зур урын бирелгән. Әсәрнең композиция элементларына хикәяләү (автор сөйләве), характеристика, риторик сораулар, диалог, эчке монолог, әсәрнең проблемалы сорау белән тәмамлануы әсәрне

бербөтен итә, укучыга тәэсир итү көчен арттыра, укучыга уйланырга куша. Китап төенләнештән башлана. Пролог, эпилог юк.

**Укытучы.** Әсәрдә хронотоп нинди? ***(5 слайдта күрсәтелә, аңлатыла. )***

**Хронотоп –** әдәбиятта чагылдырылган бербөтен урын һәм вакыт хакындагы күзаллау, әдәби әсәрдә сурәтләнгән дөньяның әһәмиятле өлешләре.

**Укучы.** Китап 2003-2004 нче елларда язылган. Әсәрдә 20 нче гасырның соңгы ун елы һәм 21 нче гасыр башында авылда һәм шәһәрдә булган вакыйгалар сурәтләнә. Совет чоры фаш ителеп, базар мөнәсәбәтләренә күчкән вакытта колхозлар таркала, завод-фабрикалар ябыла. Геннадий Харитонов кебекләр, заманага сылтап, эшсез калалар; Гамил кебек авыл кешеләре яңа шартларда да югалып калмыйлар. Ә Зөфәр сыманнар законнарны үз якларына боралар. Халыктан ваучер дигән кәгазьләрне ипилек акчага җыеп, шулар бәрабәренә зур-зур завод-фабрикаларга хуҗа булалар. Зөфәр бер мөмкинлекне дә кулыннан ычкындырмый. Нәтиҗәдә коттеджлар салдыра, олигархка әйләнә.

Әсәрдә авыл кешеләренең хезмәт итеп яшәве бирелә, монда һәр гаилә – игътибар үзәгендә, бигрәк тә малае үзенә охшамаган Гамил тормышы. Авыл кешесе гайбәт сөйләсә дә, ярдәмчел дә була белә.

Әсәрнең теленнән дә хронотопны билгеләп була. Кыйммәтле, затлы чит ил машиналары һәм аларның исемнәре безнең илгә базар мөнәсәбәтләре урнашканда керә башлады. Чит илдән яхшы белән бергә начарлыклар да керде. Наркомания – шуларның берсе.

**Укытучы.** Бу әсәрдә психологизм ничек бирелә? ***(Укучылар җавап биргәннән соң, 6 слайдта күрсәтелә.)***

**Психологизм –** персонажның эчке дөньясын, ягъни хисләрен, фикерләрен, кичерешләрен, теләк-омтылышларын матур әдәбиятның үзенчәлекле чаралары-алымнары ярдәмендә мөмкин кадәр тулы, җентекле һәм тирән итеп сурәтләүне күздә тоткан эчтәлек-форма категориясе.

**Укучы.** Психологизм – әдәбиятта милли үзенчәлек бик ачык күренә торган өлкә ул. Татар әдәбиятында психологизм ислам дине белән бәйле рәвештә кешегә үзенчәлекле караштан килеп чыга. “Чәчкә балы” повестенда кешенең эчке күңел кичерешләре бик оста бирелә. Олы уллары Җәмил этисенә (Гамилгә) охшамагач, Гамил дә, Сәгъдия дә эчтән генә сызланалар, ләкин сиздермиләр. Авыл халкы нәрсә генә сөйләсә дә, алар бик сабыр булып чыгалар. Дөрес, язучы ирнең дә, хатынның да уйларын укучысына җиткерә, безне уйланырга мәҗбүр итә, укучы ир белән хатынның хәленә керә, бәхетле гаиләгә уңышлар тели. Заман шаукымына бирелмичә, зур акчаларга кызыкмыйча яшәргә, балалар үстерергә, аларга дөрес тәрбия бирергә көч таба бер-берсен сөйгән ир белән хатын. Алар рухи яктан бай, бер-берсенә итагатьле, сабыр, кайбер хисләрне яшерә беләләр. Язучы Гамилне бик ипле ир итеп бирә. Татар гаиләсе шундый булырга тиеш тә.

Әсәрдә балаларның күңел кичерешләре дә бик тәфсилләп язылган. Автор 13-14 яшьлек балаларның психологиясе, үзләрен тотышы белән яхшы таныш.

**Ф и з к у л ь т м и н у т к а**

**(МИКС-ФРИЗ-ГРУП ка биремнәр кушымтада)**

**Укытучы.** М. Маликова әсәрдә нинди тел-сурәтләү чаралары куллана? ***(Укучылар җавап биргәннән соң, 7, 8 нче слайдта күрсәтелә. )***

“Стиль төшенчәсе бүгенге әдәбият белемендә ачыкланып бетмәгән категорияләрдән санала. Стиль – әдәби белдерү алымнары һәм чараларның бөтенлеге ул... Әдәби әсәр стилен анализлау өчен, әдәби әсәрдә стиль хасил итүчене ачыкларга кирәк. Алар, тышкы форма һәм эчке форма элементларына бүленә. Тышкы форма ул – әсәрнең иң беренче күзгә ташлана торган яклары.

Интонация – стиль бөтенлеген күрсәтүче доминанта. Ул – сөйләмнең аһәңе, тизлеге, яңгырашы.

1. Лексик чаралар – дөрес сайлау һәм урынлы куллану аркасында сурәт тудыручы сүзләр. Аларга синонимнар, антонимнар, омонимнар, сүз уйнату, архаизм, неологизм, гади сөйләм сүзләре, вульгаризм, жаргоннар, диалектизмнар, һөнәрчелек сүзләре, алынма сүзләр, калькалар һ.б. керә.

2. Троплар – күчерелмә мәгънәне төрле әйберләр, күренешләр, предметлар арасындагы бәйләнеш аша барлыкка китерә торган гыйбарәләр.

3. Стилистик фигуралар.

4. Фонетик чаралар да шигърияттә, сирәгрәк кенә прозада күзәтелә.

**Укучылар.** Теләсә кайсы әдәби әсәр нинди дә булса стильгә ия. Әсәр стиле һәм язучы стиле дигән төшенчәләр бар. Татар әдәбиятында М.Маликованың үз язу стиле бар, аны беркем белән дә бутарга мөмкин түгел. Әдипнең әсәрләрендә милләт турында кайгыртучанлык, рухи байлыкларны саклау бар. Ул язучы гына түгел, телче дә.

“Чәчкә балы” повесте **лексик чараларга** – сурәт тудыручы сүзләргә бик бай. Әйтик, әсәрдә түбәндәге архаизмнар һәм диалекталь сүзләр кулланыла: һиммәт (тырышлык), маһир (оста), хәлбуки (хәер), чәрексез (түземсез, чыдамсыз) һ.б. Язучы **синонимнар**дан оста файдалана. Мәсәлән, хак-

дөрес, тупас-дорфа, үтемле-аңлаешлы, ирекле-бәйсез, эчкерсез-ихлас, чиста-саф, ыржаю-көлү, түш-күкрәк, борчу-хәсрәт, җылы-назлы (контекстуаль синоним) һ.б. **Антонимнар** да күзәтелә: карчыга-тургай (контекстуаль антоним), иртә-кич, ачылу-ябылу һ.б. Геройларның ничек тәрбияләнгәнен, кемнәр белән аралашканын күрсәтү өчен, язучы жаргоннар да куллана: кореш һ.б.

**Троплар** – тел-сурәтләү чараларының икенче төре. **Фразеологизмнар** да, **әйтемнәр** дә язучы тарафыннан бик уңышлы кулланыла. Мәсәлән, курыккан куян арыслан өстенә сикерә, уртак малны эт җыймас, баш әйләндергеч, кул арасына керү, бүре баласы бүреккә салсаң да урманга карый һ.б. Әсәрдә М.Маликова бик матур **чагыштыруларн**ы файдалана: кызган тимердәй, өермәгә эләккәндәй, яңадан тугандай, үсмер кыздай, чыпчык кебек хәрәкәтчән, һушын җуйгандай, энҗе бөртекләре кебек. Әсәрдә **эпитетлар** һәм метафоралар, сынландырулар да күп: күркәм холык, зәгыйфь тавыш, йомшак кара канат, серле караңгылык, ала-кола болын, ләззәт диңгезе, сагышлы юл, иркен дөнья, тормышның бозлы давылы, канатлы кеше күңеле, эшем кешесе, җил бөтереп ала һ.б.

**Стилистик фигуралар, поэтик синтаксис** – сурәтләүнең өченче төре. Язучы әдәбиятта иң күп очраучы чараны үзенә хас булганча куллана. Әсәрдә кабатлаулар бар, инверсия күренешләре дә күзәтелә. Мәсәлән, “Кәттә егетләрне күргәнче, Харитонов белән сөйләшергә булды Гамил”, “Чәчкә балына коенгансың бит син”, “Булмаячак рәхәт тормыш”, “Кирәкми беркемнең киңәше”. Язучы кулланган **синтаксик берәмлекләр**не дә күрсәтеп китүне кирәк дип саныйм. Әсәрдән аныклагычлар, кереш сүзләргә мисаллар алырга була. **Аныклагычлар**: өлкән малайда – Җәмилдә, Җәмилнең җан дустына – Аккаш байталга һ.б. **Кереш сүзләр:** ниһаять, хәлбуки, әлбәттә, чыннан да.

**Укытучы.** Укучылар, әсәрдә нинди проблемалар күтәрелә? Проблема төшенчәсен искә төшерик әле. ***(9 слайдта күрсәтелә, аңлатыла.)***

**Проблема –** әдәби әсәрдә катлаулы-каршылыклы вакыйгалар, характерлар мисалында образлы фикер йөртү логикасына нигезләп куелган мәсьәлә, гомуми әһәмиятле сорау.

**Укучылар.** (Бу сорау бөтен укучыга да алдан бирелгән иде). Китапта күп проблема күтәрелгән, иң әһәмиятлеләренә тукталабыз.

*1. Гаилә һәм гаиләдә балаларны тәрбияләү проблемасы.* Авылда яшәүче Гамил гаиләсе бөтен авылга үрнәк булып тора. Алар киң күңелле, ярдәмчел, кайгыртучан. Балаларына да дөрес тәрбия бирәләр. Шәһәрдәге гаиләдә бөтен эшне хатын-кыз эшли, ире эшсез калгач, гаиләне туйдыру да хатын җилкәсендә кала. Бу гаиләдә бала бернинди тәрбия алмый.

2. *Яшүсмерләрнең спиртлы эчемлекләргә һәм наркотикларга тартылуы.* Дөрес тәрбия алмаган Макарны да сагалап тора бу афәт.

3. *Катнаш гаилә проблемасы, мондый гаиләдә баланың дөрес тәрбияләнмәве.*

4. *Эчкече ата-анадан сау-сәламәт бала тумавы.*

5. *Табибларның игътибарсыз булулары.* Аларның ваемсызлыгы аркасында балалар чит гаиләдә үсәләр, Гамил, тыштан сиздермәсә дә, эчтән бик борчыла, хатынын хыянәт иткән дип уйлый. Гаиләне таркатмый, сабыр була, уйларын кешегә сиздерми.

6. *Шәһәрдәге эшсезлек проблемасы* күтәрелә бу әсәрдә, ә эш булмау – күп начарлыкларның башы.

7. *Бу әсәрдә тагын актуаль проблемаларның берсе – ул тату гаилә, ир кешене хөрмәт итү, чын татар хатыны була белү һәм хезмәтне ярату.* Хәзерге заманда Зөфәр кебек байлык артыннан куучылар да, Харитоновлар кебек эчкечеләр дә җитәрлек. Болар безнең замана өчен типик образлар, ә менә Гамил белән Сәгъдия кебек кешелекле, бер-берсен ярты сүздән аңлый торган тату гаиләләр күп түгел. Нәфесләрен тыя белмәүчеләр, ялкау булганга, начар яшәүчеләр бар. Кешеләр, байлык артыннан чабып, рухи байлыкны югалталар. Шуның аркасында балаларыбыз да газаплана, игътибар җитмәүдән, яратмаудан төрле ялгыш юлларга кереп китәләр. Ә хатын-кызларыбыз нинди! Тәмәке тарталар, аракы эчәләр, ирләрен хөрмәт итмиләр.

Автор, бу проблемаларны күреп, бик борчыла. Һәм, аныңча, проблемаларны чишү өчен, гаиләләрдә терәк булырлык, ышанычлы ирләр кирәк. Ирләрен яратучы, хөрмәт итүче, сөйкемле һәм акыллы хатын-кызларыбыз кирәк. Шундый гаиләләрдә тәрбияләнгән балалар гына сау-сәламәт, үз-үзенә ышанучан һәм нәселне яхшы дәвам итүчеләр булачак.

**Укытучы.** Язучы нәрсә әйтергә тели? Сездә бу әсәр нинди тәэсирләр калдырды? Нинди геройлар, вакыйгалар ошады?

**Укучылар.** Бу әсәре белән язучы яман юлга баскан үсмернең яхшы якка үзгәрә алуын дәлилли. Ярдәмчел, ачык йөзле, яхшы күңелле кешеләрнең күбрәк булуын исбатлый. Мәсәлән, Гамил. Нинди генә күңелсезлеккә юлыкса да, гел кешелекле булып кала белә Гамил. Байлыгы ташып тормаса да, ходай аңа эчке матурлыкны, гүзәллекне мул биргән: ул күркәм холыклы, ипле ир. Әйе, менә шушы хакыйкатьне белү, серле-тирән җанның серләренә төшенү – әсәрне укучының эше.

Миңа Гамилнең шундый җаваплы булуы, кеше баласын үз итүе ошады. Ә Гамилнең уллары тәртипле, ата-аналарының сүзләрен тыңлый торган, эшчән балалар булып үсәләр, ата-ана сүзенең тәмен тоеп, ул сүзнең кадерен белеп яшиләр.

Балалар ата-аналарыннан үрнәк алалар, шуңа күрә ата-аналар үзләрен яхшы яктан күрсәтеп, дөрес тәрбия бирергә тиеш. Әти-әни балаларына кечкенә вакыттан ук нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнен аңлатырга тиешләр.

Автор яшәешнең мәгънәсен яхшылыкка, матурлыкка хезмәт итүдә күрә. Гамил нык ихтыярлы кеше буларак күз алдына килеп баса. Аның өчен гаиләсе, уллары беренче урында тора.

Әсәр балаларга да, олыларга да укырга җиңел һәм мавыктыргыч. Һәр кеше бу повестьтан үзен борчыган мәсьәләне һәм аңа җавапны таба ала. Әсәр бик тормышчан.

Китапта "туган җир", "туган нигез" төшенчәләренең кадер-хөрмәтен күрсәтү, әһәмиятен аңлатуга да урын бирелгән. Шәһәргә киткән Гамил кире авылына кайта һәм беркайчан да үкенми. Туган йорты, нигез ташлары аны авыр елларда фәкыйрьлектән коткара, балаларына – сихәт, үзенә куәт, ныклык бирә.

**V. Рефлексия. Укытучы.** Сезгә бу дәрес файдалы булдымы? Ни өчен? Сез авырлыклар кичердегезме? Аларны җиңеп чыгарга нәрсә булышты? Үзегезнең эшегезне ничек билгелисез?

**VI.Өй эше бирү.** Дәрестән тыш укуны дәвам итәргә, көчле укучыларга язмача анализ әзерләргә, йомшак укучыларга тел-сурәтләү чараларын табарга.

**VII. Дәресне йомгаклау.**

**Кулланылган әдәбият**


1. Бәширов Ф."Сөйлә, каләм!".– Казан:Татар.кит.нәшр., 2001 – 144 б.
2. Заһидуллина Д. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: "Мәгариф" нәшр., 2005. –112 б.
3. Заһидуллина Д. "Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы". – Казан: "Мәгариф" нәшр., 2004. – 367 б.
4. Маликова М. "Югалган якутлар". – Казан: "Рухият" нәшр., 2007. –400 б.
5. Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: "Мәгариф" нәшр., 2008. – 455 б.


**Кушымта**

1. Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Мәдинә Габделхак кызы Маликова 1935 елның 5 августында Татарстанның Сарман районы Мортыш Тамагы авылында игенче гаиләсендә туа. Үз авылларындагы җидееллык мәктәпне тәмамлап, 1949-1959 елларда башта Татарстанның Минзәлә шәһәрендәге педагогия училищесында, аннары Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында укый. Институтны тәмамлагач, 1959-1964 елларда «Чаян» журналында – корректор, 1964 елдан «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналында – әдәби хезмәткәр, ә 1978 дән 1987 елгача журналның җаваплы сәркәтибе булып эшли. Аның әдәби иҗат юлындагы беренче адымнары да журналистик язмалардан – көндәлек матбугат өчен хәбәрләр, документаль очерклар, мәкаләләр язудан башлана.

Ул елларда М.Маликованың очерклары, сәнгатькә, әхлак темаларына багышланган язмалары җәмәгатьчелектә киң яңгыраш таба, журналда басылган беренче хикәяләре, повестьлары да укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. Язучыны бигрәк тә яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләр, гаилә һәм тәрбия проблемалары, кешенең җәмгыятьтәге урыны, бурычы, хезмәткә карашы мәсьәләләре кызыксындыра. Бу темалар, күпсанлы очеркларында, мәкаләләрендә конкрет яктыртылудан тыш, язучының әдәби әсәрләре – хикәя-повестьлары һәм романнарының да төп эчтәлеген һәм идея юнәлешен тәшкил итә. 1967 елда басылып чыккан «Юлдашлар» исемле беренче хикәяләр җыентыгында ук автор укучы алдына тирән әхлакый мәсьәләләрне җитди итеп куярга омтылуы белән игътибарны җәлеп итә. Табигатькә, әйләнә-тирә мохиткә мөнәсәбәт яктылыгында яшүсмер кызның самими образын гәүдәләндергән «Кар сулары» лирик хикәясе, шундый ук лирик тонда язылган «Сары тюльпаннар», «Көндәшләр», «Ай сүрелгән чак иде», «Узма, гомер!», «Берәгәйле бәрәңге» һ.б. хикәяләр моның ачык мисалы булып тора. Язучының «Казан каласы – таш кала» (1967), «Кояш күпере» (1973), «Янар таулар яктысында» (1977) повестьлары, «Шәфкать» (1985), «Басып сайрар талы бар» (1987), «Фидая» (1990) романнары шәһәр һәм авыл интеллигенциясе – инженерлар, архитекторлар, рәссамнар, табиблар, артистлар тормышына багышлап язылганнар.

Язучы каләме, заман тормышының төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп, әсәр каһарманнарының рухи дөньясын бөтен тирәнлеге, каршылыклары белән яктыртырга, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулы нечкәлекләрен, нокталарын ачарга омтыла, яшәешнең төп мәгънәсе һәм максаты турында укучы белән җитди әңгәмә алып бара. Соңгы елларда иҗат ителгән «Кызыл гөл» (2005), «Тылсым» (2006), «Тылсым. Шәфкать» (2007) романнарында бу ачык чагыла. М.Маликова – каләмен детектив әсәрләр жанрында да чарлаган әдибә. Аның «Хөкем» (1969), «Августның беренче кичендә» (1970), «Адашканга юл кайда» (1971), «Югалган якутлар» (2003), «Чәчкә балы» (2004)

исемле маҗаралы повестьлары, «Өермә» (2002) исемле детектив романы, «Кыргый дивизия» (2001) кебек хикәяләре, жанр хасиятләре таләп иткәнчә, мавыктыргыч, киеренке агышлы вакыйга-сюжетка корылганнар. Гомумән, М.Маликова сюжетны оста, мавыктыргыч итеп кора белә, вакыйгаларны, йөрәк аша үткәреп, укучының күңел кылларын тибрәндерерлек итеп тасвирлый.

М.Маликова драматургия өлкәсендә дә уңышлы эшли. Аның «Оҗмах балалары» исемле драмасы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела (1990), «Йөрәк ничек түзсен», «Моңнар төште башыма», «Синең өчен үзем үләрмен» исемле драма әсәрләре узган гасырның туксанынчы елларында Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә уңыш белән бара.

Татарстан язучылары корылтайларында дүрт тапкыр (1979, 1984, 1989, 1994) Язучылар берлеге идарәсенә әгъза итеп сайлана, ә 1989-1990 елларда идарә рәисенең урынбасары булып эшли. Матбугат һәм мәдәният өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1976 елда Татарстанның, ә 1985 елда «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә, ул шулай ук Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге бүләге лауреаты (1980).

М.Маликова – 1972 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

**2.** МИКС-ФРИЗ-ГРУПка сораулар:

1) сюжетның төп элементлары ничәү? (5 әү);
2) әдәби әсәрнең ничә төре бар? (3 әү);
3) стиль сүзендә ничә аваз бар? (4 әү)

## ЯМЬЛЕ ҖӘЙ ҖИТТЕ

(дәрескә технологик карта, 4 сыйныф, рус төркеме)

***Әбүбәкерова Рәмзия Әфләтун кызы,***
***Чернышевка гомуми урта белем бирү мәктәбе***

***Татар теле дәресенә технологик карта*** федераль дәүләт стандартлары таләпләренә туры китереп төзелде. Яңа стандарт таләп иткәнчә, укыту-тәрбия процессының асылы махсус белем һәм күнекмәләр тәэмин итүгә юнәлтелгән универсаль гамәлләр формалаштырудан гыйбарәт. Тема предмет буенча төзелгән эш программасында урын алган, дәрес май уртасында үткәрелергә тиеш. Укытучының эш программасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган “Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасына” /Авторы: Хәйдәрова Р.З./2014/ нигезләнеп төзелгән. Дәрес эшкәртмәсенең нигезен коммуникатив технология, ягъни җанлы сөйләмгә таянучы методик алымнар комплексы тәшкил итә. Коммуникатив технология нигезендә рус телле балаларны татар сөйләменә өйрәтү процессы циклылыкка корылган. Тәкъдим ителгән дәрес – тексттан соңгы этап, ягъни диалогик-монологик сөйләм этабы.

| | |
|---|---|
| ***Сыйныф*** | 4 нче сыйныфның рус төркеме |
| ***Тема*** | Ямьле җәй җитте |
| ***Дәрес тибы*** | Диалогик – монологик сөйләм дәресе |
| ***Максат*** | 1) Укучыларны җәйге табигать турында сөйли, җәй көне нишләвең турында әйтә белергә өйрәтү;<br>2) чагыштыра,иң мөһимне аера, гомумиләштереп нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>3) табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |
| ***Дәреснең предмет нәтиҗәсе*** | җәйге табигать турында хикәяләп сөйли, җәй көне нишләвең турында әйтә белү; |
| ***Эшне оештыру төрләре*** | Фронталь, төркемнәрдә, парларда, индивидуаль |
| ***Ресурслар*** | “Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы”/ Хәйдәрова Р.З, Малафеева Л.Р./ 2014.<br>2. Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбият укытуда яңа технологияләр/Хәйдәрова Р.З./2013 .<br>3. Укытучылар өчен кулланма/Р.З.Хәйдәрова.- Казан:2013.<br>4. Р.З.Хәйдәрова, Н.Г.Галиева “Күңелле татар теле”. Дүртьеллык башлангыч рус |

| | |
|---|---|
| | мәктәбенең 4нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2014<br>5. Презентация.<br>6.Дидактик карточкалар.<br>7.Сюжетлы рәсемнәр |

| *Дәрес этаплары, һәр этапның максаты* | *Укытучы эшчәнлеге* | *Укучы эшчәнлеге* | *Универсаль уку гамәлләре (УУГ)* |
|---|---|---|---|
| ***1 этап. Оештыру. Мотивлаштыру.***<br>Максат: дәрескә уңай атмосфера, балаларда эшлисе килү халәте тудыру. | 1 слайд **1. Исәнләшү. Теләкләр теләү.**<br>- Исәнмесез, балалар!<br>- Хәерле иртә! Кәефләрегез ничек?<br>- Бик яхшы, минем кәефем дә бик әйбәт. Бер-беребезгә уңышлар теләп, дәресне башлыйк.<br>**2.Дежур укучы белән әңгәмә.**<br>- Бүген сыйныфта кем дежур?<br>- Сыйныфта кем юк?<br><br>- Бүген ничәсе?<br>- Атнаның нинди көне? | **1.** - Исәнмесез, хәерле иртә!<br><br>- Яхшы.<br><br>-Уңышлар телим. Яхшы җаваплар бир. Яхшы билгеләр ал. Тырыш.<br><br><br>**2.**- Мин – дежур.<br><br>- Сыйныфта барыбыз да бар.<br>- Бүген 16 нчы май.<br>- Дүшәмбе. | ***Коммуникатив УУГ:*** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү.<br>***Регулятив УУГ:*** эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү<br>***Шәхсиятле УУГ:*** белем алуга уңай мотив тудыру, уку теләге булдыру |
| ***2 этап Актуальләш-терү. Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру.***<br>Максат: бүгенге теманы үзләштергәндә кулланышка керергә тиешле, инде үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне искә төшерү | **1.Числоны язу.**<br>**2.Фонетик күнегүләр.**<br>- Авазларны тыңлагыз, кабатлагыз, артык авазны әйтегез : [а ][у][с] [н] [ш] [ж]<br>- Тыңлагыз, [ж] авазы булган сүзләрне әйтегез: җырлый, җитте, укыды, җил, яз, Җәмилә,чәчәк,шар,чыршы.<br>2 слайд **3.Матур язу күнегүләре.**<br>-Җҗ хәрефләрен һәм сүзләрне язып куегыз.<br><br>3 слайд **4. Теманы билгеләү**<br>-Теманы билгеләү өчен, ”Нәрсә җитми?” соравына җавап бирегез. Рәсемнәргә карагыз. Нинди ел фасыллары сурәтләнгән? Нинди ел фасылы җитми? Җәй нинди була?<br>Димәк, бүгенге дәреснең темасы – “Ямьле җәй” | Дәфтәрләрне ачып, числоны язып куялар.<br><br><br><br><br>- [ж]<br>- җырлый, җитте, җил, Җәмилә.<br><br><br><br>Җҗ хәрефләрен һәм сүзләрне язып куялар.<br><br><br><br><br><br>- Көз,кыш,яз.<br><br>- Җәй.<br>- Матур, күңелле, ямьле. | ***Регулятив УУГ*** кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу.<br>***Коммуникатив УУГ:*** тыңлый белү, диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу. |
| ***4 этап. Уку мәсьәләсен кую***<br>Максат: дәрес темасын һәм максатын билгелләү | 4 слайд<br>**5. Сүзләрне кабатлау** | -[җәй] [җите] [болотло] [йа$^{o}$ңгырлы] [йа$^{o}$ңғыр] [йа$^{o}$wa] [кыздыра] [са$^{o}$йрый] [чәчәк] [са$^{o}$lawa$^{o}$т күпэрэ] [җилэк] [пэшә] [көндөз] [эсэ] [озон] [җыя] [кыска] [үсә] [су койона] [төс] [су сибә] | ***Регулятив УУГ:*** Танып белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм максат кую.<br>***Коммуникатив УУГ:*** Коллектив фикер алышуда катнашу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **6.Тәрҗемәләрен табу**<br>/тарату материаллары/<br><br>5 слайд **7. Сүзләрне дөрес язу. Эталон буенча тикшерү.**<br>**8. Максатны билгеләү**<br>- Бу сүзләрне белү мөһимме? Аларны белү ни өчен кирәк? Бу рәсемнәр ни өчен кирәк? Без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез? Дәрестә нәрсәгә өйрәнергә тиешбез?/ Чему должны научиться?/ | Лето наступило/ облачный/ дождливый/ дождь идёт/ печёт/ поёт/ цветок/ радуга/ ягода созревает/ днём жарко/ длинный/ собирает/ короткий/ растёт/ купается/ цвет/ поливает/ Җәй җитте/ болытлы/ яңгырлы/ яңгыр ява/ кыздыра/ сайрый/ чәчәк/ салават күпере/ җиләк пешә/ көндез эссе/ озын/ җыя/ кыска/ үсә/ су коена/ төс/ су сибә/<br><br>- Мөһим. Дәрестә куллану өчен. Кызның нишләгәнен әйтер өчен.<br>Без бүген дәрестә җәй турында сөйләшәбез.<br><br>Җәй һәм ял турында сөйләргә. | |
| ***5 этап***<br>***Танып белү эшчәнлеге. Уку мәсьәләсен чишү.***<br>Максат: яңа белем үзләштерү өчен кирәк булган үткән материалны кабатлау, һәр укучының индивидуаль эшчәнлегендәге авырлыкларын ачыклау. | 6 слайд<br>**1. Текст укуга әзерлек**<br>- Җәй фасылына туры килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне билгеләгез: ямьле җәй, эссе көн, салкын көн, яңгырлы көн, күңелле каникуллар, елгада су коенам, җиләк җыям, салават күпере, ак кар, кояш кыздыра, кошлар сайрый, җиләкләр пешә, ботка пешә<br>7 слайд<br>**2.Текст өстендә эш**<br>1)-Тактага карагыз. Укыгыз.<br><br>2) - Текстны аңлап буламы? Ни өчен?<br>8 слайд 3) - Сүзләрне куеп, текстны укыгыз. Сүзләрне кайдан табарга була? /Әйе, сүзлектән/ | ямьле җәй, эссе көн, яңгырлы көн, күңелле каникуллар, елгада су коенам, җиләк җыям, салават күпере, кояш кыздыра, кошлар сайрый, җиләкләр пешә<br><br>*Минә ямьле ... җитте . Көннәр җылы. Кояш ... , көндез бик ... . Җәен көннәр ... , төннәр ... була. Кар эри, тамчы тама Урманда матур кошлар ... , тәмле җиләкләр ... . Яңгырлар да ява. Яңгырдан соң ... ... чыга. Миңа ... бик ошый.*<br>- Юк. Сүзләр җитми.<br><br>*Минә ямьле җәй җитте. Көннәр җылы. Кояш кыздыра , көндез бик эссе . Җәен көннәр озын , төннәр кыска була. Кар эри, тамчы тама. Урманда кошлар сайрый , тәмле җиләкләр пешә, матур чәчәкләр үсә. Яңгырлар да ява. Яңгырдан соң салават* | ***Танып белү УУГ:*** фикерләрне логик чылбырга салу, эзләнү характерындагы проблеманы чишү ысулларын мөстәкыйль рәвештә булдыру.<br>***Коммуникатив УУГ:*** Үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.<br>***Регулятив УУГ***: Үз эшчәнлегеңне контрольгә алу.<br>***Шәхсиятле УУГ:*** табигать кыйммәтләрен аңлау, табигатьне саклауга, сакчыл тотуга әзер булу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4) - Текст нәрсә турында?<br>Исем биреп буламы?<br>Кайсы җөмлә артык?<br>/Артык җөмлә алына/<br>- Хәзер текстка исем биреп буламы?<br><br>5) - Найдите в тексте предложение, где говорится:<br>наступило лето; солнце печёт; после дождя выходит радуга; летом дни длинные, а ночи короткие; в лесу поют красивые птицы, созревают ягоды, растут красивые цветы.<br><br>**3. Рәсемнәр буенча әңгәмә.**<br>/ Сюжетлы рәсемнәр №1/<br>1) - Кыз нишли?<br><br><br><br>2) - Сиңа кайсы рәсемнәр ошый? / Сюжетлы рәсемнәр №2/<br><br>**4. ТАЙМД ПЭА ШЭА.**<br>**Үзең турында сөйлә.**<br>- Син җәен нишлисең? | *күпере чыга. Миңа җәй бик ошый.*<br>- Җәй турында. Исем биреп булмый. Артык җөмлә бар. *Кар эри, тамчы тама.*<br>- Җәй. Матур җәй. Ямьле җәй ....<br><br>*Менә ямьле җәй җитте. Кояш кыздыра. Яңгырдан соң салават күпере чыга. Җәен көннәр озын , төннәр кыска була. Урманда кошлар сайрый , тәмле җиләкләр пешә, матур чәчәкләр үсә.*<br><br>- Урманга бара. Җиләк җыя. Чәчәк җыя. Су коена. Су сибә<br>Укучылар ошаган һәм ошамаган рәсемнәрне билгелиләр, ике төркемгә бүлеп куялар.<br>“Табигатьне сакла!» җөмләсен икенче төркем рәсемнәре өстенә урнаштыралар.<br>ТАЙМД ПЭА ШЭА.<br>Укучылар нәрсә эшләүләре турында сөйлиләр. | |
| **Динамик пауза** | - Ә хәзер кәрзиннәрне алабыз да урманга җиләккә барабыз.<br>Укучылар урманда җиләк җыялар, каршыларына “бүре килеп чыга”, куа башлый. | - Җиләк җыям, как коям,<br>Дәү әнигә бүләккә.<br>Монда җиләк күп икән,<br>Аю-бүре юк икән. | ***Регулятив УУГ***:<br>Үз гамәлләреңне контрольгә алу.<br>***Коммуникатив УУГ:***<br>Үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү. |
| ***6 этап. Белемнәрне ныгыту, сөйләмдә куллану***<br>Максат: Яңа белемнәрне кабатлау һәм ныгыту, сөйләмдә куллану. Өйрәнгән теманы ничек аңлауларын ачыклау, коррекцияләү. | **1.Төркемнәрдә эш** /тарату материаллары/<br>Бер укучы сорауны укый, икенчесе җавап бирә, өченчесе кабатлап сорый, дүртенче укучы җавап бирә.<br>1) Кайсы ел фасылы җитте?<br>2) Көннәр нинди?<br>3) Җәен көннәр нинди була?<br>4) Төннәр нинди була?<br>5) Кошлар нишли?<br>6) Чәчәкләр кайда үсә?<br>7) Җәен син нишлисең?<br>8) Кемгә җәй ошый?<br>**2. Ситуатив күнегүләр**<br>Спроси у друга :<br>- какое время года наступило?<br>- тебе лето нравится?<br>- ты лето любишь?<br>Скажи , что | - Җәй җитте.<br>- Җәй җиттеме?<br>- Әйе, җәй җитте.<br><br>2) - Көннәр нинди?<br>- Җылы.<br>- Көннәр җылымы?<br>- Әйе, җылы.<br>3) ..............<br><br>- Дустым, нинди ел фасылы җитте?<br>- Дустым, сиңа җәй ошыймы?<br>- Дустым, син җәйне яратасыңмы? | ***Танып белү УУГ:***<br>фикерләрне логик чылбырга салу, иҗади характердагы проблеманы чишү ысулларын мөстәкыйль рәвештә булдыру.<br><br>***Регулятив УУГ***:<br>Үзконтроль, биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү.<br>***Шәхсиятле УУГ:***<br>күршеңә ярдәм итүдә танып белү инициативасы күрсәтү.<br>***Коммуникатив УУГ:***<br>Мәгълүмат туплауда узара хезмәттәшлек инициативасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - ты лето любишь<br>- каникулы начинаются<br>- ты отдыхаешь<br>- вы купаетесь<br>- вы ягоды собираете<br>**3. Парларда эш**<br>1) Дәреслектәге 6 нчы күнегү<br>Нишлибез? Бурычны билгелибез.<br>**2)** Телефон шалтырый.<br>- Кем шалтырата икән? Нәрсә турында сөйләшерсез?<br><br>**4.Төркемнәрдә эш ФИНКИН МЭПС /КАРТА-ШАР**<br>“Җәй” темасына КАРТА-ШАР ясарга.<br>Җәй турында сөйләргә | - Мин җәйне яратам.<br>- Каникуллар башлана.<br>- Мин ял итәм.<br>- Су коенабыз.<br>- Җиләкләр җыябыз.<br><br>1) - Диалог төзибез.<br>2) - Алло!<br>- Исәнме, Марат!<br>- Сәлам, Сережа!<br>- Марат, хәлләрең ничек?<br>- Яхшы. Синеке?<br>- Әйбәт. Каникуллар. Мин ял итәм. Көннәр бик җылы. Безгә кунакка кил. Су коенабыз, җиләк җыябыз.<br>- Зур рәхмәт. Киләм.<br><br>“Җәй” темасына КАРТА-ШАР ясыйлар.<br>Һәр төркемнән бер укучы ясалган КАРТА-ШАРДАН файдаланып, җәй турында хикәя сөйли. | күрсәтү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү. |
| ***7 этап. Белемнәрне мөстәкыйль куллану һәм эталон буенча тикшерү.***<br>Максат: белемнәрне мөстәкыйль куллана һәм тикшерә алу, белемнәрне бәяләү | 9 слайд **1) Тест.**<br>Эталон буенча тест тикшерелә, укучы бәя куя<br><br>**2) Чыгу билеты / билетик на выход** | 1) Җәй кайсы айдан башлана?<br>*а) июньнән* ә)июльдән б)августтан<br>2) Җәен көннәр нинди була?<br>*а) озын* ә) кыска б) салкын<br>3) Җәй көне табигать нинди төстә була?<br>а) сары ә) ак *б) яшел*<br>4) Урманда нәрсә җыясың?<br>а) кошлар *ә) җиләк* ә) каникуллар<br>5) Яңгырдан соң нәрсә чыга?<br>а) малай *ә) салават күпере* б) җәй<br>Мин нишләдем? ........<br>Миңа ошады ..............<br>Миңа авыр булды ..............<br>Билге .................. | ***Шәхсиятле УУГ:***<br>Үз мөмкин-лекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау.<br>***Танып белү УУГ:***<br>Фикерләүдә логик чылбыр төзү.<br>***Регулятив УУГ***<br>Эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү. |
| ***8этап. Уку эшчәнлеген йомгаклау. Эшчәнлеккә рефлексия***<br>Максат: үз фикереңне дәлилләү, алган белемнәрнең әһәмиятен аңлау, киләчәктә куллана белү. | ***1. Рефлексия.***<br>- Без бүген нинди темага сөйләштек?<br>- Нәрсәләр белдек?<br>- Бу белемнәребезне без кайда куллана алабыз?<br>- Бүген алган белемнәре-гезне киләчәктә дөрес кул-ланырсыз дип ышанып калам.<br>***2. Өй эше.*** 1) Бирелгән җөмләләрдән текст төзергә (карточкалар); 2) ”Җәйнең бер көне” тема-сына хикәя яки диалог төзергә. | ***Куелган сорауларга җавап бирү.***<br><br>1 нче бирем мәҗбүри үтәлә, 2 нче биремне укучы үзе сайлап ала. | ***Шәхсиятле УУГ:*** үз уңышларың/ уңышсызлыкларыңны ң сәбәпләре турында фикер йөртү.<br>***Регулятив УУГ***:<br>Үз эшчәнлегеңне контрольгә алу. |

# КҮЛӘМ ХӘЛЕ

*Сәгыева Резидә Әмир кызы,*
*Әлдермеш гомуми урта белем мәктәбе*

1. **Белем бирү максаты:** күләм хәле турында төшенчә бирү; аның җөмләнең нинди кисәген ачыклап килүен билгеләргә һәм аларны башка хәлләрдән аера белергә өйрәтү.

2. **Фикер сәләтен үстерү максаты:** укучыларның сөйләм телен, логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын үстерүгә ярдәм итү, укучыларның үз фикерләрен тиз һәм төгәл әйтә белүләренә ирешү, телдән һәм язма күнекмәләр белән күләм хәле турында белемнәрне ныгыту, шулардан чыгып нәтиҗә ясый белүләренә ирешү;

3. **Тәрбияви максат** – аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен, кешелеклелек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү; дәрестә балаларның тиз һәм дөрес җавап бирүләренә ирешү.

**Дәрес тибы**: УМ кую һәм чишү

**Җиһазлау:** Мультимедиа проекторы, слайдлар

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру . Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

**Уңай психологик халәт тудыру. 3 мин. (слайд 1)**

**Укытучы:** Исәнмесез, укучылар. Хәерле көн! − Кәефләрегез әйбәтме? Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр, - диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк.

**Укучылар:**

Хәерле көн миңа да,
Хәерле көн сиңа да,
Хәерле көн һәммәбезгә дә!

Менә тагын яңа көн туды. Тышта саф һава. Табигать бик матур, нәкъ сезнең күңелләр шикелле. Әйдәгез, бер-беребезгә карап елмайыйк та, шушы күтәренке кәефтә дәресебезне башлап җибәрик.

(Слайд2)

**Экранга игътибар итик әле.**

Анда сезгә схема күрсәтелгән, шуны искә төшереп алыйк әле.




- Укучылар, без сезнең белән җөмлә кисәкләрен өйрәнәбез. Экранга карап әйтегез әле, алар нинди төрләргә бүленә?( Баш кисәкләр, иярчен кисәкләр)
- Әйе, баш һәм иярчен кисәкләр.
- Нинди баш кисәкләрне беләсез сез? (Ия һәм хәбәр)
- Ә иярчен кисәкләр безнең ничә төрле?( Өч төрле: аергыч,тәмамлык, хәл)
- Без сезнең белән кайсы кисәкне өйрәнәбез? (Хәлне)

(слайд 3)




1) Алмаз **еракта (кайда?)** яши иде.
2) Китапны мин **бүген (кайчан?)** алам.
3) Ул **тиз генә (ничек?)** татар телен өйрәнде**.**
4) Диләә **бик озак (күпме?)** уйланып ятты

- Хәл кисәк үзе тагын берничә төрле була.Сез нинди хәлләрне өйрәндегез? (Урын, вакыт, рәвеш хәлләрен өйрәндек.)
- Экрандагы җөмләләрне тикшереп карыйк карыйк әле. Алардагы аерып бирелгән сүзләр нинди җөмлә кисәге булып килә икән? (Дүрт җөмлә дә тикшерелә, җаваплар алына.)

- Беренче хәл эшнең урынын, икенче хәл эшнең үтәлү вакытын, өченче хәл эшнең үтәлү рәвешен, дүртенче хәл үтәлгән эшнең күләмен белдерә. Хәлләрнең алдагы өчесен өйрәндек, бүген кайсы хәлне өйрәнербез.

**4 слайд.** Димәк, без сезнең белән бүгенге дәрестә нинди УМ мәсьәләсен чишәчәкбез?

- Күләм хәлләрен өйрәнербез.

Максатыбыз нинди булыр? 4 слайд

Күләм хәлләре турында төшенчә формалаштыру һәм аларны аера белергә өйрәнү. Сөйләмдә куллана белү. **Үзбәя.**

Тактага һәм дәфтәрләргә тема языла.

**II. УМ адымлап чишү.**

**5-6 слайд.** Укучылар, экранда җөмләләр язылган. Күләм хәлләрен табып, астына сызыгыз.

1. Без шәһәрдә бер-ике атна ял итеп яттык.
2. Башня сәгате өч мәртәбә сукты.
3. Мин көннәр буе аның янында утырдым.
4. Яр шактый ерак иде. **Үзбәя.**

**7-8слайд. Төркемнәрдә эш**. Группаларга карточкалар бирелә.Укучылар күләм хәлләрен ачыклап килгән сүзләре белән язалар. Дөреслеген тикшерү.

Бирем № 1. **Күләм хәлләрен үзләре ачыклаган сүз белән күчереп языгыз, соравын куегыз.**

1. Талип **бераз** каушап китте.
2. Габдулла өчен бу мәктәпкә ияләшү **бик** авыр булды.
3. Сания туган авылын **шулкадәрле** сагынды.
4. Югалтулар **аз** булмады тормышымда.
5. Гомеремдә тик **бер тапкыр** еладым мин.

1. **Бераз** каушап китте (**күпме?**). 2. **Бик** авыр булды (**ни дәрәҗәдә?**)
3. **Шулкадәрле** сагынды (**никадәр?**).4. **Аз** булмады (**күпме?**)
5. **Бер тапкыр** еладым (**ничә тапкыр?**)

Бирем №2. **Күләм хәлләрен үзләре ачыклаган сүз белән күчереп языгыз, соравын куегыз.**

1. Гөлназ **бер-ике тапкыр** безгә килгән иде.
2. Әнине **берничә көн** көтәргә туры килде.
3. Менә хәзер **түзеп булмаслык дәрәҗәдә** җырлыйсы килә иде.
4. Алар капка төбендә **байтак** сөйләшеп утырдылар.
5. Актүш **бер атнага якын** ыңгырашып ятты .

1. **Бер-ике тапкыр** килгән иде (**ничә тапкыр?**) 2. **Берничә көн** көтәргә туры килде (**күпме?**) 3. **Түзеп булмаслык дәрәҗәдә** җырлыйсы килә иде (**ни дәрәҗәдә**?) 4. **Байтак** сөйләшеп утырдылар (**күпме?**) 5. **Бер атнага якын** ыңгырашып ятты **(күпме?)**

К.ж.: **- Укучылар, күләм хәлләре җөмләдә ни өчен кирәк?**

**-** Җөмләләрдә эш-хәлнең я билгенең күләмен белдерү өчен.

**- Ул нинди сорауларга җавап бирә?**

- Күпме? Никадәр? Нихәтле? Ни дәрәҗәдә? Ничә тапкыр?

**- Күләм хәлләре ияргән һәм ачыклаган сүз кайсы сүз төркеменә карый?**

- Ачыклаган сүз фигыль сүз төркеменә карый.

**Кагыйдә укып нәтиҗә ясыйлар:**

Күләм хәле

| | | |
|---|---|---|
| Эш-хәлнең я билгенең күләмен белдерә | Сораулары: күпме? никадәр?ни дәрәҗәдә? нихәтле? ничә тапкыр? | Җөмләнең фигыль белән белдерелгән кисәген ачыклап килә. **Үзбәя.** |

1. **Физкультминут МИКС –ФРИЗ –ГРУП Бию көе куеп сораулар бирү.**

1) Җөмләнең баш кисәкләре ничәү?(2)
2) Җөмләнең иярчен кисәкләре ничәү?(3)
3) Хәлләрнең ничә төркемчәсен өйрәндек? (4)

**5. Яңа материалны ныгыту.** Дәреслек белән эшләп алабыз.

**1.** 179 нчы күнегү. Сорау сүзгә мәгънәсе белән туры килгән күләм хәлләрен өстәп, җөмләләрне күчереп языгыз. Дөрес җаваплар:

1. Бер генә атнага булса да. 2. Бер-ике тапкыр. 3. Бераздан. 4. Ярты ягы. 5. Шулкадәр. **Үзбәя.**

**Тест эшләү: 1.** ***Күләм хәле нәрсәне белдерә?***

1) эш-хәлнең ничек үтәлүен
2) эш-хәлнең, билгенең күләмен, дәрәҗәсен*

3) эш-хәлнең урынын белдерә

***2. Җөмләдә калын хәрефләр белән бирелгән күләм хәле кайсы сүзне ачыклап килгән?***

*Җирне* ***берничә тапкыр*** *җепшек кар белән каплады.*

1) җепшек кар белән

2) каплады*

3 ) җирне

***3. Җөмләдә кайсы сүз күләм хәле булып килгән?***

***Шулкадәр зур гәүдәң белән "куркам" дип әйтергә сиңа кешедән оят! (Г.Камал)***

1) зур  2) шулкадәр*  3) гәүдәң белән

***4.Күләм хәле сораулары кайсы рәттә бирелгән?***

1) ничек? ни рәвешле? никадәр?

2) күпме? кайчан? нигә?

3) нихәтле? ни дәрәҗәдә? күпмедән?*

***5.Кайсы җөмләдә күләм хәле бар?***

1) Авылның уртасында зур базар кайный.

2) Агыйдел өстеннән әкрен генә сыек томан күтәрелә.

3) Күтәрә белмәгән күп күтәрер.*

***6. Күп нокталар урынына мәгънәсе белән туры килгән күләм хәлен куярга.***

Зөһрә ... оялыбрак җавап бирде.

1) бераз*  2) бик озак  3) шулкадәр

**Сималтиниус. Раунд Тэйбл.** *Соңыннан укучылар, дәфтәрләрен алмаштырып, бер-берсенекен тикшерәләр, эшләрен бәялиләр.*

**6. Рефлексия, бәяләү.**

**1. -** Нинди УМ тикшердек?

- Без дәрескә нинди максат куйган идек?
- Максатыбызга ирештекме?
- Нәрсә өчен кирәк соң безгә хәл кисәкләр?
- Алар безгә киләчәктә кирәк булачакмы?

**2.** Белемнәрне бәяләү.

**Дәрескә гомуми бәя.**

**7. Өй эше:** а) иҗади. "Җиде кат үлчә, бер кат кис" мәкален аңлатып языгыз. Күләм хәлләре кулланыгыз; ә) ярымиҗади. 181 нчы күнегү; бирелгән җөмләләрнең схемасын сорау сүзләр ярдәмендә төзегез.

## СОРАУ ҖӨМЛӘ
(5 нче сыйныф)

***Вәлиева Алсу Зөфәр кызы,***
***Әлдермеш гомуми урта белем мәктәбе***

| **Тема** | **Сорау җөмлә** | |
|---|---|---|
| **Максат** | 1. – сорау җөмлә турында белгәннәрне актуальләштерү, сорау җөмләнең белдерелү үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итү;<br>2. – телдән һәм язма сөйләмдә сорау җөмләләрне табу күнекмәсен үстерүгә шартлар тудыру;<br>3. – укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерүгә, коллективта эшләү, үзара ярдәмләшү, бер-береңә яхшы мөнәсәбәттә булу сыйфатлары тәрбияләү өчен шартлар тудыру. | |
| **Планлаштырылган нәтиҗә** | **Предмет буенча белем, күнекмәләр** | **Универсаль уку күнекмәләре** |
| | Предмет буенча:<br>- сорау җөмләнең ни икәнен белү;<br>- сорау җөмлә белдерелү чараларын үзләштерү ;<br>- төрле грамматик | **Регулятив:**<br>- уку мәсьәләсен кабул итү һәм дәрес дәвамында шуның буенча эшләү;<br>- куелган мәсьәлә нигезендә үз эшчәнлегеңне планлаштыру.<br>**Танып белү:** |

| | | |
|---|---|---|
| | чаралардан файдаланып, сорау җөмләләр төзеп яза белү. | - куелган мәсьәләне чишүдә алгоритмны куллана белү;<br>- язма һәм телдән сөйләмдә үз фикерләреңне формалаштыра белү;<br>- өлешләрдән бербөтенне төзи белү;<br>- гомумиләштерү.<br>**Коммуникатив:**<br>- сөйләмнең диалогик формасы белән эш итә белү;<br>- хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү;<br>- үз фикереңне һәм карашыңны формалаштыру;<br>- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү. |
| **Төп төшенчәләр** | Сорау җөмлә | |
| **Оештыру** | | |
| **Предметара бәйләнеш** | **Эш формалары** | **Ресурслар** |
| әдәбият, рус теле, әйләнә-тирәне өйрәнү | Индивидуаль,<br>фронталь,<br>төркемнәрдә эш | Дәреслек<br>Интерактив такта<br>Презентация |

**1. Мотивлаштыру-ориентлашу.** Уңай психологик халәт тудыру. Белемнәрне актуальләштерү. Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.

– Хәерле көн, балалар! Кәефләрегез әйбәтме? Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр, - диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк. Шушы күтәренке кәефтә дәресебезне башлап җибәрик.

**2. Уку мәсьәләсен кую. -** Экранга игътибар итик әле. Анда сезгә кечкенә генә текст бирелгән. Әйдәгез, бергәләп шул текстны укыйк .

**2 слайд. Кемгә яшәү җиңелрәк**? **Яхшы күңелле кешегәме яки явыз кешегәме?** Игелекле кешегә дуслар табуы, гаилә коруы җиңелрәк. Аның күңеле саф, уйлары якты. Мәрхәмәтле кешенең яхшы сыйфатлары икеләтә үзенә әйләнеп кайтачак. Әйе, игелекле, шәфкатьле булу хәзер дә актуаль.

- Текстта сүз нәрсә турында бара? (кешеләргә хас сыйфатлар турында,)
- Бу фикерләрне безгә нәрсәләр ярдәмендә җиткерделәр? (Җөмләләр ярдәмендә)
- Җөмләнең билгеләмәсен искә төшерик әле.
- Әйтү максаты ягыннан җөмләләр ниндиләргә бүленә? (Хикәя, сорау, боерык)
- Узган дәрестә без нинди җөмләләрне өйрәндек? (Хикәя җөмләләрне)

Тексттан хикәя җөмләләрне уку.

- Тагын нинди җөмләләр калды? (Сорау җөмләләр, аларны уку)

Сорау җөмлә икәнен каян белдек? ( Җөмлә ахырындагы тыныш билгесеннән)

Без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез*? (Дәреснең темасын әйтәләр, максатын билгелибез. Тактага һәм дәфтәрләргә тема языла).*

**4. УМ адымлап (өлешләп) чишү**

1. Ак яулык һәм калфаклар халкыбызның борынгыдан калган йоласымы? («Сөембикә» журналыннан)
2. Мәктәбем дә, телем дә ул Тукай,
Тукайдагы кебек тел кайда? (С.Хәким)
3.Урлаганнармы әллә
4. Кыш бабайның Кар кызын? (М.Шабаев)
5. Болар – синең беренче шигырьләрең?
6. Чү! Бу безнең әниләрнең берсе түгелме соң? (Р. Фәйзуллин)
7. Ә, алаймыни, күзегез кызыгамыни? (Г. Ибраһимов)

К.ж.: Сорау җөмләләрне белдерүче чаралар:

1. –мы сорау кисәкчәсе. 2. Кайда сорау алмашлыгы. 3. –мы сорау кисәкчәсе + әллә кисәкчәсе. 4. Сорау интонациясе генә. 5. –ме сорау кисәкчәсе + соң кисәкчәсе. 6. –мыни сорау кисәкчәсе. **Үзбәя.**

2. Төркемнәрдә эш. Ике группага да карточкалар бирелә. Укучылар сорау җөмләләрне белдерүче чараларны куялар.

**Карточка № 1.** Табын янына утырасың, табыннан җылылык, нур бөркелә. Каян килә ул нур, ул җылылык? Кояшлы тәрәзәләрдәнме? Тәрәзә төбендәге гөлләрдәнме? Әллә инде пар бөркеп утырган

самавырданмы? Белмәссең... Ә күңелдә әнә шул җылылыгы, нуры белән бергә моң да бар. Әйтү, аңлату мөмкин булмаган моң газаплый. Шуны куарга, онытырга теләгәндәй, сүз башлыйм:

- Һаман дөнья куасыз инде, ә?

**Карточка № 2.** Яңгыр басылды, чак сизелеп, җир өстеннән ак пар күтәрелде, җиргә һәм күккә тоташып, бик матур җиде тасма уйнады.

Беренче күкрәү. Ул күкеләрнең телен ачтымы? Әллә май аена өстәмә ямь булдымы? Бар табигать үзгәрде. Ямь өстенә яңа ямь өстәлдемени? Күкеләр хәзер көнозын томшык йоммады. Нигә шулай көнозын кычкыралар алар? Белмисең? Ә мин беләм. Безгә гомер саный алар. Озын гомер...

Дөреслеген тикшерү.

2. Модельләштерү. Сорау җөмлә турында белгәннәрне гомумиләштереп, модель төзергә.

***Сорау* җөмлә**

↓

– сөйләүченең үз-үзенә яки башка берәүгә булган соравын белдерә,
– сорау интонациясе белән әйтелә,
– сорауны белдерә торган сүзгә логик басым төшә,
– җөмлә ахырында сорау билгесе куела,
– түбәндәге чаралар белән белдерелә:

сорау алмашлыкл. | **–мыни, -мени -мы, -ме** сорау Кисәкчәләре | сорау интонациясе

**Үзбәя.**

1. **Физкультминут МИКС – ФРИЗ – ГРУП Бию көе куеп сораулар бирү**

1) Сорау җөмлә ясауда ничә төрле кисәкчә кулланыла? (2)
2) сорау җөмлә ничә төрле чара белән белдерелә? (3)
3)әйтү максаты ягыннан җөмләләр ничә төргә бүленә? (3)

**5. Яңа материалны ныгыту.** Дәреслек белән эш:

**1.** 127 нче күнегү. Сорау җөмләләрне барлыкка китерүче чараларны язып алыгыз.

Дөрес җаваплар: килде-**ме, ни** дияр идең, **кемгә** охшаган, **кемгә, кайсы** **Үзбәя.**

**2.** 131 нче күнегү. Ике группага бүленеп эшләү:

**1 нче группа җаваплары:** Сез укыган мәктәп нинди? Мәктәптә нәрсәләр бар? Дәресләрдән соң малайлар һәм кызлар бик теләп кайсы түгәрәкләргә йөри?

Син нинди түгәрәккә йөрисең? Марат дустың нинди түгәрәккә йөри? Кызлар нинди түгәрәккә йөриләр?

**2 нче группа җаваплары**: Сез укыган мәктәп зур һәм яктымы? Мәктәптә китапханә, спорт залы, ашханә бармы? Дәресләрдән соң малайлар, кызлар түгәрәкләргә йөриләрме? Син көрәш түгәрәгенә йөрисеңме? Дустың Марат бокс түгәрәгенә йөриме? Кызлар бию түгәрәгенә йөриләрме? **Үзбәя.**

**3. Тест. Сималтиниус Раунд Тэйбл.** Соңыннан укучылар, дәфтәрләрен алмаштырып, бер-берсенекен тикшерәләр, эшләрен бәялиләр.

**5. Рефлексия, бәяләү.**

1. - Дәрескә нинди УМ куйган идек?
- Без дәрескә нинди максат куйган идек?
- Максатыбызга ирештекме?
- Сорау җөмләләр нәрсә өчен кирәк?
- Алар безгә киләчәктә кирәк булачакмы?

**6. Дәрескә гомуми бәя.**

**7. Өй эше:** а) Иҗади. 128 нче күнегү. Бирелгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне кулланып, “Кем кемгә охшаган?” дигән темага хикәя язу.

ә) Ярым иҗади. 129 нчы күнегү. Бирелгән җөмләләрне сорау җөмләләр итеп үзгәртеп языгыз, нинди чара кулланыуыгызны аңлатыгыз.

## "КҮГӘРЧЕН ҺӘМ МАЛАЙ" ХИКӘЯСЕН ӨЙРӘНҮ

(дәреснең технологик картасы)

***Садикова Дания Солтан кызы,***
***Беренче номерлы Биектау урта мәктәбе***

| | |
|---|---|
| **Тема** | Роза Хафизованың "Күгәрчен һәм малай" хикәясен өйрәнү |
| **Предмет** | Әдәби уку, 4нче сыйныф татар төркеме |
| **Дәреснең максатлары** | 1. Хикәяне анализлау өчен шартлар тудыру.<br>2. Табигатьне саклау юлларының төрле булуын ачыкларга ярдәм итү.<br>3. Миһербанлы, мәрхәмәтле булып үсәргә кирәклекне аңларга булышу. |
| **Дәреснең бурычлары** | 1. Белем бирү максаты: хикәянең төп фикерен укучы аңына җиткерү өчен шартлар тудыру.<br>2. Фикерләү сәләтен үстерү максаты: анализлау, чагыштыру, гомумиләштереп, нәтиҗә ясау күнекмәләрен үстерүне дәвам итү.<br>3. Тәрбия бирү максаты: коллективта эшләү, үзара ярдәмләшү, бер-берең ә яхшы мөнәсәбәттә (вежливость) булу сыйфатлары тәрбияләү өчен шартлар тудыру. |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | 1. Предмет нәтиҗәләре: хикәянең темасын аңлау һәм формалаштыру, идеясен күрсәтү.<br>2. Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: герой кылган гамәлләр аша яхшыны начардан аерырга өйрәнү.<br>3. Метапредмет нәтиҗәләр:<br>- регулятив: әсәрнең төп проблемасын табу, герой эшчәнлеген бәяләгәндә, үзеңнең һәм башкаларның фикерен дөрес бәяләү, төп нәтиҗәне чыгару эшчәнлегендә катнашу өчен тырышу.<br>- танып-белү: булган белемнәргә таянып, "яхшылык эшләү" төшенчәсенә кагылышлы мәгълүматны табу һәм анализлау аша аны бәяләү, гомуми нәтиҗәне чыгару.<br>- коммуникатив: яхшылык эшләү дигән төп фикергә килгәнче, төрле җавапларны тыңлау; төркемнәрдә эшләгәндә, төрле мисаллар белән үз фикереңне дәлилләү, әсәрнең төп фикерен табу һәм формалаштыру. |
| **Предметара бәйләнешләр** | Әйләнә –тирә дөнья, география. |
| **Ресурслар:**<br>**- төп**<br>**- өстәмә** | Төп: Рус телендә гомуми башлангыч белем бирү мәктәбенең 4 нче сыйныфы өчен дәреслек. 2 нче кисәк. /Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова.-Казан"Мәгариф-Вакыт"нәшрияты, 2014<br>Өстәмә: укучыларның бүлек буенча эшләгән төрле әсәрләргә иллюстрацияләре , слайдлар күрсәтү өчен проектор, экран, ноутбук, китап күргәзмәсе, язучыларның портретлары, глобус |
| **Эшне оештыру** | Төркемнәрдә һәм индивидуаль эшләү. |
| **Төп төшенчәләр** | Тема, экологик проблема, анализлау, чагыштыру, гомуми нәтиҗә |
| **Кулланылган технологияләр** | Шәхескә юнәлтелгән , иҗади үсеш, мәгълүмати, проблемалы укыту. |
| **Дәрес тибы**<br>**Кулланылган структуралар** | Яңа белем бирү<br>ФИНК-РАЙТ-РАУНД РОБИН, ОЛ РАЙТ РАУНД РОБИН |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|
| **I.Оештыру-мотивлаштыру**<br>**2 мин.**<br>**Максат:** уңай психологик халәт тудыру | Исәнмесез, укучылар,<br>Килдегезме дәрескә.<br>Уен, көлке эшләрегез<br>Калдымы тәнәфестә?<br>Слайд №2 | Кыңгырауны ишеттек тә<br>Ашыктык без дәрескә.<br>Җиңнәребезне сызганып<br>Тотынабыз зур эшкә.<br>*Дәрестә төркемнәрдә эшләү кагыйдәләрен искә төшерәләр: башкаларны тыңла, үз фикереңне ачык әйт, игътибарлы бул.* | **Шәхси:** әдәп-әхлак кагыйдәләрен искә төшерү, бер-берсенә уңышлар теләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **II.Белемнәрне актуальләштерү**<br>**6 мин.**<br>**Максат:** яңа белем алуга әзерлекне тикшерү, аның темасын формалаштыру. | *(Китап күргәзмәсе, язучыларның портретлары.)*<br>- Укучылар, бу китаплар сезгә танышмы? | - Әйе, таныш. Ш.Галиев, Р.Миңнуллин, Х.Халиков, Ф.Яруллин һәм аларның китаплары. | **Шәхси**: уку эшчәнлегендә бер-берсе һәм укытучы белән хезмәттәшлек оештыру.<br>**Регулятив**: һәр укучының бәясен тыңлап, нәтиҗә чыгару, алдагы адымнарны фаразлау.<br>**Танып-белү:** гади ситуацияләрне бәяләп, геройның конкрет гамәлен күрә белү, аны дөрес бәяләү. |
| | - Без аларның әсәрләрен беләбезме? | - Беләбез. Дәреслекнең “Балачак әдипләре” бүлегендә аларның шигырьләрен, хикәяләрен, әкиятләрен укыдык. | |
| | - Шигырь, хикәя, әкият - әдәбиятта ничек дип атала? | - Жанр дип атала (аңлатмасы искә төшерелә). | |
| | Өй эше. Вариантларда эшләр бирелде. | “Балачак әдипләре” бүлегендә өйрәнгән бер шигырьне ятларга, үзебезгә ошаган бер әсәр буенча иллюстрация ясарга, бүлекне кабатлау өчен сорауларга әзерләнергә. Яттан шигырь сөйләнә. Иллюстрация белән таныштырыла. (Эшне башкаручы кыскача мәгълүмат бирә). | |
| | Сорауларны таблица ярдәмендә тикшерербез.(Укучыларга карточкалар таратыла)<br>Слайд №3<br><br>*(Өй эшләре буенча билгеләр куела.)* | Бирелгән таблицадан әсәрнең исемен, әсәр героен, жанрын төсле карандашлар белән тоташтыралар.<br>*(Слайд № 5 ярдәмендә җавапларның дөреслеген тикшерәләр.)* | |
| **III.Проблемалы ситуация булдыру. Уку мәсьәләсен кую**<br>**4 мин.**<br>Максат: укучының нинди авырлык белән очрашуын билгеләү | - Бу әсәрләрдә нинди геройларны очраттык? | - Кеше, йорт хайваннары, урман җәнлекләре, үсемлекләр, кошларны очраттык.<br>Слайд №5,6,7,8,9 | |
| | - Сез санап киткән: кеше, йорт хайваннары, урман җәнлекләре, үсемлекләр, кошлар - барыбыз да кайда яшибез? | - Без барыбыз да табигатьтә яшибез. Слайд №10 | |
| | - Бу очракта табигатьне нәрсә белән чагыштырырга мөмкин? | Табигатьне зур йорт белән чагыштырырга мөмкин. | |
| | - Бер йорт эчендә яшәүчеләр үзара ничек яшәргә тиешләр.<br>- Дөрес, килешәм, укучылар. Әдәби уку дәресеннән башка, тагын | - Бер йорт эчендә яшәүчеләр үзара дус, тату, ярдәмләшеп яшәргә тиешләр.<br><br>- Без әйләнә-тирә дөнья дәресендә табигатьне | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | нинди дәресләрдә сез табигать турында сөйләшәсез, өйрәнәсез?<br>- Димәк, табигатьтә һәркайсыбызның яшәү тирәлеге бар. Шуңа күрә табигатькә карата миһербанлы, мәрхәмәтле булырга кирәк.<br>Бу очракта Фәнис ага Яруллинның "Ашыгыйк" дигән шигыреннән менә мондыйрак юлларны искә төшерми мөмкин түгел.<br>*Күтәрик егылган гөлләрне*<br>*Матурлык калмасын егылып*<br>*Һәркемнең гомере бер генә*<br>*Яхшылык эшләргә ашыгыйк.*<br>Слайд №11<br>- Шигырьнең соңгы юлына игътибар итегез.<br>- Димәк, укучылар, автор безне нәрсә эшләргә чакыра, өнди?<br>- Укучылар, без дәреслегебезнең яңа бүлегенен өйрәнә башларбыз. "Яхшылык эшләргә ашыгыйк..." дип аталыр ул. Бүлекнең исеменнән аңлашылганча, бу нинди шигырьдән алынган сүзләр.<br>Слайд №12<br>- Дөрес, укучылар. Әгәр дә тирәнрәк фикер йөртеп карасак, бү бүлектә өйрәнәсе әсәрләребез нәрсә турында булыр дип уйлыйсыз?<br>- Яңа бүлек үткәненең дәвамы булыр дип уйламыйсызмы?<br>- Әдипләрнең иҗаты белән танышканда нинди хисләр кичердек?<br>- Бу бүлектә нинди мөнәсәбәтләр турында сүз барыр дип уйлыйсыз. | өйрәнәбез.<br>*Яхшылык эшләргә ашыгыйк* дигән сүзләрне укучылар кычкырып укыйлар.<br>- Автор безне яхшылык эшләргә чакыра.<br>- Сез әле генә укып киткән Ф.Яруллинның "Ашыгыйк" исемле шигырь юлларыннан алынган.<br>- Схемада күргәнебезчә, кеше белән кеше, кошлар, җәнлекләр - табигать турында булачак.<br>Слайд №10 нчы күздә тотыла.<br>- Охшаш яклары булыр дип уйлыйбыз.<br>Без шатландык та, көлдек тә, уйландык та, күңелсезләндек тә...<br>??? *Укучылар өчен сорау ачык кала. Әлегә җавап бирә алмыйлар.* | |
| **IV.Яңа теманы өйрәнү**<br>**8 мин.**<br>**Максат:** кыенлыктан чыгу юлларын ачыклау . | Слайд №13<br>Беренче әсәребез - Роза Хафизованың "Күгәрчен һәм малай" хикәясе.<br>*(Укучыларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып, язучының тормышы һәм иҗаты буенча кыска гына мәгълүмат бирергә.)* | Һәр төркем фикер алыша. Һәр төркемнең фикере тыңлана. ФИНК-РАЙТ-РАУНД РОБИН<br>ОЛ РАЙТ РАУНД РОБИН структуралары буенча башкарыла. | **Коммуникатив УУГ:** күмәк эш вакытында, бигрәк тә фикер агышлары төрле булганда, бер фикергә килә белү.<br>**Регулятив УУГ:** укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Башка дәресләрдән аермалы буларак, әсәрне дәреслектән укыганчы, сез бүлек исемен исегездә тотып, әсәрнең исеменнән чыгып , бу әсәрдә нәрсә турында сүз барачагын үзегез уйлап карыйсыз.<br>ФИНК-РАЙТ-РАУНД РОБИН<br>ОЛ РАЙТ РАУНД РОБИН<br>структуралары буенча эшлиләр. | | җавапларын бәяләү.<br>**Танып-белү:** әдәби әсәрнең әхлакый ягын дөрес чамалау. |
| **Ял итү**<br>**1мин. Максат:** укучыларның ялын оештыру. | Ял итүне үткәрүгә җаваплы укучының эшен оештыру. | Күнегүләр ясыйлар. | **Шәхси:** төрле ял итү күнегүләре ясау.<br>**РегулятивУУГ:** күнегүләрне дөрес эшләүне контрольдә тоту. |
| **V.Беренчел ныгыту**<br>**6-7 мин.**<br>**Максат** : ишетеп, күреп тану күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. | Ә хәзер дәреслекнең 57нче битен ачып укып карыйк. Сезнең фикерләрегез белән автор хикәясе арасында уртак яклар бармы?<br>Беренче эш итеп,сүзлекчә белән танышырбыз.<br>Слайд №14 | Бер укучы сүзлекчәне кычкырып укый.<br>Һәр төркемгә берәр сүз бирелә. Шул сүз белән җөмлә төзиләр.<br><br>Укучылар хикәяне чылбыр тәртибендә кычкырып укыйлар. | **Танып белү**: төрле жанрдагы әдәби әсәрне аңлап уку.<br>**КоммуникативУУГ** укылган, тыңланган әсәрләр буенча сораулар бирә белү.<br>**Эстетик өлкәдә:** әсәрдән рухи тәм табу. |
| **VI . Мөстәкыйль эш.**<br>**5 мин.**<br>**Максат:** укучыларның игъти барлылыгын тикшерү, хаталарны төзәтү | - Күгәрчен нинди бәлага юлыккан?<br>- Ни өчен кешеләр күгәрчен баласына игътабар итми?<br>- Кошка кем ярдәм итә?<br>- Ни өчен күгәрчен башта малайдан курка?<br>- Малай, күгәрченне җибәргәч, нинди хисләр кичерә? Шул өлешне табып укыгыз әле.<br>- Малай кая ашыга иде ? Шулай булуга карамастан да, ул күгәрченгә ярдәм итте.<br>- Малай нинди яхшы сыйфатларга ия?<br>- Күгәрчен ни сәбәпле бәлага юлыкты?<br>- Әйе, укучылар. Без, кешеләр, кечкенә дусларыбызны уйламыйча, аларга зыян китерәбез. Табигатьне пычратуыбыз турында аз уйлыйбыз. Димәк, укучылар, без дә хикәядәге геройлар кебек үзебез турында гына уйлап, вакытны кызганып, үз эшебезне генә эшләргә ашыгырга тиешме? | - Күгәрчен урамдагы чүплектә бәлага юлыккан.<br><br>- Чөнки барысы да каядыр ашыга.<br><br>- Кошка бер малай ярдәм итә.<br><br>- Минем уйлавымча, моңа кадәр кешеләр аларны куркытканнардыр. Аларга әйбер ташлаганнардыр.<br><br>Аңа рәхәт була.<br>*Хикәя эченнән табып укыйлар.*<br><br>- Малай стадионга ашыга иде.<br><br>- Малай кызгана белә, кошларны ярата, ярдәм итәргә ярата, вакытын кызганмый.<br>- Күгәрчен чүплек савытыннан асылынып торган чуалчык капрон җепкә эләгеп калган.<br>- Юк. Малай кебек, **ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘРГӘ ДӘ АШЫГЫЙК**, вакытыбызны кызганмыйк! | **Танып-белү:** алган белемнәрдән тиешле нәтиҗәләр чыгару күнекмәләрен формалаштыру.<br>**Коммуникатив:** төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү.<br>**Шәхси:** эш барышында үз фикереңне белдерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **V. Кабатлау һәм ныгыту**<br>**5 мин. Максат:** алган белемнәрне куллану һәм ныгыту. | 2017 нче ел - Россиядә Экология елы. Шул турыда фотолардан төзелгән слайдлар карау. Слайд №15-27<br>- Укучылар, сез үзегездән табигатьне саклауга өлеш кертәсезме?<br>Укучылырның фотоларыннан төзелгән слайд карау.<br>Слайд №28,29 | Бер укучы глобустан үзебез яшәгән урынны табып күрсәтә. Укучылар белән әңгәмә дәвам итә. Фикерләр тыңлана. Тормыштан алган мисаллар китерәләр. | **Танып-белү:** алган белемнәрдән тиешле нәтиҗәләр чыгару күнекмәләрен формалаштыру.<br>**Шәхси:** эш барышында үз фикереңне белдерү. |
| **VI. Рефлексия**<br>2 мин.<br>Максат: дәрестә эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясау. | "Бүлектә нинди мөнәсәбәтләр турында сүз барыр дип уйлыйсыз?" дигән сорауга җавап бирә алабызмы? | Әйе, хикәядән аңлашылганча, без өйрәнәсе әсәрләрдә кешеләр һәм табигать арасындагы мөнәсәбәтләр турында сүз барачагын аңладык. | **Регулятив:** аңлашылмаган якны ачыклау, бергәләп эшләгәндә, бердәм карар кабул итә белүнең әһәмиятен аңларга булышу.<br>**Шәхси:** һәр баланың шәхси нәтиҗәгә ирешүе.<br>**Коммуникатив:** әңгәмәдә актив катнашу |
| **IX. Дәресне йомгаклау.**<br>**2 мин.**<br><br>Максат: бер-береңнең эшен бәяләү, билгеләр кую. | Укучылар, без дәрестә нәрсә өйрәндек? Дәрестәниләр белдек? Дәрестә нинди авырлыкларга очрадык? Дәрес ошадымы? | <br>*Дәрес башында схемалы карточкалар һәр укучыга бирелә. Сорауларга җавап бирәләр.* | **Шәхси:** үз эшеңә объектив бәя бирә белү һәм тәнкыйть күзлегеннән карау. |
| **X.Өй эше бирү һәм теләкләр.**<br>**1 минут** | 57-60 нчы биттәге хикәяне укырга.<br>1 вар. - 60 нчы биттәге сүзлекчәне ятларга.<br>2 вар. - Хикәянең эчтәлеген малай исеменнән сөйләргә өйрәнергә.<br>3 вар.- 60-61нче биттәге 1,2,3,4 нче сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнергә.<br>4 вар.- "Аксыл-көрән каурый җылысы" дигән темага кечкенә хикәя төзеп язарга.<br>Дәрестә катнашуыгыз һәм игътибарыгыз өчен рәхмәт! | | **Шәхси:** үз мөмкинлегеңнән чыгып, өй эше алу. |

**Кулланылган әдәбият**


1.Рус телендә гомуми башлангыч белем бирү мәктәбенең 4 нче сыйныфы өчен дәреслек.2 нче кисәк. /Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова.-Казан"Мәгариф-Вакыт"нәшрияты, 2014

2. Интернет-ресурслар.

## ХЕЗМӘТЛЕ КЕШЕ - ХӨРМӘТЛЕ КЕШЕ
(8 нче сыйныф, рус төркеме)

***Абдуллина Нурсанә Нурхәмәт кызы,***
***Усад урта гомуми белем бирү мәктәбе***

| | |
|---|---|
| **Максат** | Һөнәр сайлау проблемасы буенча лексик-грамматик күнекмәләрне кулланып, диалогик һәм монологик сөйләмгә чыгу;<br>Имтихан таләпләренә якынайтылган текст өстендә эшли белү үзенчәлекләрен өйрәнүне дәвам итү, үз мөнәсәбәтеңне әйтә һәм дәлилли белү күнекмәләрен үстерү;<br>Һөнәр сайлау җаваплы эш икәнен ассызыклау, әти-әниләренең хезмәтенә, башка хезмәт ияләренә хөрмәт тәрбияләү. |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Предмет буенча:** һөнәр, һөнәрчелек атамаларын белү, сөйләмдә урынлы куллану<br>**Танып-белү УУГ:** текст белән эшли белү, тест чишү, җыйнак һәм җәенке җөмлә төрләрен аңлый,аңлата белү<br>**Коммуникатив УУГ**: балаларга бер-берсенә сораулар әзерләтү, диалогик сөйләмдә катнашу; күнегү эшләтеп, алышып тикшерттерү;<br>**Регулятив УУГ:** күнегүләрне тикшергәндә, үз хаталарын таптыру;<br>**Шәхси УУГ:** дәресне йомгаклауда катнаштыру, иҗади эш. |
| **Дәреснең тибы** | Белем-күнекмәләрне куллану, белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру |
| **Предметара бәйләнеш** | Рус теле , әдәбият |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, төркемдә, парларда, индивидуаль |
| **Чыганаклар** | Проектор, ноутбок, презентация, сүзлек, карточкаларда ситуатив күнегүләр, таратма материаллар |
| **Кулланылган структуралар** | Конэрс, сималтинус рэлли тэйбл |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
|---|---|---|---|
| **Оештыру Мотивлаштыру (1-2 мин)** | Исәнләшү. Уңай пси хологик халәт тудыру.<br>- Хәерле көн, кәефләрегез ничек? Тактага 3 смайлик эленә,кәефләрен билгелиләр (әйбәт,яхшы, канәгатьләнерлек)<br>- Бүген атнаның нинди көне?<br>Бер-берегезгә, кунакларга яхшы кәеф телик һәм дәресне башлыйк. **1 слайд** | Исәнләшү, яхшы кәеф телиләр. Дәрескә әзерлекне күрсәтү.<br><br>Тактага 3 смайлик эленә, кәефләрен билгелиләр (әйбәт, яхшы, канәгатьләнерлек). | Р:<br>укытучы һәм сыйныфташлары белән теләктәшлек планлаштыру |
| **Өй эшен тикшерү** | 1.Фонетик зарядка<br>2.Өй эшен тикшерәбез: **икмәк, хәзинә, бәхет** сүзләренә синквейн<br>Нәтиҗә: Һәркем үзенчә тырышкан, бик яхшы | 11.*Фонетик зарядка:* ка-кә, кы-ке, кый-ки, ко-кө, ку-кү; ак-әк, ык-эк, ыйк-ик, ок-өк, ук-үк.<br>2. Синквейн юлы белән төзелгән шигырьләрен укыйлар (иптәшләре,ошаса, мактыйлар). | |
| **Белемнәрне актуальләштерү** | Хәзер берничә эш башкарып китәрбез,бу күнегүләр дәресебезнең темасын ачыкларга ярдәм итәр. **(конэрс )**<br>1.Укучылар, игътибар | Төрле хезмәт ияләренә багышланган рәсемнәр арасыннан күңелләренә якынын сайлыйлар.Тыңлыйлар, сорауларга җавап бирәләр. | К: ишетә һәм тыңлый белү; кирәкле информацияне табу;<br>укытучы һәм сыйныфташлары белән теләктәшлектә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | итегез, бүлмәдә почмаклар исемләнгән. Берсен сайларга кирәк. Ни өчен бу почмакны сайладың?<br>Иптәшең бу почмакны ни өчен сайлаган?<br>Бик яхшы.<br>2.Укучылар, хәзер сез текст тыңлап үтәрсез һәм, аңлаганыгызны күрсәтеп, мин куйган сорауларга җавап бирерсез.<br>- Текст нәрсә турында һәм кемнәр турында булды? (Кушымта №1)<br>- Үскәч укучы кем булырга тели? Укучылар, һөнәр сайлау - һәркемнең тормышында бик мөһим нәрсә. Һәрбер кеше үзенең күңеленә хуш килгән һөнәрне сайлый һәм аңа гомерен багышлый (Выбор профессии- очень серьезный момент для каждого человека. Каждый человек выбирает профессию по души и посвящает этому всю свою жизнь.). | Кыскача русча эчтәлек сөйлиләр, җавап бирәләр | булу; әйтергә теләгән фикереңне сөйләм нормаларына китереп формалаштыру.<br>Ш: темага кызыксыну уяту. |
| **Проблемалы ситуация булдыру. Уку мәсьәләсен кую** | Укучылар, тактага да карагыз әле, анда бирелгән сүзләрне карап китик: машина йөртүче, хисапчы, сатучы, диңгезче, рәссам, сыер савучы, көтүче, галим, укытучы (транскрипциясе һәм тәрҗемәсе бирелә).<br>Бу сүзләр нинди юл белән ясалган?<br>**2 слайд.** Бер сүз белән бу сүзләр нәрсәне аңлата?<br>Һөнәр сүзенең синонимнары әйттерелә, һөнәр сүзенең мәгънәсе **сүзлектән** аңлатыла.<br>**3 слайд** | Сүзләрне укыйлар, тәрҗемәсе белән танышалар, нәтиҗә ясыйлар.<br><br>Кушымча ярдәмендә<br><br>Һөнәр<br>Хезмәт<br>Эш<br>Профессия - это у людей основной род занятий трудовой деятельности.<br>Һөнәр - ул кеше хезмәте һәм эшчәнлегенең төп төре. (Дәфтәргә язу) | Ш: сүзлек белән эшли белү.<br><br>Р: алган белемнәрен системага салу. |
| **Тема, максат, бурычларны билгеләү** | Димәк, без бүген нинди **темага** сөйләшү алып барырбыз?<br>Хезмәтле, һөнәрле кеше - хөрмәтле кеше<br>**4 слайд.** Әйе, укучылар, бүген без кеше тормышында хезмәтнең әһәмиятенә кабат тукталырбыз.<br>**Максатыбыз**: һөнәр сайлау турында сөйләшү, фикер йөртү, язарга өйрәнүне | Теманы атыйлар.<br><br>Тактадагы яңа һөнәр исемнәрен карап китәләр. | Р: тема һәм максат билгеләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | дәвам итү.<br>Заман үзгәрә барган саен,тормыш яңа һөнәрләр таләп итә. Кайбер һөнәрләр турында ишеткәнебез дә булмаска мөмкин. Мәсәлән, кем ул актуарий, титестер?<br>Слайд (яңа һөнәр исемнәре белән)<br>**5 слайд**<br>Интернеттан яңа һөнәрләрнең мәгънәләрен табып килергә. | Аңлатыла:<br>актуариий - кеше гомерен озак вакытка страховкалау өлкәсендә эшләүче белгеч;<br>титестер - чәйнең сыйфатын билгеләүче сирәк очрый торган һөнәрләрнең берсе. | |
| **Теманы ныгыту** | Текст таратыла (кушымта№2)<br>Бер-берсенең җавабын тикшерәләр (**сималтинус рэлли тэйбл)**<br>Тактадан дөрес җавапны карап дөреслиләр.<br>**6 слайд** | Укыйлар,5 биремгә туры килү-килмәвен ачыклыйлар; бер-берсенең эшен тикшерәләр, дөреслиләр | П: текст белән эшли белү, танып белү эшчәнлеге, дөрес җавапны таба белү, проблеманы чишү.<br>Р: контроль, коррекция.<br>Ш: иҗади эш.<br>К: иптәшенең ялгышын табып төзәтә белү. |
| | **Ял минуты.** 7 слайд.<br>Без инде хәзер зурлар,<br>Күп эшли безнең куллар.<br>Компьютерда да уйныйбыз,<br>Без бәйләм дә бәйлибез,<br>Без бии дә беләбез,<br>Хезмәт сөеп үсәбез. | | |
| **Теманы ныгыту**<br>*Лексик-грамматик материалны искә төшерү* | Белемнәрне ныгытуга күнегүләр бирелә.<br>1) Укучылар, тактада сез нинди һөнәр ияләренең рәсемнәрен күрәсез?<br>**8 слайд**<br>Табиб нишли?<br>Бу нәрсә?<br>Нинди җөмлә?<br>Җәенкеләндерергә.<br>Табиб кайда дәвалый? Ничәнче?ничек?кемнәр белән?ни өчен? сорауларына җавап алу. **9 слайд**<br>2) **Югалган сүзләр, сүзтезмәләр**<br>(кушымта №3)<br>һөнәрле булу турында Каюм Насыйри сүзләре һәм ярдәмлек сүзлек бирелә: сүзләрдән җөмләләр төзү<br>**10 слайд**<br>**11 слайд**<br>**12 слайд** | Укучылар күнегүләрне эшлиләр.<br><br>Врач, табиб, доктор<br><br>дәвалый<br>җөмлә<br>**җыйнак җөмлә**<br>**җәенке җөмлә**<br>Бүген табиб коллегалары белән бишенче хастаханәдә әйбәт дәвалый, чөнки ул чын доктор (үз эшен ярата).<br><br>Сүзлек эше: җаннарым - милые мои, дорогие; карак -вор; хәтәрдер - наверное опасно; кайгырмас - не будет переживать; югалтса да - даже если потеряет.<br>Җөмләләр, җөмләләрдән хикәят төзиләр.<br>Әй җаннарым, угланнарым, хикәятемне ишетегез - һөнәр өйрәнегез. Дөньяның байлыгына ышанырга ярамый. Алтын-көмешләр кеше өчен хәтәрдер: аны я карак алып китә, я утта янып бетә. Әмма һөнәр ышанычлы дәүләттер, һөнәр иясе байлыгын югалтса да кайгырмас. Әй | П: фикер йөртүнең логик чылбырын төзү; дәлилләү; белемнәрне структуралаштыру<br>К: әйтергә теләгән фикереңне сөйләм нормаларына китереп формалаштыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Бу хикәяттән ниләр белеп калдыгыз?<br>- Нигә К.Насыйри аны беренче хикәят итеп алды икән?<br>Нәтиҗә:<br>һөнәрле кеше - бай кеше.<br>**13 слайд** | угыл, син дә шулай һөнәр өйрән, тәрбияле бул, белем ал.<br>Көтелгән җаваплар:<br>Һөнәргә өйрәнергә куша.Һөнәрле кеше- бай кеше. К.Насыйри да иң беренче баланы кечкенәдән һөнәргә өйрәтергә кирәклеген әйтә. | |
| **Мөстәкыйль эш** | Укучыларның игътибарлылыкларын тикшерү өчен, башваткыч бирелә (5 һөнәр атамасын табыгыз) (кушымта №5) | укытучы, сатучы, тәрбияче, табиб, балыкчы сүзләре табыла | |
| **Ситуацияләр белән эш** | Парларда эш:<br>укытучыга сораулар, табибка сораулар.<br><br>**14, 15 слайдлар**<br><br>ТНВ каналында “Һөнәр” тапшыруы бара, карарга киңәш итәм. | Парларда эшлиләр. Терәк сүзләр бирелә: матур, ошый, ничә ел, сайладыгыз, уңышлар.<br>Көтелгән нәтиҗә:<br>аралашуда итәгатьлелек.<br>- Сез бүген бик матур.<br>- Гафу итегез, сез ничә ел сатучы (табиб) булып эшлисез?<br>- Бу һөнәр ошыймы? Нәрсә ошый?<br>- Акча күп түлиләрме?<br>Хезмәт хакыгыз күпме?<br>- Сабырлык һәм саулык, уңышлар телим сезгә.<br>(Шулай ук табибка). | П: проблеманы иҗади характерда чишү юлларын табу.<br>К: әйтергә теләгән фикереңне сөйләм нормаларына китереп формалаштыру. |
| **Өй эше** | Өй эше биремен аңлату:<br>1) әти-әни һөнәре турында язу (презентация ясарга мөмкин);<br>2) тест: сайлаган һөнәрне яратырга кирәк. Ә сез кем булырга телисез? (Тест өлешенә (кушымта №5));<br>3) интернеттан яңа һөнәрләр турында мәгълүмат алып килү.<br>Өй эше биременең аңлашылып бетмәгән өлешен ачыклыйлар **12 слайд** | | |
| **Рефлексия, бәяләү, үзбәя** | Рефлексияне оештыра. Һәр укучының максатка ирешү дәрәҗәсен билгели.<br>Укучыларның дәрестәге эшен бәяли.<br>Дәрес сезнең өчен файдалы булдымы?<br>Синеңчә, дәрестә кем актив эшләде?<br>Син үз җавабыңнан канәгатьме? Дусларыңның җаваплары ошадымы?<br>Нәтиҗә: әйе, укучылар, бөтен эш тә әһәмиятле.<br>Барысы да яхшы. Һөнәр сайлау - бик җаваплы.<br>Дәресне шигырь юллары белән тәмамлыйсы килә.<br>Н.Дәүли “Бәхет кайда була?” | Сорауларга җавап бирәләр, әңгәмәгә катнашалар.<br>Максат һәм нәтиҗәләрдән чыгып, үз-үзләрен бәялиләр.<br><br>Укучы (укытучы) сөйли. | Ш: дәресне йомгаклауда катнаштыру. |

## СИНОНИМҺӘМ АНТОНИМ СЫЙФАТЛАР

(дәрескә технологик карта, 5 нче сыйныф)

***Минһаҗетдинова Розалия Фәйзерахман кызы,***
***Мүлмә гомуми урта белем мәктәбе***

| **Тема** | **Синоним һәм антоним сыйфатлар** |
|---|---|
| Максат: | Антоним һәм синоним сыйфатлар турында төшенчә бирү; аларны аера, сөйләмдә куллана белергә ярдәм итү. |
| Планлаштырылган нәтиҗә | Укучыларның сөйләм телен, логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын үстерүгә ярдәм итү, укучыларның үз фикерләрен тиз һәм төгәл әйтә белүләренә ирешү, телдән һәм язма күнекмәләр белән антоним һәм синоним сыйфатлар турында белемнәрне ныгыту, шулардан чыгып нәтиҗә ясый белүләренә ирешү. |
| Эшне оештыру төрләре | Төркемнәрдә эшләү |
| Чыганаклар:<br>- төп<br><br>- өстәмә | 1.Р.Г.Хәсәншина. Татар теле : 5 нче сыйныф<br>2. Р.Г.Хәсәншина. Татар теле: 5 нче сыйныф: укытучы өчен методик кулланма, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2015<br>1.Презентация Power Point – “Синоним һәм антоним сыйфатлар”<br>2. тест |
| Универсаль уку гамәлләре (УУГ) төрләренең кыскартмалары | ШУУГ –шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре<br>РУУГ- регулятив универсаль уку гамәлләре<br>ТБУУГ- танып белү универсаль уку гамәлләре<br>КУУГ- коммуникатив универсаль уку гамәлләре |

| **Дәрес этаплары** | **Дәрес этабының максаты** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
|---|---|---|---|---|
| **Оештыру. Эшкә кызыксыну тудыру.** | Укытучы өчен максат: психологик уңай халәт барлыкка китерү. | Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.<br>− Хәерле көн, балалар!<br>− Кәефләрегез әйбәтме? Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр, - диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк.<br><br>- Шушы күтәренке кәефтә дәресебезне башлап җибәрик. | Укучылар теләкләр тели:<br>− Хәерле көн миңа да,<br>Хәерле көн сиңа да,<br>Хәерле көн һәммәбезгә дә! | КУУГ: классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү.<br>ШУУГ: үзмаксат кую. |
| **Актуальләштерү. Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру** | **Укытучы өчен максат:** сыйфат темасы буенча алдагы дәресләрдә алган белемнәрне мөстәкыйль рәвештә искә төшерү мөмкинлеге булдыру.<br><br>**Укучылар өчен максат:** сыйфатларны тексттан таба белү, сыйфатка хас билгеләрне | - Экранга игътибар итик әле. Анда сезгә кечкенә генә текст бирелгән. Әйдәгез, бергәләп шул текстны укыйк әле.<br>**2 слайд**<br>Кемгә яшәү җиңелрәк?<br>**Яхшы күңелле** кешегәме яки явыз кешегәме? Игелекле кешегә дуслар табуы, гаилә коруы җиңелрәк. Аның күңеле саф, уйлары якты. Мәрхәмәтле кешенең яхшы сыйфатлары икеләтә үзенә әйләнеп | | ТБУУГ: сыйфатның төп билгеләрен аерып күрсәтеп, кагыйдә формалаштыру<br>РУУГ: кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | аңлата алу. | кайтачак. Әйе, игелекле, шәфкатьле булу хәзер дә актуаль.<br>- Текстта сүз нәрсә турында бара?<br>- Кешегә хас сыйфатлар турында<br>- Тексттан сыйфатларны табыйк әле. | - Кешегә хас сыйфатлар турында.<br>Укучылар текст турында үз фикерләрен әйтәләр.<br>**Җавап:** җиңелрәк, яхшы күңелле, явыз, игелекле, саф, якты, мәрхәмәтле, шәфкатьле, яхшы | |
| **Уку мәсьәләсен кую** | **Укытучы өчен максат:**<br>яңа белемнәр кабул итүне оештыру һәм үзләштерүгә юнәлеш бирү.<br><br>**Укучылар өчен максат:** килеп туган уку мәсьәләсен анализлау; дәреснең темасын, максатын билгели белү. | Игелекле, мәрхәмәтле, шәфкатьле,<br>Яхшы күңелле- явыз<br>- Тексттагы билгеләнгән сүзләргә игътибар итик әле.<br>- Сез аларның мәгънәләрен ничек аңлыйсыз? (Мәгънәләрен ачыклау)<br>*Укучылар әйткән сүзләрне укытучы экранда күрсәтә бара.*<br><br>Димәк, бу сүзләр нинди сүзләр булырлар?<br>- Нәрсәдән чыгып бу сүзләрне антоним һәм синоним сыйфатлар дип атадыгыз?<br><br>Димәк, без сезнең белән бүгенге дәрестә нинди УМ мәсьәләсен чишәчәкбез?<br><br>Дәрескә нинди максат куярсыз? | *кучыларның җаваплары*<br>- Беренче баганадагы сыйфатлар мәгънәләре буенча бердәй, икенче баганадагы сыйфатлар капма – каршы мәгънәне белдерәләр .<br>- Синоним һәм антоним сыйфатлар булырлар.<br>- Бер үк мәгънәне белдерә торган сүзләр синонимнар дип, капма-каршы мәгънәне белдерә торган сүзләр антонимнар дип атала.<br>- Синоним һәм антоним сыйфатлар турында сөйләшербез.<br>- Синоним һәм антоним сыйфатлар турында өйрәнербез.<br>- Аларны аера белергә, сөйләмдә кулланырга өйрәнербез. | ТБУУГ: танып белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм максат кую.<br>РУУГ: кагыйдә, инструкуцияләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу.<br>КУУГ: коллектив фикер алышуда катнашу. |
| **Танып-белү эшчәнлеге. Уку мәсьәләсен чишү**. | **Укытучы өчен максат:**<br>антоним һәм синоним сыйфатлар турында күзаллау булдыруда ярдәм итү.<br><br>**Укучылар өчен максат:**<br>антоним һәм синоним сыйфатларны таба | 1. Экранда бирелгән сүзләрнең синонимнарын һәм антонимнарын табарга.<br>Зур чибәр<br>Матур куркак<br>Нечкә кыйммәт<br>Батыр файдалы<br>Шифалы юан<br>Арзан дәү<br>МАТУР, ЧИБӘР синонимнарына игътибар итик әле.<br>Аларның тагы нинди | Синоним һәм антоним сыйфатларны таптык.<br>*Балаларның җаваплары.*<br>***Үзбәя.***<br>*Төркемнәрдә эшлиләр.*<br><br>***синоним һәм антоним парларын табып язалар..*** | ТБУУГ: уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру<br>КУУГ: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү<br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белү. | синонимнарын таба алырсыз?<br>Матур һава урынына чибәр һава, сылу һава дип әйтә алабызмы?<br>Димәк, синонимнар мәгънәдәш сүзләр булсалар да, барлык очракта да бер-берсен алмаштыра алмыйлар икән.<br>7-9 слайд<br>Укучылар, экранда җөмләләр язылган. Сез җөмләләрдән сыйфатларны табып, билгеләнгән сүзләрнең синоним һәм антоним парларын табып язарга тиеш буласыз.<br>*1. Халык- художник ул. Ул хәтта табигатьнең иң назлы иркәсе, иң нәфис сәнгате-чәчәкләрне дә матуррак итә. (Г. Әпсәләмов)*<br>*2.Егет яшь тә түгел, карт та түгел, боек та түгел, шат та түгел, биек тә түгел, тәбәнәк тә түгел, , сәламәт тә түгел икән. ( Ф. Яруллин)*<br>*3. Ул зирәк тә, шаян да,*<br>*Акыллы да, әйбәт тә!*<br>*Иң-иң әйбәт ул кеше –*<br>*Минем әти, әлбәттә!* - Укучылар, синоним һәм антоним сыйфатлар безгә тормышта ни өчен кирәк?<br>Димәк, синоним сыйфатлар дип нинди сыйфатларга әйтәбез?<br>- Антоним сыйфатлар дип нинди сыйфатлар атала?<br>*Экранда модель күрсәтелә.* Дөреслеге тикшерелә. | ***ГҮЗӘЛ ,СЫЛУ***<br><br>*Юк.*<br><br>*Үзбәя*<br><br>*Күтелгән җавап: назлы, нәфис, матуррак*<br>*Яшь, карт, боек, шат, биек, тәбәнәк, сәламәт, зирәк, шаян,акыллы, әйбәт*<br><br>*- Синоним һәм антоним сыйфатлар предмет билгеләрен төгәлрәк сурәтләргә ярдәм итә.*<br><br>*Укучылар кагыйдәне үзләре чыгаралар.*<br>Дәреслекнең 34 нче битендәге кагыйдәне укып нәтиҗә ясыйлар. Кагыйдәне бер-берсенә әйтеп карыйлар, мөстәкыйль рәвештә модель төзиләр. Үзбәя. | |
| **Яңа белемнәрне ныгыту** | **Укытучы өчен максат:**<br>белемнәрне күнегүләр ярдәмендә ныгыту мөмкинлеге булдыру. | Дәреслек белән эш.<br><br>1. 104 нче күнегү. Антоним сыйфатлар уйлап язарга. Җөмләләр төзергә. | Дәреслектәге күнегүне эшлиләр,шул сүзләр белән җөмләләр төзиләр. Берничә укучы үзе төзегән җөмләләрне укый. | РУУГ: үзконтроль, биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү.<br>ШУУГ: күршеңә ярдәм итүдә танып белү инициативасы күрсәтү.<br>КУУГ: мәгълүмат туплауда үзара |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **Укучылар өчен максат:** яңа белемнәрне дәреслек һәм өстәмә әдәбият кулланып камилләштерү. | Димәк, укучылар, безгә антонимнар ни өчен кирәк?<br><br>Физкультминут МИКС –ФРИЗ –ГРУП Бию көе куеп сораулар бирү<br>1.Һичберкайчан сөйләшми ул,<br>Ләкин һәркем аңлый телен.<br>Олы кеше дими, кече кеше дими,<br>Карт кеше дими, яшь кеше дими,<br>Өйрәтә ул безгә белем. (Китап)<br>2.Безнең бакчада тәмле, татлы, баллы, сусыл алмалар үсә.<br>3.Үзе аңсыз, йөзе ямьсез, сүзе тәмсез кешедән саклан.<br>2. Төркемнәрдә эш.<br>- экранда бирелгән мәкальләрнең икенче өлешен табарга кирәк.<br>Батыр бер үләр,.......мең үләр. (Куркак)<br>Яхшы сүз җанга рәхәт, ...... сүз җанга җәрәхәт. (Яман)<br>Төче ялганнан …... хакыйкать яхшы. (Ачы)<br>Тәмле тел таш яра, ......тел баш яра. (тәмсез)<br>Яхшы сүз-яз кебек, ....сүз-көз кебек. ( яман)<br>Яман кешегә барма,......кешедән калма. (яхшы)<br>-Димәк , антонимнар күбрәк нәрсәләрдә кулланыла?<br>Мәкальләр безне нинди булырга өйрәтә? | Җавап тыңлана. Үзбәя<br>Укучылар, антоним һәм синоним санына карап, төркемләп басалар.<br><br>Укучылар мәкальләрнең икенче өлешен эзләп табарга , өйрәнгәннәргә нигезләнеп, антонимнарын билгеләргә тиешләр.<br><br>- халык авыз иҗаты әсәрләрендә.<br><br>Тәрбияле, акыллы, яхшы .....һ.б. Үзбәя | хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү. |
| **Яңа белемнәрне мөстәкыйль куллану һәм тикшерү** | **Укытучы өчен максат:** яңа белемнәрне мөстәкыйль куллану мөмкинлеге булдыру<br><br>**Укучылар өчен максат:** синоним һәм антоним | 1. **105 нче күнегү**.Төшеп калган хәрефләрне куеп күчереп язарга, синонимнарны табарга.<br>2. **106 нчы күнегү**. Антоним сыйфатларны өстәп язарга.<br>3. Тест<br>**Ситалтиниус Раунд Тэйбл** | Күнегү мөстәкыйль рәвештә эшләнә. Дөреслеге экран аша тикшерелә. **Үзбәя**. | ШУГГ: үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау.<br>ТБУУГ: фикерләүдә логик чылбыр төзү.<br>РУУГ: эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.<br>КУУГ: күршең белән |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | сыйфатлар турындагы белемнәрне практик куллана белү. | Соңыннан дәфтәрләрен алмаштырып, бер-берсенекен тикшерәләр, эшләрен бәялиләр. | Укучылар бер-берсенең эшләрен тикшерәләр. **Үзбәя.** | хезмәттәшлек итү. |
| **Уку эшчәнлеген йомгаклау.** | **Укытучы өчен максат:** дәрестәге эшчәнлекне анализлау, белемнәрне бәяләү.<br><br>**Укучылар өчен максат:** үз фикереңне дәлилләү, дәрестә алган белемнәрнең әһәмиятен аңлау, аларны киләчәктә куллана белү.<br><br>**Укытучы өчен максат:** өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын аңлату.<br>**Укучылар өчен максат:** өй эшен дөрес башкару. | Рефлексия.<br>1. Нинди УМ тикшердек?<br>- Без дәрескә нинди максат куйган идек?<br>- Максаты бызга ирештекме?<br>-- Нәрсә өчен кирәк соң безгә синоним һәм антоним сыйфатлар?<br>- Алар безгә киләчәктә кирәк булачакмы?<br>2. Белемнәрне бәяләү.<br>3. Өй эше.<br>107 нче күнегү – мәҗбүри. Төшеп калган хәрефләрне куеп күчереп язарга,сыйфатларның антонимнарын табарга.<br>108 нче күнегү – ярым иҗади.<br>Антоним сыйфатлар кергән мәкальләр сайлап язарга.<br>109 нчы күнегү - иҗади. Синоним һәм антоним сыйфатлар кулланып, “Табигать үзгәрешләре” дигән иҗади эш. | Синоним һәм антоним сыйфатлар турында өйрәндек.<br><br>Балаларның җаваплары тыңланыла.<br><br>Алар безгә киләчәктә кирәк булачак. | ШУУГ: үз уңышларың / уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү.<br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу. |

## ИЯРЧЕН МАКСАТ ҖӨМЛӘ

(сингапур структурасына нигезләнгән дәрес эшкәртмәсе)

***Рамазанова Розалия Гарифулла кызы,***
***Коркачык гомуми урта белем мәктәбе***

**I. Максатлар:**
1. фәнни максат: иярчен максат җөмлә турында мәгълүмат бирү;
2. коммуникатив максат: иярчен максат җөмләләр кулланып хикәя төзү;
3. тәрбияви максат: укучыларда хезмәткә карата хөрмәт тәрбияләү.

**II. Бурычлар:**
1. иярчен максат җөмлә турында мәгълүмат бирү;
2. иярчен максат җөмләне иярчен сәбәп җөмләдән аерырга өйрәтү;
3. бәйләүче чаралар нигезендә иярчен максат җөмләләрне танырга өйрәтү;
4. иярчен максат җөмләләр хисабына укучыларның сүзлек байлыгын арттыру.

**III. Принциплар:**
1. дидактик принциплар: фәннилек, күрсәтмәлелек, эзлеклелек, предметара бәйләнеш;
2. лингвистик принциплар: функциональ, бүлекара бәйләнеш.
3. гомумметодик принциплар: коммуникатив, ситуатив.

4. хосусый методик принциплар: чагыштыру, грамматик теория белән сөйләм практикасының берлеге.

**IV. Укыту ысуллары:**

1. аңлату-күрсәтү;
2. өлешчә эзләнү;
3. тикшеренү.

**V. Укыту алымнары:** таблица белән эшләү, темага карата фикер алышу, күнегүләр эшләү, карточкалар белән эш.

**VI. Кулланылган стуктуралар:**

**- КУИЗ-КУИЗ-ТРЕЙД,**

**- ФОЛОУ ЗЕ ЛИДЕР,**

**- ТИК - ТЭК – ТОУ,**

**-МИКС ПЭА ШЭА,**

**- КОНТИНИУС РАУНД РОБИН,**

**- РАУНД РОБИН**

**Дәрес барышы**

1) Укучыларның дәрескә әзерлекләрен ***ХАЙ ФАЙВ*** структурасы ярдәмендә тикшерү.

**I. Укытучы:** Исәнмесез, укучылар! Утырыгыз. Кәефләрегез ничек? Барыгыз да бармы? Алайса, дәресебезне башлыйбыз.

- Бүгенге дәрестә без сезнең белән төрле структуралар кулланып дәресебезне алып барырбыз.

**II.Укытучы:** - Укучылар, яңа темага кереп киткәнче, кушма җөмләләрне кабатлап китәбез.

- Сез хәзер ***КУИЗ-КУИЗ-ТРЕЙД (опроси-опроси-обменяйся)***структурасы ярдәмендә бер-берегезнең белемнәрен тикшерерсез. Моның өчен сезгә карточкалар ясарга кирәк булачак.

-Хәзер беренче номерлы партнерлар ак бит алалар, битне уртага бүләләр. Яртысын иң баш партнерына бирәләр һәм тагын уртага битне бүләргә тиеш буласыз. Битнең берсен биткә-бит партнерга бирәсез.

Битнең астын 4/1 өлешен бөкләргә кирәк була.(Күрсәтелә).

-Битнең күренә торган өлешенә сез иң яхшы дип саналган соравыгызны язасыз,ә күренми торган өлешенә соравыгызга җавабы языла.

- Моны эшләү өчен сезгә 2 минут вакыт бирелә. Вакыт башланды (Таймер куела).

- Вакыт бетте. Хәзер сез торасыз, кулыгызны күтәрәсез, якында булган иптәшегез янына барасыз һәм соравыгызны бирәсез, иптәшегез сорауга җавап бирергә тиеш. Иптәшегез сорауга җавап бирә алмаса,сез аңа булышасыз. Дөрес җавап ишеткәннән соң, иптәшегезне мактыйсыз һәм аның соравын тыңлап җавап бирәсез. Бергә кабатлыйбыз "Молодец, рәхмәт, миңа синең белән эшләргә бик рәхәт булды".

1. **ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ** - ияреп килгән **һәм** баш җөмләдән чыгып куелган сорауга җавап булып килгән җөмлә.
2. **БАШ ҖӨМЛӘ** - ияртеп килә торган **һәм** аннан чыгып, башка җөмләгә сорау куела торган җөмлә.
3. **ТӨЗЕЛЕШЕ БУЕНЧА ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘНЕҢ ТӨРЛӘРЕ** - аналитик **һәм** синтетик.
4. **АНАЛИТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ** - баш җөмләгә үзенең хәбәре составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә.
5. **СИНТЕТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ** - баш җөмләгә үзенең хәбәре составындагы чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә.
6. **АНАЛИТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘРНЕ БАШ ҖӨМЛӘГӘ БӘЙЛӘҮЧЕ ЧАРАЛАР** - мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр, көттерү интонациясе.
7 .**ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘР МӘГЪНӘ ЯГЫННАН ТӨРЛӘРГӘ БҮЛЕНӘ** - нинди җөмлә кисәге мәгънәсендә килүенә карап.

**III.1.Укытучы:** Бик яхшы, укучылар, булдырдыгыз. Без бүгенге дәрестә иярчен җөмләләрне өйрәнүне дәвам итәбез.

**Укытучы:** Бүгенге дәресебезнең темасы – "Иярчен максат җөмлә". (укучылар дәреснең темасын бергәләп, кычкырып әйтәләр). Ә, хәзер дәфтәрләрне ачып, бүгенге числоны һәм теманы язып куябыз.

Укучылар, тактага игътибар итик әле. Монда безнең ике җөмлә бирелгән:

Мең орлыкның һәммәсе дә шытып чыксын, шуның өчен җирне бик яхшы эшкәртергә кирәк.

( ... ), [шуның өчен]

Игеннәр мул уңыш бирсен дип, вакытында кар тоту оештырылды.

( ... дип), [ ].

Беренче җөмләне укый өстәл №... №...

Нинди максат белән җирне эшкәртергә кирәк?

**Укучы:** Мең орлыкның һәммәсе дә шытып чыксын, шуның өчен җирне бик яхшы эшкәртергә кирәк.

**Укытучы:** Бу җөмләнең баш кисәкләрен табыйк әле.

**Укучы:** Һәммәсе шытып чыксын, эшкәртергә кирәк.

**Укытучы:** Әйе, кайсы җөмлә баш җөмлә була?

**Укучы:** Икенче җөмлә баш җөмлә була, беренче җөмлә иярчен җөмлә була.

**Укытучы:** Иярчен җөмләнең төрен билгеләп карыйк әле, моның өчен баш җөмләдән иярчен җөмләгә нинди сорау куеп була?

**Укучы:** Нинди максат белән җирне эшкәртергә кирәк?

**Укытучы:** Бик дөрес. Бәйләүче чарасы кайда?

**Укучы:** ***Шуның өчен*** мөнәсәбәтле сүзе. Иярчен җөмлә баш җөмләнең максат хәле урынында килә.

**Укытучы:** Яхшы. Димәк, укучылар, бу җөмлә иярчен максат җөмлә була. Укучылар, иярчен максат җөмләнең кагыйдәсен чыгарып карыйк әле.

Әйдә, өстәл №....., №....

**Укучы:** Иярчен максат җөмлә я баш җөмләнең максат хәле урынында килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән максат хәлен ачыклый.

**Укытучы:** Бик яхшы. Димәк, укучылар, иярчен максат җөмлә баш җөмләнең максат хәле урынында килә һәм баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән максат хәленең конкрет эчтәлеген тәшкил итә.

Җөмләнең мәгънә ягыннан төрен билгеләгәндә бәйләүче чараларны белү мөһим. Әйдәгез әле, иярчен максат җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чараларны тактадагы таблицадан карап китик. Укучылар, кем безгә аналитик төрнең бәйләүче чараларын укып чыгар? Әйдә әле, ...

**Иярчен максат җөмлә:**

| **Синтетик төре** | **Аналитик төре** |
|---|---|
| 1.өчен бәйлеге, дип сүзе ярдәмендә;<br>2.-сын / -сен боер. фиг. формасы + -га / -гә юнәлеш килеше кушымчасы;<br>3.-маска / -мәскә фигыль формасы. | 1.шуның өчен, моның өчен, аның өчен мөнәсәбәтле сүзләре ярдәмендә;<br>2.күтәрү интонациясе. |

Бик яхшы, укучылар. Ә хәзер дәреслекләрне ачып, иярчен максат җөмлә турында укыйбыз. Өстәл№....№..... (укучы параграфны укый)

**Укытучы:** Рәхмәт, яхшы.

**Ял минуты**. ***ФОЛОУ ЗЕ ЛИДЕР(следуем за лидером)*** структурасы.

- Без сезнең белән хәзер аз гына ял итеп алабыз. Моның өчен без ФОЛОУ ЗЕ ЛИДЕР (следуем за лидером) структурасын кулланабыз.

Сез хәзер бер-берегез артына басасыз. Музыка уйный башлау белән, беренче укучы - ул лидер, нәрсә эшли, сез дә шуны эшләргә тиеш буласыз. Хәрәкәтләрне сыйныф буенча эшлибез. Музыка бетүгә лидер алышына . Беренче укучы артка барып баса. Хәзер инде икенче укучы лидер була, һәм шулай дәвам итәбез.

- Барыбыз да урындыкларны рәтләдек, бер-беребез артыннын бастык. Музыка башланды. (Музыканы туктатабыз һәм җибәрәбез). Рәхмәт ,урыннарга утырабыз.

- Дәресебезне дәвам итәбез. Укучылар, иярчен максат җөмләләр аналитик төрдән синтетик төргә үзгәрәләр һәм үзара синонимнар булып торалар. Моны ныклап карау өчен өстәлләрдәге беренче номерлы карточкаларга игътибар итик әле.(өстәлдә карточка № 1)

***Беренче җөмлә***: Игеннәр мул уңыш бирсен өчен, вакытында кар тоту оештырылды.

( ... өчен), [ ] Бу иярчен максат җөмлә, синтетик төре.

***Икенче җөмлә:*** Игеннәр мул уңыш бирсен дип, вакытында кар тоту оештырылды.

( ... дип), [ ] Бу иярчен максат җөмлә, синтетик төре.

***Өченче җөмлә***: Игеннәр мул уңыш бирсен, шуның өчен вакытында кар тоту оештырылды.

( ...), [ шуның өчен] Бу иярчен максат җөмлә, аналитик төре.

*Укучылар, әгәр сез бу җавап белән килешсәгез, баш бармакларыгызны өскә күтәрәсез, әгәр килешмисез икән, киресенчә түбән төшерәсез.*

- Хәзер, без сезнең белән дәресебезне ***МИКС ПЭА ШЭА структурасы*** ярдәмендә дәвам итәбез.. (***Музыка тавышы яңгырый.)*** Укучылар музыка тәэсиренә бирелеп хәрәкәт итә, шуннан соң туктап кала. Шул вакытта алар тиз генә парлашып өлгерергә тиеш. Кулларын өскә күтәреп “биш” бирәләр. Укытучы тема буенча сорау бирә, укучылар үз фикерләрен, җавапларын әйтә. Уен дәвам итә, музыка туктагач, алар башка парга берләшә.

*-Нинди җөмлә ул иярченле кушма җөмлә?(үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмлә иярченле кушма җөмлә дип атала)*

*-Иярчен җөмләләрне без нинди төркемнәргә бүлеп өйрәнәбез?(төзелеше, мәгънәсе)*

*-Төзелеше ягыннан иярчен җөмләләр нинди булалар?(аналитик, синтетик)*

*-Иярчен хәл җөмләләрнең саны ничә?(8)(иярчен вакыт, иярчен урын, иярчен рәвеш, иярчен күләм, иярчен сәбәп, иярчен максат, иярчен шарт, иярчен кире)*

**Укытучы:** -ХАЙ ФАЙВ.

**Карточка№2 (төркемнәрдә эшләү).** Җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрен билгеләгез. Җөмләдәге бәйләүче чараларны синонимнары белән алыштырыгыз.

Иң кызыгы шул: күренмичә йөри ул. Без Хәкимҗан белән алгарак чыгарга маташкан арада, беренче ат тар гына юлдан выжлап узып та китте. Гайфулла белән Сәлим, авыл картлары да шаһит булсыннар дип, әле генә безне алып_чыктылар.

**1**. Иң кызыгы менә нәрсә: күренмичә йөри ул (иярчен хәбәр җөмлә).

**2**.Без Хәкимҗан белән алгарак чыгарга маташкан вакытта, беренче ат тар гына юлдан выжлап узып та китте (иярчен вакыт җөмлә).

**3**.Гайфулла белән Сәлим, авыл картлары да шаһит булсыннар өчен, әле генә безне алып чыктылар (иярчен максат җөмлә).

**Укытучы:** Күргәнебезчә, җөмләләр бәйләүче чаралары белән генә аерылалар. Димәк, бер җөмләне төрле бәйләүче чаралар ярдәмендә бер төрдән икенче төргә үзгәртеп була. Шуны да әйтергә кирәк: еш кына иярчен максат җөмләләрне иярчен сәбәп җөмләләр белән бутыйлар. Кайбер очракта иярчен сәбәп җөмләгә дә, иярчен максат җөмләгә дә бер үк сорау куеп була. Мондый очракта җөмләнең төрен дөрес билгеләү өчен, түбәндәге үзенчәлекне истә тотарга кирәк: иярчен сәбәп җөмләдәге процесс үткәнгә карый, ә иярчен максат җөмләдәге процесс киләчәккә карый.

**IV.Укытучы:** Алдагы эшне без **ТИК - ТЭК – ТОУ(крестики нолики)** структурасы ярдәмендә үтәячәкбез.

- Моның өчен сезнең өстәлләрегезгә карточкалар(№3) куелган .

- Икенче номерлы партнер әлеге битләрне өстәлнең уртасына ,тәртип буенча 3*3 рәвешендә урнаштыра.

Сез хәзер сүзләрдән 3 җөмлә төзергә тиеш буласыз. Ләкин теләсә ничек түгел, яки горизонталь, яки вертикаль, яки диагональ буенча. Башка сүзләр өстәргә ярый.

Җөмләләр төзи башлаганчы, сез сүзләрне нинди тәртиптә кулланасыз , язып куярга тиеш буласыз. Сезгә моның өчен 3 минут вакыт бирелә. Вакыт башланды.(Таймер куела).

- Вакытыгыз бетте. Хәзер сез **КОНТИНИУС РАУНД РОБИН (продолжительный раунд робин) структурасы** ярдәменә командада бер-берегезгә чират буенча җөмләләрегезне укыйсыз, истә калдырырга тырышасыз яки язасыз.

– Беренче булып дүртенче номерлы партнер үзенең беренче җөмләсен укый һәм шулай чылбыр буенча эшне дәвам итәбез. Аннары икенче җөмләне укыйсыз һәм өченче җөмләне.

Моның өчен сезгә 3 минут вакыт бирелә. Вакыт китте (Таймер куела).

**-РАУНД РОБИН** ***структурасы ярдәмендә. (По часовой стрелке.)Укучылар***, хәзер яңа материалны ныгыту өчен күнегү эшләп алабыз. (Кәгазь битендә эшләү.) Укучылар, бу күнегүдә сез, беренче баганадагы җөмләнең икенче баганадагы дөрес дип уйланган схемага уклар җибәрәсез. Һәм җөмләнең төрен билгелисез.

1. Монда эш кайный, шуңа күрә күңелле. (...),[ шуңа күрә ...].
 (иярчен сәбәп)
2. Уру вакытында башлансын, шуның өчен машиналарны алдан ук хәзерләп куегыз. ( ... ), [ шуның өчен]. (иярчен максат)
3. Бер баруда эшләре бетсен дип, әнкәй ураклары кертеп бирде.
 ( ... дип), [ ]. (иярчен максат)
4. Әйткән сүзгә каршы килмәгәч, аны һәр җирдә яраттылар.
 (...),[...]. (иярчен сәбәп)
5. Бәдри китү сәбәпле, Хәлим налогны үзе генә җыярга булды.
 ( ... сәбәпле), [ ]. (иярчен сәбәп)

6. Безгә китаплар шуның өчен кирәк, без беренчеләргә китапханә оештырырга булдык. [...шуның өчен.. ], (...). (иярчен максат)

7. Яңгыр яуса, тузан басылыр иде. (са),[….]. (иярчен шарт)

8. Ул кая гына бармасын, һәр җирдә таныйлар. (сын),[….].

Кәгазь битләре №1 җыеп алына.

**Укытучы:** Бик дөрес, укучылар, булдырдыгыз. Ә хәзер менә тактада язылган *"Кайда хезмәт, шунда хөрмәт"*мәкаленә бәйле, хезмәт турында кечкенә генә хикәя язабыз. Аннары тикшерәбез.

**Укытучы:** Кайсыгызның бетте? Кем үзенең хикәясен укырга тели? Әйдә, өстәл №... , №... Укучылар, барыбыз да тыңлыйбыз.

(берәр укучыдан укыту)

**Укучы:** *Җир йөзенә кеше хезмәт итәргә килә. Хезмәт белән бәйле тормыштан, кеше ямь табып яши. Хезмәтнең әһәмияте шунда: ул кешене кеше итә, яшәвенә мәгънә, көч бирә.*

*Үзенең күңеленә ошаган һөнәрне һәркем сайларга хокуклы. "Кайда хезмәт, шунда хөрмәт" – дип , халык юкка гына әйтмәгәннәр. Кеше үзенең сайлаган һөнәре белән халыкка хезмәт итә, яшәвен мәңгеләштерә.*

**Укытучы:** Бик яхшы, укучылар, молодцы. Барыбызга да билгеле: һөнәр сайлау һәркемнең шәхси эше. Һөнәр сайлаганда шуны истән чыгармаска кирәк : һәр кеше үз мөмкинлеген яхшы белергә тиеш. Холкыңны һәм белемне дә истән чыгармаска кирәк. Белем булган җирдә хезмәтнең нәтиҗәсе күренә.

**V. Өй эше бирү.** Ә хәзер көндәлекләрне ачып, өй эшен язып куегыз.

Өй эше: иярчен сәбәп һәм иярчен максат җөмләләр кулланып хикәя төзергә.

**VI. 1. (Парковка)** Укучылар, өстәлдәге карточкаларны алып, сорауларга җавап язызыз һәм аларны парковкага илтеп куясыз. Биремнәр аңлашылдымы? Сезгә дәрес ошадымы? Тагын нинди сорауларыгыз бар, язып калдырыгыз.

Укучылар, хәзер өйрәнелгән теманы ничек аңлаганыгызны тикшерү максатыннан тагын бер эш эшләп алабыз. Сезгә өч чатта сүзләр язылган плакат эленгән. Сез шуның кайсысын дөрес дип табасыз, шул чатка барып басасыз. - Молодцы! Бик яхшы!

**2. Укытучы:** укучылар, бүген дәрестә барыгыз да бик актив катнаштыгыз, молодцы. Бик тырышып эшләгәннәргә ....... "5" ле билгесе куям.

## ИНФИНИТИВ+ХИКӘЯ ФИГЫЛЬ СТРУКТУРАСЫН СӨЙЛӘМГӘ КЕРТҮ
(5 нче сыйныф, рус төркеме)

***Гобәйдуллина Алмазия Фәрит кызы,***
***Бөреле гомуми урта белем бирү мәктәбе***

**Дәреснең тибы.** Яңа төшенчәләр формалаштыру дәресе.

**Дәреснең** белем бирү максаты – укучыларның инфинитив темасы буенча алдагы дәресләрдә өйрәнгән белемнәрен искә төшерү, инфинитивны хикәя фигыльләр белән дөрес кулланырга өйрәтү.

**Фикер сәләтен үстерү максаты** – укучыларның өйрәнгән структураны тиешле урында кулланырга омтылыш уяту. Җөмлә, диалог төзү күнекмәләрен үстерү.

**Тәрбияви максат**ы - укучыларга әти-әнигә һәрвакыт булышырга, ярдәмгә килергә кирәклеген төшендерү.

**Җиһазлау:** компьютер, проектор, экран, тема буенча презентация, карточкалар, татар теле дәреслеге.

**Дәреслек**: 5 нче сыйныф өчен Р.З.Хәйдәрова тарафыннан эшләнгән (Казан, Мәгариф, 2011), ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслек һәм рус телендә сөйләшүче балалар белән эшләүче укытучылар өчен Р.З. Хәйдәрова, Л.Ә.Гыйниятуллина әзерләгән кулланмага нигезләнеп төзелде.

**Дәрес технологиясе**: үстерешле укыту.

**Методы:** өлешчә эзләнү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

- Шәхси нәтиҗәләр: укытучы һәм сыйныфташлар белән берлектә эшләргә,төркемнәрдә, индивидуаль рәвештә эшне оештырырга, уртак нәтиҗәгә килергә, үз фикереңне дәлилләргә өйрәтергә.
- Предмет нәтиҗәләр: өйрәнгән структураны сөйләмдә кулланырга өйрәтү, кечкенә диалоглар, җөмләләр төзүгә ирешү.
- Метапредмет нәтиҗәләр: үзмаксат куярга өйрәтү, шул максатка ирешү юлларын үзлектән табарга омтылыш уяту.

- Регулятив: уку мәсьәләсен кабул итү һәм дәрес дәвамында шуның буенча эшләү, куелган мәсьәлә нигезендә үз эшчәнлегеңне планлаштыру.

**Танып - белү**: язма һәм телдән сөйләмдә үз фикерләреңне формалаштыра белү;

**Коммуникатив**: дәрес дәвамында башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм җавабыңны яклый белү, бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү.

**Эш төрләре:** фронталь, төркемләп, индивидуаль.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлешенең максаты:** укучыларның игътибарын дәрескә юнәлтү, аларда уңай эмоциональ халәт тудыру.

Укытучы: Исәнмесез! Хәерле көн! Укучылар: Исәнмесез! Хәерле көн!

Укытучы: Кәефләрегез ничек? Укучылар: Рәхмәт, яхшы.

Укытучы: Бик яхшы! Укучылар, бүген безне дәрестә күп эшләр көтә. Игътибар белән тыңлап җавап бирсәгез, барыгыз да “4"ле һәм “5"леләр алырсыз дип ышанам. Ә хәзер, укучылар, өй эшен тикшерәбез.

**II. Актуальләштерү.** Уку эшчәнлеген мотивлаштыру. Үткән дәрес материалын хәтердә яңарту.

Максат. Кулланылачак белемнәрне искә төшерү. Белмәгәннәргә дә белергә мөмкинлек тудыру.

Укытучы: Укучылар, хәзер алдагы дәресләрдә үткәннәрне искә төшереп үтик әле. Слайдтагы рәсемгә карагыз әле. Сез монда нәрсә күрәсез? Бу бүлмәне тәртипкә китерер өчен, сез монда нишләр идегез?

Ребята, мы с вами поможем Алсу подмести пол, помыть посуду, прибрать комнату? А как скажем по татарски поможем? (Җаваплар тыңлана: булышабыз).

**III. Карточкалар белән эш.** Син Алсуга нишләргә булышасың? соравына җавап язарга. Укучылар бер-берсен тикшерәләр, билге куялар. (Үзбәя).

**IV. Дәрескә максат һәм бурычлар кую.**

Максат. Уку мәсьәләсен чишү. Куелган мәсьәлә аерым, гади уку биремнәренә бүлгәләп башкарыла.

а) - Укучылар, безгә бүген хат килде? Сез хат укырга яратасызмы? Сезгә хатлар киләме? (Җаваплар тыңлана)

а) Әйдәгез, безгә килгән хатны укып китик әле. Кем язды икән аны безгә? Игътибарлы булыгыз, хатны укыгач, бүгенге дәресебезнең темасын һәм максатларын белербез.

б) Сорауларга җавап бирү.

- Укучылар, хатны кем язган? (Әни)

- Хаттагы малайны без беләбезме? (Хат Рәсим турында.)

- Димәк, дәрестә без кемнәр турында сөйләшербез? (Рәсим белән Илнур турында)

- Дәрескә нинди бурыч куябыз? (Малайларнын характерларын ачыклау)

в) Рәсим һәм Илнур турында ике укучы сөйли.

в) Дәреслектән күнегү эшләү. 47б. 8 нче күнегү.

г) Парларда эшләү, диалогларны тикшерү .Укучылар бер-берсенә сораулар бирәләр. (Микс ПЭА ШЭА структурасы) Үзегезгә парлар табасыз һәм сөйлисез. Сезгә 1 минут вакыт бирелә. (Кемнең чәче озынрак, шул башлый).

д) Укучылар, бүген бездә кунаклар. Әйдәгез, аларны татар халкының милли ризыгы -бәлеш белән сыйлыйбыз. Миңа бәлеш пешерергә булышасызмы? Мин сезгә эшләрне бүлеп бирдем.

..., син миңа нишләргә булышасың?

-..., мин сезгә бәрәңге әрчергә булышам.

- Рәхмәт, син бик эшчән кыз (малай)

-..., .... ....?

-...., мин сезгә ит турарга булышам.

Менә бәлешебез әзер инде. Рәхмәт, сез эшчән балалар.

**V. Өй эшен бирү.** 57 №3

**VI. Эшчәнлеккә рефлексия.** Белемнәрне формалаштыру, үзбәя, үзконтроль. Бәя кую уку мәсьәләсен кисәкләргә бүлеп өйрәнүдән җыелган билгеләргә нигезләнә.

- Укучылар, бүгенге дәрес ошадымы? Бүген дәрестә нишләдек? Нәрсәгә өйрәндек? Без нинди булырга тиеш икән? Көтелгән җавап: тырыш,уңган.

- Әйе, бик дөрес укучылар , без тырыш, эш сөючән һәм уңган булырбыз.

**VII. Билгеләр кую.** Укытучы: Укучылар, тырышлык бушка китми, ул үзенең нәтиҗәләрен бирә. Җавапларыгыз да, китергән мисалларыгыз да дөрес. Бүген барыгыз да бик яхшы эшләде.

Билге кую өчен критерий: "5" - биремнәр төгәл үтәлде, җаваплар аңлаешлы булды (кызыл смайкл);

"4" - бер-ике сорауда хата булды (сары смайкл);

"3" - биремнәр төгәл үтәлмәде, хаталар күп булды (яшел смайкл);

Укытучы: Дәрестә актив катнашуыгыз өчен рәхмәт. Сау булыгыз!

## ЭЧТӘЛЕК


| | | |
|---|---|---|
| **КЕРЕШ** | **Юнысова С.Ф.** Биектау муниципаль районы мәктәпләрендә федераль дәүләт белем бирү стандартлары шартларында милли укыту-тәрбия процессын оештыру үзенчәлекләре ............................................... | 3 |
| **І НЧЕ БҮЛЕК** | **ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЫ ТАЛӘПЛӘРЕН ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТОРМЫШКА АШЫРУ** | |
| | **Вәлиуллина С.М.** Г.Тукайның "Кызыклы шәкерт" шигыренә технологик карта төзү ........................................................................ | 6 |
| | **Галиәхмәтова Ч.И.** Риваять һәм легендаларны өйрәнү дәресенең технологик картасы ........................................................................ | 10 |
| | **Галиәхмәтова Р.И.** Эндәш сүзләрне кабатлау .......................................... | 13 |
| | **Низамиева Ә.Н.** Яңа әдәбият дәреслекләре һәм дәрестән тыш уку ......... | 23 |
| | **Әхмәдуллина С.Н.** Аваз ияртемнәре турында төшенчә, төзелеше ягыннан төрләре (7 нче сыйныф) ........................................................ | 26 |
| | **Тазмиева Р.М.** Дуртаяклы дусларыбыз (әдәби укудан дәрес эшкәртмәсе, 3 сыйныф, рус төркеме)........................................................ | 30 |
| | **Гарипова К.Б.** Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә буыннар бәйләнеше (7 нче сыйныф) ........................................................................ | 32 |
| | **Сәйфуллина Р.С.** Исем, сыйфат, фигыль сүз төркемнәрен кабатлау (2 нче сыйныф өчен дәрес фрагменты) ........................................................ | 35 |
| | **Җамалиева Л.И.** Серле хәрефләр (10 нчы сыйныфта татар теле һәм әдәбиятыннан интеграл дәрес) .................................................................. | 37 |
| | **Рамазанова Р.Р.** Затланышлы һәм затланышсыз фигыльтөркемчәләрен гомумиләштереп кабатлау (Татар төркеме. 7 нче сыйныф) ....................... | 41 |
| **ІІ НЧЕ БҮЛЕК** | **ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫ ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА СИНГАПУР СТРУКТУРАЛАРЫН КУЛЛАНУ** | |
| | **Низамиева Ә.Н.** Ата-ана бердәм булса, балалары күркәм үсә (М. Маликованың "Чәчкә балы" повестена анализ) ....................................... | 46 |
| | **Әбүбәкерова Р.Ә.** Ямьле җәй җитте (дәресекә технологик карта, 4 сыйныф, рус төркеме) ........................................................................ | 51 |
| | **Сәгыева Р.Ә.** Күләм хәле ........................................................................ | 56 |
| | **Вәлиева А.З.** Сорау җөмлә (5 нче сыйныф) ................................................ | 58 |
| | **Садикова Д.С.** "Күгәрчен һәм малай" хикәясен өйрәнү (дәреснең технологик картасы) ........................................................................ | 61 |
| | **Абдуллина Н.Н**. Хезмәтле кеше - хөрмәтле кеше (8 нче сыйныф, рус төркеме)........................................................................ | 66 |
| | **Минһаҗетдинова Р.Ф.** Синоним һәм антоним сыйфатлар (дәрескә технологик карта, 5 нче сыйныф) ................................................................ | 70 |
| | **Рамазанова Р.Р.** Иярчен максат җөмлә (сингапур структурасына нигезләнгән дәрес эшкәртмәсе) ................................................................ | 74 |
| | **Гобәйдуллина А.Ф.** Инфинитив+хикәя фигыль структурасын сөйләмгә кертү (5 нче сыйныф, рус төркеме) ............................................................ | 78 |